**Әлмәт энциклопедиясе**

**Марсель Әхмәтҗанов**

# ДАСТАННАР ВАТАНЫ

**аръягының көнчыгыш төбәкләре һәм татар әдәбияты тарихы.**

**Казан. Мәгариф. 1999**

УДК 820/89.0
ББК 83.3(2Рос-Тат)
Ә 87

«Әлмәт энциклопедиясе» фәнни-иҗади төркеменең
төбәк тарихын тикшерүгә багышланган IV китабы

**Әхмәтҗанов М. И.**

Дастаннар ватаны: Кама аръягының көнчыгыш төбәкләре һәм татар әдәбияты тарихы.— Казан: Мәгариф, 1999. —159 б.
ISBN 5-7761-0848-9

Татар филологиясендә төбәк әдәбияты тарихын өйрәнүнең беренче тәҗрибәсе булган бу китап борынгы язма чыганакларны археографик экспедицияләр юлы белән эзләп табу, фәнни архивларда, китапханәләрдә тикшеренү эшләре алып бару, катлаулы текстологик хезмәт нәтиҗәләре нигезендә язылды.
Китап студентларга, әдәбият укытучыларына, татар әдәби мирасын сөючеләргә һәм укучы яшьләргә адреслана.

**БЗ — 7(66)—87—2000/2001**

ISBN 5-7761-0848-9
© «Мәгариф» нәшрияты, 1999

## КЕРЕШ

*Аерым татар төбәкләренең әдәби үткәне, мәдәни тарихы хакындагы фәнни карашны бездә беренче мәртәбә күренекле татар галиме, археограф Альберт Фәтхи (1937—1992) тикшереп, билгеле бер системага салып мәйданга чыгарды. Без бу очракта аның үз заманында «Казан утлары» журналында басылган «Мәгърифәт төбәкләре һәм әдәби бäгланышлар» исемле хезмәтен күз алдында тотабыз (1968, №2, 103—122 б.). Танылган галимнең әлеге проблеманы чишү юлларын күрсәтүе безнең тарафтан алга максат итеп куелган хезмәтнең язылышына таяныч итеп алынды.*

*Әдәбият тарихын язу өчен беренче чиратта чыганаклар кирәклеге фәндә зарури әйбер. Шунлыктан, проблемага бәйле рәвештә, чыганакларны эзләп табарга, аларны өйрәнергә һәм анализларга туры килде. Мәгълүм булганча, татар әдәбиятының узган тарихы буенча конкрет чыганаклар системасы билгеле бер күләмдә безнең галимнәребез тарафыннан барланган. Ул чыганаклар тел, текстология, жанр яссылыгында өйрәнелеп, аларның татар әдәбиятына мөнәсәбәтләре фәнни нигезгә куеп эшләнгән. Аларның мәгълүм булган өлешен Кама аръягының көнчыгыш төбәге белән бәйләп карау мантыйкка ярашлы булып тора. Ләкин һәр төбәкнең үз үзенчәлеге анда туган әдәбиятта чагылмый калмый, шуның белән Әлмәт ягы да татар әдәбиятының бай мирасы, үзенчәлекле төбәге буларак таныла.*

*Игътибарыгызга тәкъдим ителгән бу хезмәтне язганда, күрсәтелгән юнәлештә эш алып барылды.*

*Төбәкнең әдәби чыганакларын барлау, эзләнүләр алып бару процессында, аларның татар галимнәре хезмәтләрендә һәм кайбер фәнни архивларда ни дәрәҗәдә сакланган булуына ачыклык кертелде.*

*Тупланган чыганаклардан күренгәнчә, төбәктә урта гасырлардан алып XX гасырның беренче чирегенә кадәр өзлексез рәвештә татар милли әдәбияты үсеп килә. Урыс мәдәниятенең аерым вәкилләре (мәсәлән Петр Рычков) бу төбәк белән бәйле булсалар да, алар монда бердәм җирле урыс*

*әдәбиятын тудыра алмадылар.*

*«Әлмәт энциклопедиясе» сериясеннән нәшер ителә торган бу китапта урта гасырлардан алып XX йөз башларына кадәр Кама аръягының көнчыгыш төбәкләрендә булган әдәби күренешләр бәян ителә. Әлбәттә, бер өлеш материал гомуми характерда алынып, күп санлы басмаларга нигезләнеп бирелде. Әлеге хезмәтнең төп чыганаклары Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Кулъязмалар бүлеге мирасханәсендә саклана.*

## КАМА АРЪЯГЫ ТӨБӘКЛӘРЕНДӘГЕ АРХЕОГРАФИК ТАБЫШЛАР

Кама аръягының көнчыгыш өлеше әдәби-язма чыганаклары белән кызыксыну XIX йөз урталарыннан ук башлана. Башта бу юнәлештә эшләргә Салихҗан Кукляшев, Туктар Ибраев, Ризаэддин бине Фәхреддин, Һади Атласов, Фазыл Туйкин, Сәйед Вахиди һ. б. татар укымышлылары алыналар.

Салихҗан Кукляшев (1811—1864) үзенең 1851 елда Казанда басылып чыккан «Диване хикаяте татар» исемле хрестоматиясендә татар кулъязмаларыннан алынган әдәби мирас үрнәкләрен бастыра. Хрестоматия авторы үзе Бөгелмә төбәгеннән булган дип күрсәтелә. Аның хрестоматиясенә борынгы кулъязма китаплардан алып кертелгән «Гайсә углы Амәт», «Искәндәрнамә» һ. б. урта гасыр ядкәрләрен Кама аръягы көнчыгышында табылган истәлекләр дип уйларга нигез бар. Туктар Ибраев тарафыннан Байсар авылында 1851 елны төзелгән «Кара бик шәҗәрәсе» чыганаклары да шушы фикерне куәтлиләр.

Әлмәт төбәге Кичүчат авылында туган Ризаэддин бине Фәхреддин (1859—1936), XIX гасыр ахырында үзенең туган төбәгендә гаять бай борынгы язма әдәби-тарихи чыганаклар коллекциясе туплап, алар нигезендә атаклы «Асар» исемле био-библиографик хезмәтен яза.

Ризаэддин бине Фәхреддин җыйган археографик коллекциядә Казан ханнарыннан Мөхәммәд Әмин, Сахиб Гәрәй, Сафа Гәрәй һ.б. ярлыкларыннан үрнәкләр тупланган була. Шулай ук анда тарихи легендалар текстлары кергән шәҗәрәләр, елъязмалар, хикәятләр, аерым галимнәрнең, шагыйрьләрнең автографлары туплана. Ләкин, кызганыч ки, 1911 елның 12 февралендә патша жандармериясе тарафыннан уздырылган тентү вакытында галимнең иң кыйммәтле әсәрләре, кулъязмалары конфискацияләнә һәм соңыннан аларның бик аз өлеше генә хуҗасына кире кайтарыла. Шулай да галимнең архивында бик кызыклы тарихи документлар шактый күләмдә сакланып калган. Петербургтагы Русия Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институты архивында Ризаэддин бине Фәхреддин җыйган кыйммәтле документлар тупланмасы бар. Алар арасында Мифтахеддин Акмулла, Мәхүбҗамал Акчурина, Гали Чокрый, Гарифулла Чокрый, Хөсәен Фәизханов һәм башкаларның кулъязмалары, йөзләгән татар шәҗәрәләре текстлары һ. б. мәгъ-лүм. Галим туплаган материалларның бер өлеше аның Уфадагы архивында кулъязма килеш калган «Асар» хезмәтенең 3—4 томнарын язган вакытта файдаланылган.

Ризаэддин бине Фәхреддин үзе бөек галим-реформатор, тарихчы Шиһабеддин Мәрҗани хәзрәтләреннән өйрәнә, фән дөньясында аның шәкерте санала.

Тарихчы-галим Һади Атласов (1876—1938), Әлмәт якларында яшәгәндә, чыганаклар ачыклау буенча күп эшли. Аның китапханәсендә кулъязма китаплар, документлар, шәҗәрәләр тупланган булган. Ул аларның кайберләрен үзенең «Казан ханлыгы» китабында файдалана. Мәсәлән, бу китапта китерелгән «Урдаҗ бий» шәҗәрәсе һәм XVIII гасыр башларында күчерелгән «Илаһи бәет» әсәре кулъязмалары — шуларның мисалыдыр . Кызганыч, әмма бу китапханәнең язмышы да 1918 елда фаҗига белән бетә.

Фольклорчы, драматург һәм тарихчы Фазыл Туйкин (1887—1938) Лениногорск төбәгенә караган Зәй-Каратай авылында төбәкнең борынгы язмалары белән кызыксынган. XVII йөздә яшәгән күренекле татар шагыйре Мәүла Колыйның иҗаты да беренче мәртәбә ул ачкан кулъязма китап аша 1926 елда мәгълүм булды. Моннан соңгы елларда төбәкнең язма мирасын өйрәнү фәнни-археографик экспедицияләр оештыру юлы белән бара башлый.

Кама аръягының көнчыгыш төбәкләренә беренче археографик экспедиция Казаннан 1929 елны чыга. Экспедициянең кулъязма китаплар, документлар туплау, борынгы кабер ташларын һәм аларның язулы текстларын күчереп алу эшенә атаклы татар археографы Сәйед Вахиди җитәкчелек итә. Бу вакытта галимнәр, Минзәлә кантунына кергән авылларны өйрәнеп, күп кенә кыйммәтле чыганаклар туплап кайталар. Моннан соң 1930 елда Татарстан экономика фәнни-тикшеренү институтының тел, әдәбият кабинеты тарафыннан Чаллы һәм Бөгелмә кантуннарына археографик

экспедиция оештырыла. Ул экспедиция материалларының бер өлеше Казан дәүләт университеты фәнни китапханәсенә тапшырылган .

Кызганыч ки, 1930 елдан соң Кама аръягына археографик максатлардагы фәнни экспедицияләр оештыру туктапып кала. Бу эшне анда 1960 еллардан соң күренекле археограф галим Альберт Фәтхи яңадан башлап җибәрә. Ул да, 1929 елгы экспедицияләр маршруты буенча, әүвәлдә булган Минзәлә өязе административ бүленешенә кергән төбәкләрдә йөрү эшенә керешә. Альберт Фәтхинең уздырган археографик эзләнүләре гаять кыйммәтле язма чыганаклар табу белән тәгәлләнде. Мәсәлән, Алтын Урда шагыйре Хәйдәр Хәрәзминең «Мәхзәнел-әсрар» әсәренең үтә дә сирәк кульязмасы Актаныш төбәгендә табылды һ. б. Аның тарафыннан хәзерге Актаныш, Минзәлә, Тукай, Мөслим, Зәй, Сарман районнарына кергән татар авыллары бик яхшылап өйрәнелделәр. Кызганыч ки, галим үз ачышлары турында матбугатка хәбәр бирергә һич ашыкмады, һәм аның кылган күп изге гамәлләре халыкка ирешмичә калдылар.

Татарстан Фәннәр академиясенең Әлмәт һәм гомумән Кама аръягы төбәкләренә бәйләнешле археографик экспедицияләре яңадан 1968 елдан гына башланып киттеләр.

Шушы вакыттан 1998 елгача Әлмәт һәм аңа күрше төбәкләрдә археографлардан К. Дәүләтшин, М. Юсупов, Ш. Абилов, М. Гайнеддинов, Ә. Шәрипов, М. Әхмәтҗанов, Җ. Миңнуллин, Р. Әхмәтов, Ф. Яхин һ. б. фәнни-археографик экспедицияләрдә булып, йөзләрчә кульязма китаплар һәм документлар табып кайттылар. Нәтиҗәдә урта гасырлардан алып XX гасыр башына кадәр булган тарихи дәвердән калган күп кенә кыйммәтле әдәби истәлекләр тупланды. Билгеле, ул дәвердәге әдәбият синкретик характерда булган, шунлыктан әдәбият төшенчәсенә фән дә, дин дә, матур әдәбият ядкәрләре дә кертелгән. Ләкин бу хезмәттә Әлмәт төбәгендә үскән әдәбият турында сүз алып барганда, күбрәк нәфис әдәбиятка бәйле булган истәлекләргә генә игътибар ителде.

Татарстан Фәннәр академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты каршындагы Мирасханәдә саклаучы 39 нчы коллекциядәге ядкәрләрнең күчермәләрен барлап үтик:

***Сөләйман Бакырганый*** (? — 1186):
Шигырьләр — 39 нчы коллекция, 2976 нчы эш берәмлеге.
«Ахырзаман» китабы — 39 кол. — № 25, 2690, 2832 эш бер. һ. б.
«Такый гаҗәп» — 39 кол. — № 2666, 2669, 2671, 2694 эш бер. һ. б.
«Ярты алма» китабы — 39 кол.— № 2510 эш бер. һ. б.

***Кол Гали*** (XII—XIII):
«Кыйсса-и Йосыф» — 39 кол. — № 339, 713, 714, 725, 755, 2576, 3042, 3730, 5132 эш бер. һ. б.

***Кәрдәҗи Гали*** (XIV):
«Кисекбаш» китабы — 39 кол. — № 55, 2510, 2521, 2674, 2699, 2785, 2824, 2863 эш бер. һ. б.

***Мәхмүд бине Гали әс-Сараи әл-Кердәри әл-Болгари*** (?—1360):
«Нәһҗел-фарадис» — 39 кол. — № 88 эш бер.

***Хисам Кятиб*** (XIV):
«Дастане Җөмҗөмә» — 39 кол. — № 1 эш бер.

***Хатаи Сакай*** (XIV):
«Кыйссаи Әхтәм» — 39 кол. — № 4582 эш бер. һ. б.

***Мөхәммәд Чәләби*** (XV):
«Мөхәммәдия» — 39 кол. — № 2683 эш бер. һ. б.

***Вафаи*** (XV)
«Рәүнәкыль-ислам»— 39 кол. — № 58, 2419 эш бер. һ. б.

***Өмми Камал*** (XV):
Шигырьләр — 39 кол. — № 3000, 3730 эш бер. һ. б.

***Мәүла Колый*** (XVII):
Хикмәтләр — 39 кол. — № 48 эш бер. 23 ф. һ. б.

***Лотфи*** (1366—1466):
«Гөл вә Нәүрүз» — 39 кол. — № 6042 эш бер. (ксерокопия)

***Халык китабы ядкәрләре***
«Тәгъбирнамә» — 39 кол. — № 2832 эш бер. һ. б.
«Ана белән угыл» — 39 кол. — № 2831, 2863 эш бер. һ. б.
«Кыйссаи Авык» — 39 кол. — № 2684 эш бер. һ.б.

«Кыйссаи Ибраһим» — 39 кол. — № 2701, 2786 эш бер. һ. б.

***Габди*** (1669 — ?):
Хикмәтләр — 39 кол. — № 48, 2766 эш бер.

***Габдессәлам Урай углы*** (1700 — ?):
«Илаһи бәетләр» — 39 кол. — № 5020 эш бер. һ. б.

***Габдерәхим Утыз Имәни*** (1754—1834):
Әсәрләре — 39 кол. — № 6, 44, 45, 46, 47, 133, 182, 2517, 2530, 2863, 2970, 2971, 2972, 2973, 2974, 2981, 2982, 2983, 3648, 5685, 5847 эш бер. һ. б.

***Таҗеддин бине Ялчыгол әл-Иштәки әл-Башгыри әл-Болгари*** (1768—1838):
«Рисаләи Газизә» әсәре — 39 кол.— № 2268, 2465, 3126 эш бер. һ. б.

***Әбелмәныйх Каргалый*** (1782—1833):
Шигырьләр, поэмалар — 39 кол. — № 2659 эш бер.

***Рәхимкол бине Исламкол*** (XVIII):
Шигырьләр — 39 кол. — № 48 эш бер.

***Габделҗаббар Кандалый*** (1797—1860):
Шигырьләр — 39 кол. — № 3728, 3729 эш бер. һ. б.

***Һибәтулла Салихов*** (1794—1867):
Шигырьләр — 39 кол. — № 2685 эш бер. һ. б.

***Җамаледдин Сабави*** (1780—1866):
Шигырьләр — 39 кол. — № 2680 эш бер. һ. б.

***Гали Чокрый*** (1826—1899):
Шигырьләр — 39 кол. — № 2971 эш бер.

***Әхмәтҗан Тубыли*** (1823— ?)
Шигырьләр, проза — 39 кол. — № 128, 133, 444, 445, 5169, 6058 эш бер.

Әдәби мирас болар белән генә чикләнми. Кульязмаларның нык таушалуы, битләре югалу сәбәпле, күп генә поэтик әсәрләрнең әлегә авторлары, исемнәре ачыкланмаган ядкәрләр дә күп.

Җыйналган археографик материаллар арасында татар һәм мөселман көнчыгышы әдәбиятларына кагылышлы кызыклы әсәрләр, кульязма үрнәкләре барлыгы ачылды.

Мәсәлән, 1982—1983 еллар арасында гына да Әлмәт төбәгендә «Исәгуҗи китабы» (логика фәне буенча хезмәт) — 39 кол.— № 2928; фарсыча шигырьләр — 39 кол. — № 2929; «Нәфәхат әл-өнес» (суфый өйрәтүләре) — 39 кол. — № 2930; Шәригать гыйлеме фәлсәфәсе — 39 кол. — № 2931; Гарәпчә-төркичә сүзлек, XVIII гасыр. — 39 кол. № 2951 һ. б. табылдылар.

1992 елның сентябрендә табылган кульязмалардан: «Кыйсса-и Йосыф» күчермәсе — 39 кол.— № 5132; «Тәварихе Болгария» әсәре 39 кол.— № 5148; «Кыйсса-и Сәйет Баттал гази» — 39 кол.— № 5149 һ. б. әһәмиятле.

1997 елның июль аенда табылган әсәрләрдән: Таҗеддин Ялчыголның «Тәварихе Болгария» — 39 кол.— № 4691; 1892 елда Тайсуган авылында күчерелгән «Шәрхел гакаиде Нәсефи» — 39 кол.— № 4692; Пәйгамбәрләр тарихы, татар телендә — 39 кол.— № 4694; гарәп телендә Хәдисләр — 39 кол.— № 4695; татар телендә Шәригать хөкемнәре — 39 кол.— № 4696; әхлак проблемаларына багыш- ланган поэтик әсәр фрагменты, татар телендә — 39 кол.— № 4697; гарәпчә-татарча сүзлек — 39 кол.— № 4699; татар һәм фарсы телләрендәге матур әдәбият әсәре — 39 кол.— № 4700. Шулай ук шагыйрь һәм галим Габдерәхим Утыз Имәнинең «Кәшфеллөгате... шәрхел мәүләнә Шәмседдин» хезмәте фрагменты табылды. Бу китап Шәмседдин Көһстани исемле галимнең шәригать хөкемнәре буенча язылган хезмәтенә төзелгән аңлатмалы сүзлектән гыйбарәт. Г. Утыз Имәни әлеге әсәрен Бохарада торган чорда язган. Бу әсәрнең фәнгә билгеле булган унбер күчермәсе барлыгы мәгълүм. Әсәрнең тулы күчермәсе Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Кульязмалар бүлеге мирасханәсендә саклана.

Йомгаклап әйткәндә, археографик экспедицияләр барышында, борынгы татар әдәбияты классикларының күп әсәрләре кульязмалары, шәҗәрәләр, логика, ислам фәлсәфәсе, ислам шәригате буенча хезмәтләр табылды.

Җыйналган археографик материал Кама аръягының көнчыгыш төбәгендә әдәби репертуарның гомуммилли язма мирас фондыннан аерылмаганын раслый.

# ТАРИХ ҺӘМ ӘДӘБИ МИРАС

Әдәби процессны халыкның милли тарихыннан аерып карап булмый. Шунлыктан, аңа ачыклык кертү өчен, Кама аръягы төбәгенең кыскача гына этносәяси тарихына тукталып үтәргә кирәк.

Безнең эрага кадәр бу җирләрдә скифлар, сарматлар хакимлек итә. Безнең эраның III—V гасырларында төбәк һуннар биләмәсенә әйләнә. Һуннарның Әлмәт якларында яшәгәнлегенә дәлил булып, Ык, Аксубай төбәгеннән агучы Сөнчә елгасы буенда һәм Сенбер өлкәсендә археологлар тарафыннан табылган ритуаль казаннар, Менделеев төбәгендәге Турай авылы янында табылган каберлек һ. б. ачышлар хезмәт итәләр.

Һуннардан соң Ык белән Идел арасы далаларына VI—VIII йөзләрдә Төрки каһаннары хуҗа булалар. Әлмәт төбәгендәге Түбән Абдул авылы кырындагы примитив төрки балбалы шул дәвер хатирәсе булса кирәк.

Төрки каһанат таркалганнан соң, Әлмәт ягындагы җирләргә VIII—IX йөзләрдә Иртыш буйларыннан чыккан угорлар хуҗа булып тора. Ә инде IX гасырда бу төбәккә болгарлар керә башлый. Ләкин аңа карап угорлар юкка чыкмый. Болгар дәүләтендә аларның бер өлеше мөселманлык кабул итеп, урыс елъязмаларында «бисермән» исеме белән еш кына телгә алыналар. Бисерманнәрнең кечкенә бер өлеше бүгенге көндә удмурт халкының этник группасын тәшкил итә. Угорларның XIII гасырда да мәҗүси хәлдә Кама буйларында яшәүләре 1236 елда Бүләр шәһәренә килгән венгр католик миссионерының язмаларында теркәлеп калган. Алардан калган Җурматы, Йенәй, Үсәргән исемле кабиләләр Нугай урдасы дәверендә XV—XVI гасырларда татарлашып бетәләр. Ләкин кабилә исемнәре сакланып кала. Татарлашкан Җурматы нәселенең шәҗәрә тексты Сарман төбәгендә Ф. Яхин тарафыннан табылган иде.

XII гасырларда Әлмәт төбәгенә көньяктан кыпчаклар килә. Кыпчакларның бу якларга килеп җиткәненә дәлил булып, әлегәчә сакланып калган борынгы топонимнар (мәсәлән Ык буенда Кыпчак тавы, Кызыл Кыпчак авылы) һәм Кече Урыссу авылы янында 1940—1950 елларга кадәр сакланган кыпчак балбалы һ.б. хәбәрләр тора. Кыпчакларның Саратов, Самара, Оренбург, Чиләбе өлкәләре далаларында XVIII—XIX гасырларда да әле таш балбаллары күп сакланган була. Аларны бу җирләргә соңгы гасырларда күчеп килгән халыклар дошманлык белән ватып бетерәләр, хуҗалыкларында төзелеш материалы итеп файдаланалар.

Болгар дәүләтен 1236—1237 елларда Батый хан җитәкчелегендә хәзерге Казахстан һәм Урта Азия далаларында V—VI гасырлардан бирле яшәгән, мөселманлык кабул иткән татарлар яулап ала. Урта Азиядә аларның бер өлеше күчмә тормыш алып барган, икенчеләре Хәрәзм һәм Төркестан шәһәрләрендә яшәгән булганнар.

Батый хан 1243 елны Алтын Урда дәүләтен төзеп, башкала итеп Болгар шәһәрен сайлый. Татарларның бер өлеше Болгар, Җүкәтау шәһәрендә торып калалар, алар өчен бу яклардагы далалар ватанга әйләнә; татарлар төньякта Пермь һәм Вятка тирәләренә кадәр барып урнашалар. Алар әүвәлге Болгар дәүләтенең халкын кырып бетермәгәннәр һәм кысрыклап та чыгармаганнар. Болгарлар үзләренең төп регионнарында XIV гасырның 60 нчы елларына кадәр яшиләр, ләкин интенсив татарлашу процессын кичерәләр. Алардан көньякка һәм көнчыгышка таба булган җирләргә нигездә татар кабиләләре килеп урнашканнар.

Алтын Урда дәүләтен төзегән татарлар монда Урта Азиядәге Караханилар дәүләтендә һәм Хәрәзмдә иҗат ителгән үз мәдәниятләрен, әдәбиятларын, сәнгатьләрен, архитектура, техника казанышларын тагын да үстерә башлыйлар. Алар килгәнче, Болгар илендә ак ташлардан зур шәһәрләр салу гадәте булмый, хәтта таштан ясалган эпиграфик истәлекләрнең традициясен дә татарлар Караханилар дәүләтеннән алып киләләр. XI—XIII гасырларда Караханилар дәүләтендә, Хәрәзмдә яшәгән һәм иҗат иткән Йосыф Баласагуни, Әхмәт Йүгнәки, Әхмәт Йәсәви, Сөләйман Бакырганый, Кол Гали кебек шагыйрьләрнең әсәрләрен дә Идел буена татарлар алып килә. Әлеге шагыйрьләрнең иҗаты Алтын Урда татар әдәбиятының нигез ташын тәшкил итәләр. Хәтта XIII гасыр ахыры— XIV гасыр башында Хәрәзмдә иҗат иткән Насреддин Рабгузи, соңрак Хәрәзми, Хәйдәр Хәрәзми кебек шагыйрьләр дә, үз итеп, бу дәүләткә нисбәтле санап, әсәрләрен татар ханнарына (мәсәлән Үзбәк ханга) багышлаганнар.

XIII гасырда Батый хан кул астындагы татарлар бу якларга чәчәнлек традициясен дә алып киләләр. «Дастане Чынгызхан», «Алпамыш», «Кузы Күрпәч белән Баян Сылу», «Түләк белән Сусылу» һәм соңыннан барлыкка килгән «Идегәй», «Чура батыр» һ. б. дастаннар шушы традиция нигезендә иҗат ителгән татар мирасы булып торалар. Татарларның чәчәнлек иҗаты соңрак Нугай урдасы дәүләте чорында чәчәк ата. Бу чорлардан мираслары нугай, казах, кыргыз, каракалпак фольклорында сакланган чәчәннәрнең (Субра җырау, Асан Кайгу, Дусмәмбәт җырау, Чалкыяз

җырау һ. б.) исемнәре мәгълүм. Нугай урдасында иҗат иткән бу чәчәннәрнең әсәрләрен нугай, казах, кыргыз, каракалпак халыкларының этник тарихларына катнашкан татар кабиләләре, татар ырулары вәкилләре әлеге халыкларга таратканнар.

Югарыда искә алынган дастаннардан «Түләк белән Сусылу», «Кузы Күрпәч белән Баян Сылу», «Алпамыш», «Идегәй» һ. б. Әлмәт төбәгенә күрше булган төбәкләрдән язылып алыну очраклары мәгълүм. Төбәктә чәчәнлек традициясе XX гасыр ахырына кадәр сакланып килгән.

Алтын Урда, үзенең төзелү көненнән башлап, утраклыкка юнәлеш тоткан дәүләт була. Анда интенсив рәвештә шәһәрләр салына. Археологиягә караган хезмәтләрдә XIV гасырда анда 170 тән артык шәһәр исәпләнә. Алтын Урда Европага иң яхшы сыйфатлы ашлык, терлекләр чыгара. Анда йөзләгән керамика мастерской-лары, таш карьерлары, чуен кою мичләре, елга транспорты, затлы металлар, агач эшкәртү, балык тоту, күн иләү, сәүдә юллары салу алга киткән һәм бөтен Көнчыгыш Европаның экономикасын тотрыклы хәлдә тоткан акча системасы булган.

Бөтен Алтын Урда дәүләтендә татар этносы төп көч була. Аның составына әүвәлдә мөстәкыйль булып яшәгән болгарлар, кыпчаклар, угызлар 1360 елларга кадәр кушылып бетәләр. Үз телләрен югалткан аз санлы әрмәннәр, греклар, генуэзлылар, яһүдиләр, татар теленә күчсәләр дә, этнос составына кермәгәннәр.

Туктамыш хан җитәкчелегендәге Алтын Урда татар дәүләте Урта Азиядән чыккан әмир Аксак Тимер һәм аңа хезмәткә күчкән Идегәй мангыт гаскәрләре тарафыннан 1395 елда җимерелә. Аксак Тимер бөтен татар илен суеп, шәһәрләрен җир белән тигезләп вәхшилек эшли. Бу җиңелүдән татарларның куәте нык кими, Алтын Урда мәйданында Казан, Олы Урда, Хаҗи Тархан, Кырым, Себер, Нугай урдасы ханлыклары оешуга җирлек салына. Алар арасында Аксак Тимер кыргыныннан чагыштырмача кимрәк зыян күргән күчмә татарлар дәүләте — Нугай урдасы — зурлыгы һәм көче белән аерылып торган. Нугай урдасы сугышларга өчәр йөз меңгә җиткән атлы гаскәр куя алган, ләкин аларның корал ягы бик зәгыйфь була. Ул үзенең күршесе булган Казан ханлыгы белән икътисади, сәяси, этник тамырлар аша нык бәйләнә. Казан ханлыгында Нугай урдасы биләре зур дәүләт чиновниклары, гаскәри җитәкчеләр һ. б. булып торганнар. Казанда яшәгән морзаларның Агыйдел, Зәй, Ык елгалары буйларында күпсанлы кардәшләре булган. Бу фактлар шәҗәрә материаллары белән дә раслана.

Әлмәт төбәге (бүгенге Татарстанның Кама елгасы сул ягындагы барлык җирләр) XV—XVII гасыр урталарына кадәр Нугай урдасының төп биләмәләре булып саналган. Бу дәүләтнең халкы Кама аръягының бөтен якларында да, урда җимерелгәч тә сакланып, яшәп кала. Шунлыктан Нугай урдасының әдәби чәчәнлек мирасында бөтен Кама аръягы халкының хакы бар.

Тарихта Нугай урдасы хакиме Йосыф мирзаның 1549 елның июнендә Мәскәү князе Иван IV гә язган хаты сакланган. Хатта Казаннан Мәскәүгә дипломатик миссия белән барган Мөхәммәдьяр исемле тылмачның язмышы турында ачыклык кертү сорала. Иван IV, шул ук елның август башларында язган хатында, Мөхәммәдьярның Муром шәһәрендә үтерелүен хәбәр итә. Йосыф морза гади бер тәрҗемәче язмышы белән кызыксынып та тормас иде: Мөхәммәдьяр аның якын кешеләреннән берсе булган. Бу — Мөхәммәдьяр белән Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдьяр бер үк кеше булганнар дигән фикер [1] — татар әдәбияты тарихында шактый ныгып бара [2]. Әүвәлге Нугай урдасы биләмәләре булган Ык елгасы буендагы татар авылларында таралган Шәех Дирбеш шәҗәрәсе күчермәләре, үзенең атаклы суфыйлар, хаҗилар нәселе булуы һәм анда Йар-Мөхәммәд исеме булуы белән, шагыйрь Мөхәммәдьяр нәселенә нисбәтле түгел микән дигән фикер уята.

Нугай урдасы XVII гасырның урталарында күршеләренең мәкерле эшләре һәм аларга ялланган Калмык урдасының, Темников татарларының өзлексез барган канлы һөҗүмнәре аркасында җимерелә. Аның җирләрен күршеләре төрле яклап үзләштерә башлыйлар. Кама аръягы төбәгенә дә калмыкларның баскынлык һөҗүмнәре зур зыян китергән.

Шушы шартларда, 1640 еллардан Каманың уң як ярындагы һәм Иделнең Тау ягындагы татарлар әүвәлге Нугай урдасы җирләренә күчеп утыра башлыйлар. Анда авыллар барлыкка килә. XVII гасырның урталарында Мәскәү кенәзлеге, Нугай урдасы җирләрен колонизацияләү максатында, Кама аръягы ныгытмалары чылбырын корырга керешә. Бу ныгытмаларның беренче рәте Сенбердән Минзәләгә кадәр, икенчесе — аннан көньяктанрак үтә. Аларга әүвәле — татарларны, соңрак урыс, чуваш, мукшы крестьяннарын күчереп утырталар.

Шушы дәвердән Кама аръягында (шул исәптән Әлмәт төбәгендә дә) татар әдәбияты үсешенең яңа дәвере башлана.

## МОНДА ГЫЙРФАН, МОНДА НУР...

Әлбәттә, әдәби һәм мәдәни тормыш учагы яңадан дөрләп китсен өчен төбәктә укый-яза белгән, мәдрәсәләре эшләгән җәмәгатьчелек нигезләре торгызылырга тиеш. Шундый җәмәгатьчелек үзәкләре буларак, Бүләр шәһәре җимерекләре янына XVII гасыр урталарында Казан—Лаеш тирәсендәге татар авылларыннан күчереп утыртылган Балынгуз тавындагы халык тора. Алар, Балынгуз тавындагы изге каберләрне карап, төзәтеп тору сылтавы белән, тауда авыл корганнар.

Ләкин алар 1667—1671 елгы крестьяннар сугышы вакытында ни сәбәптәндер кырылып бетәләр. Бүләргә 1678 елда татарларның бер төркеме яңадан күченеп килә.

Аларга җитәкче булып хәзерге Татарстанның Питрәч төбәге- нә караган Чыты авылыннан чыккан Бәйрәмгали Колаев исемле йомышлы татар торган. Аның халык телендәге кыскартылган исеме Бимкә суфый дип йөртелүе ачыкланды. Бәйрәмгали Колаевның шәхесе шагыйрь Мәүла Колый шәхесенә туры килә. Без аларны бер үк кеше булганнар дигән фикергә килдек [1].

Патша администрациясе Бимкә суфый җитәкчелегендәге мөселман татар общинасын Бүләр шәһәре җимерекләре яныннан куып җибәрү чарасын күреп, 1699 елда бу теләгенә ирешә. Бүләрдәге татарлар Чирмешән, Шушма елгалары буйларындагы татар авылларына нигез салып, яңа урыннарда яши башлыйлар. Болар рәтеннән Кизләү, Сарабиккол (Әби), Иштирәк авылларының исемнәрен күрсәтергә мөмкин. Шушы өч авылны Кама аръягында суфыйчылык үзәкләре булганнар дип санарга нигез бар. Ни өчен дигәндә, археографик экспедицияләр вакытында табылган суфыйлар силсиләләрендә еш кына «Кизләви» һ. б. тәхәллүсле ишаннарның исемнәре күзгә еш ташлана [1]. Сарабиккол авылында Бимкә суфый шәҗәрәсенең XVIII йөз күчермәләре дә шактый санда табылды [2].

Бимкә суфый — Бәйрәмгали Колаев, яки Мәүла Колыйның шигырьләрендә суфыйлык фикерләренең күплеге күзгә ташлана. Әлеге фикерләрнең эчтәлеге татар мөселманнарда үткән буынга, алардан калган истәлекләргә, ата-анага хөрмәт тәрбияләү, аларны онытмауны максатка ярашлы итүдән гыйбарәт. Адәмнәрнең күңелләренә изге тойгы-хисләр, яшәүгә, тормышка сабырлык белән карау фикерләре үткәрелә. Ата-анага баланың каршы әйтүен гаепләү, аларны ата-ана каргышы белән кисәтү, ата-ана ризалыгын Хак ризасы белән тиңләү чагыла.

Мәүла Колый әсәрләрендә тормыш, табигать күренешләре дә тасвирлана. Дөньяви эшләрдән игенчелек эшен мактау, яз килешенә шатлык, тарихи һәйкәлләрне торгызучыларга теләктәшлек һ. б. сурәтләнә.

Шагыйрь Мәүла Колыйның иҗаты бөтен татар дөньясына диярлек мәгълүм була. Археографик экспедицияләр вакытында аның хикмәтләре, поэмалары язылган кулъязмалар Татарстанның Норлат, Яшел Үзән, Әгерҗе, Лениногорск, Башкортстанның Бакалы төбәкләрендә һ. б. урыннарда табылдылар [3].

Мәүла Колыйның иҗаты аннан соңгы татар шагыйрьләренең иҗатларына да тәэсир ясаган. Мәсәлән, XVIII йөзнең икенче яртысы — XIX йөзнең беренче чирегендә яшәгән татар шагыйре Колмөхәммәднең әсәрләрендә аның әхлак темасына караган фикерләре, хәтта ки аерым шигъри юллары еш очравы шул хакта сөйли.

XVII гасырда Кама аръягында игенчелек белән көн итүче татар авыллары арта бара.

Шуның белән бергә, аларда мәдрәсәләр дә ачыла башлый. Әлегә безгә, кайбер документлар буенча, XVII гасырның соңгы чирегендә Минзәлә төбәгенең Шыгай, Ютазы төбәгенең Бәйрәкә авылларында мәдрәсәләр булуы мәгълүм. XVIII гасырга кергәч, Азнакай төбәгендә Чалпы, Әлмәт төбәгендә Тайсуган, Норлат төбәгендәге Кизләү (Корманай) авылларында мәдрәсәләр булганлыкка хәбәрләр бар.

Тайсуган авылындагы мәдрәсәнең мөдәррисе булып шагыйрь һәм дин галиме Габдерахман (1690—1753) торган. Габдерахман, озак еллар укып йөреп, Тайсуган авылына килеп урнаша. Аның 1140 ел һиҗри, 1728 ел румида 38 яшендә язган «Касыйдә»се сакланган [1].

«Васыятьнамә» дини темага, шигырь белән язылган. Анда Мөхәммәд пәйгамбәрнең күрсәткән могҗизалары бәян ителә. Аның эчтәлегеннән Габдерахман Тайсуганиның ислам дине гыйлемен тирән өйрәнгән бер шәхес икәнлеге күренә. (Аның мәдрәсәсендә атаклы татар публицисты, азатлык хәрәкәте җитәкчесе Батырша Алиев та укыган булган.) Әсәрнең теле гаять авыр, гарәп-фарсы сүзләре белән чуарланган.

Кизләү мәдрәсәсе мөдәррисе Гобәйдулла Болгариның да ка- ләм мирасы калган. Аның тарафыннан 1726 елда, мәдрәсәләрдә файдалану өчен, гарәп теле грамматикасын тасвирлап, фарсы телендә «Гавамил китабы» язылган. Фәнни китапханәләрдә аның берничә кулъязмасы саклана [2].

Кама аръягында һәм Әлмәт төбәгендә XVIII гасырда Рәхимкол бине Исламкол, Рәхимкол

Әбүбәкер улы, Таҗеддин Ялчыголов, Габдерәхим Утыз Имәни, Әшрәф улы Руми, Габделмәннан Мөслим улы, Габделҗәлил Габделмәннан улы, Габделҗәлил бине Ишмөхәммәд әл-Болгари (1797 елда вафат), Таҗеддин Иштирәки кебек күп кенә шагыйрь, филолог, юрист, дин галимнәре һ. б. иҗат кешеләренең исемнәре, әсәрләре үрнәкләре сакланып калган. Бу әсәрләрнең зур өлеше Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Мирасханәсендәге борынгы кульязмалар коллекциясендә сакланалар. Шагыйрь-галимнәрнең хезмәтләре хакындагы кайбер мәгълүматлар Әлмәт төбәгеннән чыккан татар галиме һәм язучысы Ризаэддин бине Фәхреддиннең «Асар» исемле зур хезмәтендә теркәлгән. Шулай ук икенче бер татар галиме Мөхәммәт Гали тарафыннан иске кульязмалардан кыйммәтле мәгълүматлар табып бастырылган [1]. XVIII гасырның күренекле вакыйгаларыннан булган Акай исеме белән бәйле азатлык сугышы хакында татар телендә тарихи хикәят булып, аның кыскартылган урысча тәрҗемәсе генә сакланган [2].

XVIII гасырда Әлмәт төбәгендә укымышлы кешеләр аз булмаган. Пугачев кузгалышы вакытында баш күтәрүчеләрдән калган йөзләрчә документлар татар халкының аек акыл һәм иҗат киеренкелеге белән яшәгәнлеген сөйлиләр. Ул гасырның соңгы чирегендә күчерелгән яки яңадан иҗат ителгән кульязма календарь үрнәкләре халык арасында астрономиядән, математикадан, медицинадан, дин гыйлеменнән, тарихтан, табигать белеменнән үз дәвере өчен зур укымышлы галимнәрнең яшәгәнлегенә дәлил булып хезмәт итәләр.

Кызыклы календарьлардан Азнакай төбәге Митрәй авылында табылган кульязма җыентыкны искә алырга мөмкин. Ул җыентыкта борынгы хайван исемнәре белән йөртелгән унике еллык календарь һәм аның фалнамәсе китерелә. Аның тулы тексты матбугатта чыгарылды [3]. Әлеге календарь татар халкының иң иске әдәби ядкәрләреннән санала. Алар бабаларыбызның безнең эрага кадәр үк югары цивилизацияләр белән бәйләнгәнлеген раслый торган уникаль әдәби чыганаклар булып та саналалар.

Митрәй авылында 1783—1799 еллар өчен төзелгән бай куль-язма календарь да табылган иде [4]. Мондый истәлекләр Лениногорск төбәгенең Иске Иштирәк [5], Ютазы төбәгенең Кече Урыссу [6], Азнакай төбәгенең Балтач [7], Лениногорск төбәге Иске Шөгер [8] авылларында һ. б. җирләрдә уздырылган археографик экспедицияләр барышында табылып, фәнни әйләнешкә кердeләр.

Календарьлар белән янәшә, кульязмаларда йолдызнамәләр, төш тәгъбирләре, төрле ырым-дәва догалары да теркәлеп килгән. Аларда татар халкының образлы тасвирлары, фикри фантазиясе, мифология элементлары чагылыш ала. Әлеге әдәби жанрлар бик ерак гасырлардан бирле сакланып, баетылып килгән тарихи-әдәби истәлекләр булып саналалар. Аларның мисаллары алда искә алынган Митрәй авылыннан табылган кульязма җыентыкта тупланганнар [1].

Татар халкында кульязма календарьлар төзү XIX гасыр ахырынача бара, аларны күчереп язу очракларын исә XX гасырның икенче яртысында да очратырга мөмкин булды. Әлмәт һәм аңа якын төбәкләрдә табылган кульязма календарьлар материалына караганда, татар халкы, XIX гасырның икенче яртысына кадәр борынгы хайван исемнәре белән йөртелгән милли календарьдан тыш, юнан (грек), урыс (григориан), сирияни (кояш), гарәби (ай), гарәби (кояш), фарсы (кояш) календарь системалары белән таныш булган. Сарабиккол авылында 1870 елларда төзелгән кульязма календарьда биш төрле календарь системасы чагыштырма таблицасы тасвирлана [2].

Төбәктә тарихи хроникалар төзүчеләр дә булган. Мәсәлән, Сарман ягындагы Шыгай авылы имамы Борһанеддин бине мулла Шәриф (1766—1827) тарафыннан төзелгән тарихи хроника Ризаэддин бине Фәхреддин тарафыннан табылып, «Асар» китабында аннан бер өзек китерелә [3]. Мондый хроникаларның берсе Нигъмәтулла Мәүлекәй улы (1785—1834) тарафыннан Азнакай төбәге Митрәй авылында төзелгән [4]. Аның хроникасы бик үзенчәлекле, кыйммәтле фактлары күп.

XVIII—XIX гасырлардан калган кульязмалар арасында тыйб гыйльменең фармакология тармагына багышланганнары да табылды. Мәсәлән, Азнакай төбәге Митрәй (39 кол.— № 2337 эш бер.), Сарлы (39 кол.— № 2299 эш бер.— фармакология), Мәсгут (39 кол.— № 2473, 2475, 2478 эш бер.), Лениногорск төбәге Болгар (39 кол.— № 2662 эш бер.), Ормышлы (39 кол.— № 2663 эш бер.) һ. б. авыллардан нигездә фармакология, гипноз методы белән дәвалау кулланмаларының XVIII—XIX гасырда эшләнгән кульязмалары табылды.

XVIII—XIX йөзләрдә Әлмәт һәм аңа күрше төбәкләрдә татар авыллары зураеп китеп, анда мәгърифәт һәм мәдәният тә үсә. Мирасханәләргә кергән кульязмаларда аларның кайсы авыл мәдрәсәсендә, кайсы елда һәм кем тарафыннан күчерелүе хакында да кызыклы хәбәрләр саклана. Мәсәлән:

1. Минзәлә төбәге Аю авылы — XIX йөздә мелла Кашшафеддин бине Хөсәен әл-Аюви тарафыннан күчерелгән «Нәхү» китабы (гарәп теле синтаксисы).— Мирасханә: 39 кол.— № 3093

эш бер.

2. Азнакай төбәге Чубар Абдул авылында 1846 елда мелла Габидулла бине Моратай мәдрәсәсендә күчерелгән әсәр.— Мирасханә: 39 кол.— № 2629 эш бер.

3. Актаныш төбәге Такталачык авылында 1775 елда дамелла Хәмид бине Габдулла мәдрәсәсендә күчерелгән кулъязма «Хәдис».—Мирасханә: 39 кол.— № 669 эш бер.

4. Әлмәт төбәге Тайсуган авылында 1766 елда Габделмәннан мәдрәсәсендә күчерелгән әсәр.— Мирасханә: 39 кол.— № 2561 эш бер.

5. Лениногорск төбәге Зәй-Каратай авылында 1853 елда Фәхреддин мәдрәсәсендә Минһаҗеддин бине Ильяс әл-Болгари күчергән кулъязма. — Мирасханә: 39 кол. — № 5548 эш бер.

1905 елда Зәй-Каратайда дамелла Җамаледдин бине дамелла Нигъмәтулла мәдрәсәсендә күчерелгән кулъязма. — Мирасханә: 39 кол. — № 2831 эш бер.

6. Лениногорск төбәге Зәй-Каратай авылында остаз Гыйрфан бине дамелла Габделмөэмин мәдрәсәсендә 1871 елда Җәлаледдин бине Габделгафур әл-Ормышлый тарафыннан күчерелгән кулъязма. — Мирасханә: 39 кол. — № 2886 эш бер.; Каратай авылында 1883 елда Җамаледдин бине Ногман әл-Каратай язган кулъязмалар. —Мирасханә: 39 кол. — № 3024, 3222 эш бер.

7. Лениногорск төбәге Сарабиккол (Әби) авылында дамелла Җамаледдин бине мелла Ногман әл-Каратаи Самари әл-Әбеви мәдрәсәсендә Габдерәхим бине Сөләйман әл-Әбеви күчергән «Сарыф» китабы (морфология). — Мирасханә: 39 кол.— № 3033 эш бер.; Әби авылында 1909 елда дамелла Җамаледдин мәдрәсәсендә күчерелгән әсәр.— Мирасханә: 39 кол.— № 3026 эш бер. 1910 елда Җамаледдин бине Ногман бине Каратаи мәдрәсәсендә Миңлебай бине Җәлаледдин күчергән хәдисләр.— Мирасханә: 39 кол.— № 3028 эш бер.

8. Лениногорск төбәге Түбән Чыршылы (Чәшеле) авылында 1879 елда Габделфәттах бине Габделкаюм мәдрәсәсендә күчерелгән «Төхфәтел-мөлек» китабы. — Мирасханә, 39 кол. — № 3849 эш бер.

9. Сарман төбәге Мортышбаш авылында 1828 елда дамелла Габделхәлим бине Зәйнелгабидин мәдрәсәсендә Хәмидулла бине әл-Зөбәйер әл-Болгари тарафыннан күчереп төгәлләнгән, 314 кәгазьдән торган шәригать китабы.— Мирасханә: 39 кол.— № 3943 эш бер.

10. Минзәлә төбәге Мортыш авылында дамелла Габделгафур бине мелла Сәйфулла әл-Мортыши мәдрәсәсендә 1819 ел, апрель аенда Габделлатыйф бине Сәйфулла күчергән кулъязма.— Мирасханә: 39 кол. — № 642 эш бер.

11. Сарман төбәге Шыгай авылында 1791 елда мелла Борһанеддин бине Мөхәммәдшәриф мәдрәсәсендә күчерелгән шәригать китабы, күчерүче Төхфәтулла бине Мөхәммәдьяр. — Мирасханә: 39 кол. — № 3850 эш бер.

12. Түбән Кама төбәге Кызыл Чапчак (Кыпчак) авылында 1811 елның 5 мартында Таҗеддин бине Ялчыгол мәдрәсәсендә Искәндәр бине Мөрсәлим күчергән «Мохтәсәрел-вәкая» кулъязмасы.— Мирасханә: 39 кол. — № 2649 эш бер.

Әлбәттә, бу исемлекне тагын да дәвам итәргә мөмкин.

Егерменче гасырның башларына кадәрле булган төбәк әдәбиятын тулырак күз алдына китерү өчен, аны тудыру юлында эшләгән каләм ияләренең тормыш һәм иҗатына киңрәк тукталып үтү кирәк булыр. Түбәндә без татар халык китабы ядкәрләре үрнәкләре һәм тарихта мәгълүм булган каләм осталары белән таныштырып үтәбез. Алар язма әдәбиятның ерак тамырлары белән бәйләнгән һәм халык тарихында җуелмаслык эз калдырганнар.

## ХАЛЫК КИТАБЫ ЯДКӘРЛӘРЕ

Татар кулъязма китаплары арасында чын мәгънәсендә халык китабына әйләнгән әдәби әсәрләр һәм алардан төзелгән җыентыклар бар. Аларның күбесенең инде авторлары да онытылып беткән. Шундый китаплардан «Йосыф китабы», «Бакырган китабы», «Ярты алма», «Бәдәвам», «Кисекбаш» һ. б. әйтергә була. Укучыларга тәкъдим ителә торган «Авык китабы» тексты да шундый җыентыкларның берсеннән алынды, аның авторы күрсәтелмәгән.

### Китабе авык

Кяфер биге авык аулап килер иде,
Сәвеклек рәсүл йул узыр торыр иде.

Кырык кяфер терек авык [1] тотмыш иде,
Мөхәммәдкә авык зари кылыр имди.

Рәсүл торып кяферләргә каршы килде,
Кырык кяфер Мөхәммәдкә сәлам кылды,
Кырык кяфернең сәламен Мөхәммәд алды,
Агъзын ачып, рәсүл авыкны теләр имди.

Кяфер әйтер, кырык ир берлән ау ауласам,
Бу көн үзем тагъдин тагъга аша йөрсәм,
Кырык ир берлән ау аулап йалгыз килсәм,
Нитәк бирәм бу авыкны, әйтер имди.
Рәсүл әйтер, бу авыкны мәңа сатгыл!
Алтын-көмеш кирәк булса, мәндин алгыл!
Ушпу зәгыйфә авыкны мәңа биргел!
Кяфер торып шунда җавап бирер имди.

Әйтер, моны мәндин нә өчен теләйерсен,
Нә монча моның өчен канатланырсын.
Канын алып җадаулыкларны әйләйерсен,
Тугъры сүзләп моны сәңа бирәм имди!

Рәсүл әйтер, бу кийекне үлтермәсмен,
Канын алып җадаулыклар әйләмәсмен,
Бу авыкны үзем өчен теләмәсмен,
Авык моңа кәндү разин [2] әйтер имди.

Кяфер әйтер, мәңа ни өчен разин әйтмәс,
Кырык ир маның [3] өнене һич ишетмәс.
Җиһан халкы барча моның телен белмәс,
Мөхәммәдне йалганчы дип сүгәр имди.

Рәсүл әйтер, ушпу авык мәңа сүзләр,
Күңелендәге разин мәңа ачар,
Әйтер, мәним үҗ кечек балачагым бар,
Үксез калды балаларым, әйтер имди.

Авык әйтер, көндә тагъга чыкар ирдем,
Төрлек-төрлек чәчәкләрне утлар ирдем,
Кичә килеп балаларым имезер ирдем,
Бүген килеп бу бәлагә төштем имди.

Рәсүл әйтер, казгырырмын бу авкыйга,
Тагъда калмыш үҗ кечек балаларга,
Аның өчен йалбарырмын сез кяфергә,
Рәхим кылгыл, мән шәфәгать кылам имди.
Кяфер әйтер, әгәр рәхимең килер ирсә,
Ушпу авык сәңа байык[1] сүзләр ирсә,
Разин ачып сәндин хаҗәт теләр ирсә,
Сән буйыңа йөккә бу авыкга кылгыл имди!

Без тора итү, ушпу авык әвенә китсен,
Балаларын имездин соң кайыра килсен,
Килмәз ирсә, ушпу сүзнең булсын,
Кырык ир берлән сәңа икърар кылам имди!

Авык барып килерене үзем күрәм,

Пәйгамбәрлек сәңа ирмеш байык беләм,
Килмәз ирсә, кылыч берлә башың кисәм,
Рәсүл берлә буйлә вәгъдә кылыр имди.

Рәсүл әйтер, бу авыкга мән барайын,
Йире кайда, йорты кайда — мән беләйен,
Качан барып килерене мән беләйен,
Танык булып буйым йөккә кылам имди.

Кяфер әйтер, йа Мөхәммәд, моны аңла,
Төгәл байык сорагыл имди бу авыкга:
Ничәгә тигре ултыргаймыз ушпу йирдә,
Килер вактын әйтү биргел! — беләм имди.

Рәсүл әйтер, йа авык, йирең кайда?
Качан барып килерсен кайыра монда?
Ничәгә тигре ултыргаймыз ушпу йирдә?
Мәлгунь кяфер канны хаҗәт кылыр имди.

Фәсыйх 2 телен ачып авык сүзләр,
Авыкның сүзләрен рәсүл аңлар,
Бу ике сүзләдедекен кяфер таңлар,
Авык анда килер вәгъдә бирер имди.
Авык ул дәм күзен текәп күккә бакар,
Күккә бакып зәвал 1 вакыт булмыш күрер,
Кайыра бакып рәсүл таба мондагъ сүзләр,
Икендегә тигре кайыра киләм, тийер имди.

Тәркин барып балаларым мән йөзен күрәм,
Күкрәмдәге үзем сөтем берлә имезәм.
Андин торып, сәни таба тәркин киләм.
Рәсүл әйтер, ушымән танык булдым имди!

Атдин төшең, бераз монда ултырайың,
Бу авыкны, килен шишең, коткарайың,
Һәрни кем Алла кашындин бизари 2,
Кяфер торып кылыч тартып торыр имди.

Әйтер, бу көн без тилеләрне алдайырсән,
Офтанмайын мондагъ йалган сүзләйүрсән,
Әлемездин 3 бу кийекне коткарырсән,
Кийек безгә кәндү качан килер имди?

Рәсүл әйтер, ушпу авык бардыкында,
Мән икенде намазны кылыр вакытда.
Көн күләгәне ике почык булдыгында,
Килмәс ирсә, мәне мондагъ үлтер имди.

Авык йөзен йиргә орды рәсүл таба,
Йулга керде имди китәр эве таба,
Бу кырык кяфер багып көләр биге таба,
Мөхәммәдкә әҗәл килде, әйтерләр имди.

Торып-торып йау кяферләр киңәштеләр,
Биге берлән үз теленчә сүзләштеләр,
Барып анда тозак кораның, дийешделәр,
Килер иркән, ул тозакга эленер имди.

Кирәк кем, бу Мөхәммәд җадау булгай,
Җадаулыкдин Мөхәммәдкә кире килгәй,
Андин килеп ушпу безгә зәхмәт биргәй,
Сәңа айгай, кил, мөселман булгыл имди!

Кяферләрдин икәкүси торды, барды,
Бер тагъда бу авыкның йулын күрде,
Ике тагъның арасында тозак корды,
Килер иркән ул тозакга эленер имди.

Йарлы авык эве таба барыр ирде,
Балачыклар анасыга каршы килде,
Мескен авык балаларын йөзен үпте,
Зарый кылып, йарлы авык йыгълар имди.

Авык әйтер, тәркин имең балаларым,
Исән калың мәндин имди кузыйларым,
Халикъ баксын сезне имди үксезләрем,
Мәнем көнем мәңа байык булмыш имди.

Йа Раббе, тийү күкә бакып иңрәшделәр,
Ни кылам бу хәлдә, әйтешделәр,
Хәддин изенгә йа иннә әйтешделәр,
Йыгъламакдин ике күзе күрмәс имди.

Авык әйтер, кяферләргә тоткын булдым,
Сезнең өчен Мөхәммәдне йөккә куйдым,
Мән икенде намазында киләм, тидем,
Икеләнермен тәркин имең балаларым.

Ойатлыг булдың Мөхәммәдкә, хата кылдың,
Безнең өчен Мөхәммәдне йөккә куйдың,
Сәнең сөтең һич кирәкмәс безгә, куйың,
Икеләнерсең, кайыра янына баргыл имди.

Йарлы авык кайыра барды рәсүл таба,
Ул мескиннең күзе күңле эве таба,
Ирексез килеп ул тозакга төште,
Зарый кылып йарлы авык йыгълар имди.
Торып-торып бу кяферлар күләгә үлчәр,
Очдыкы көн ике почык булмыш күрер,
Моны күреп кяферләрнең эче пошар,
Төгәл кяфер кылыч тартып торыр имди.

Андин торып рәсүлулла күккә бакар,
Күккә бакып намаз вакты булмыш күрер,
Андин торып ике рәкәгать намаз үтәр,
Мәгәр авык аңа тигрек килгән имди.

Ике рәкәгать әттәхийәткә  ултырыр,
Ул җәлилдин  Җәбраилгә  фәрман килер.
Ул кыйаны авык берлә итең, диде,
Мәндин сәлам Мөхәммәдкә айгыл имди.

Дәр сәгатьтә ул Җәбраил хазир булды,
Ул кыйаны авык берлә алып килде,
Килеп рәсүл уңында кул бирде,
Рәсүл йөзен күреп авык йыгълар имди.

Авык әйтер, ойатлыйг булдым, хата кылдым,
Сән икенде намаздан киләм тидем;
Бу кяферлар тозак кормыш, аңа төштем,
Мәндин дүгел бу кичмәкү вә иннә имди.

Моны күреп бу кяферләр табышдылар,
Андин торып шәһиде халкый төгәл кердем,
Моны күреп ун бең җәһүд мөселман булды,
Төгәл кяфер шәһәдәткә килер имди.

* * *

Борынгы әдәбиятыбызның кульъязмалар битләрендә генә сакланып калган үрнәкләре арасында «Ана белән угыл» әсәре текстлары да бар. Әлеге әсәрнең исеме фәнни әдәбиятта искә алынгалап килә инде, ләкин аның кайчан язылган булуы, теле хакында нигезле фикерләр күренми. Әдәбият һәм фольклор галиме Марсель Бакиров бу әсәрне Болгар чорында, болгар әдәби телендә язылган дигән фикерне алга сөрә. Бу фикерне заманында борынгы әдәбият белгече Зәйнәп ханым Максудова беренче мәртәбә әйткән иде. Әлбәттә, бу ике тикшерүченең чыганаклар белән эшләгәндә бәйләнешләре булган, чөнки Марсель әфәнде Бакиров дастан текстын Зәйнәп Максудова укылышында файдалана. Соңгысы исә дастанда очраган берничә сүзне болгар теле үзенчәлеге сакланган чуваш телендә бар ди, һәм аларны чуваш теле орфографиясенә яраклаштырып укыганы сизелә. Ул укыган сүзләрдән *имди, хәләш, келәч, сил, чәвүр* кебекләр «болгаризм» ягъни «чувашизм»нар дип бәяләнә. Болардан тыш М. Бакиров китергән мисалда *угъланчухи* дип дөрес укылмаган *угланчыкы* сүзен дә әлеге исемлеккә өстәргә мөмкин булыр иде. Әлбәттә, әлеге сүзләрнең берсен дә «болгаризм» яки «чувашизм» белән бәйләп булмый, хәтта *сил* сүзе чувашта сакланган, ул «сөртү»не белдерә дигән фикер белән дә килешеп булмый: чувашлар сөртүне *шәл* дип әйтәләр.

Зәйнәп ханым Максудованың Сөләйман Чәләби исемле XV гасыр төрек шагыйренең «Дастане могъҗизат» әсәрен Дауд әс-Саксини әс-Сиварига нисбәтләве, Казан ханлыгында татар теленә тәрҗемә ителгән «Кәлилә вә Димнә» исемле әсәр текстындагы чыгыш килеш кушымчалары -*зан* ны -*ран* дип чувашчалап уку тәҗрибәләре заманында мәгълүм иде. Шунлыктан дөрес укылмаган сүзләргә таянып кына «Ана белән угыл» дастаны язылу вакытын Болгар чорларына нисбәтләп булмый.

Безнең тарафтан археографик экспедицияләр вакытында табып алынган һәм текстологик яктан өйрәнелгән «Ана белән угыл» дастанының кульъязма текстлары алда әйтелгән фикерләрне рас-ламыйлар. Әлеге текстлар нигездә XIX гасырда яки XX гасыр башларында күчерелгән. Аларның табылу географиясе һәм теле өлкәсендә ясалган күзәтүләр дә игътибарга лаек. Мәсәлән, безнең тарафтан табылган өч кульъязма текст та Татарстанның хәзерге Әлмәт һәм Лениногорск төбәкләренә карый. Хәлбуки, Казан арты авылларын егерме елдан артык өйрәнсәк тә, анда безгә дастанның кульъязма текстлары очрамады. Тел ягыннан караганда да «Ана белән угыл» теле чагыштырмача яңа, һәм ул саф татар җирлегендә язылган, татар тормышындагы тарихи вакыйгаларга аваздаш. Вакытлар, тарихлар фонында караганда, әсәр XVII — XVIII гасырлар вәзгыяте белән өртелгән: дастанның төп каһарманнары ятим малай һәм тол хатын, вакыйгасы — аларның тормышы. Мондый хәл XVII—XVIII гасырларда Русиядә «пушка ите» итеп файдаланылган татар гаиләләрендә генә булырга мөмкин. Русия хөкүмәте, татар ирләрен походларда, башка илләрне сугышып алу юлында даими рәвештә йөртеп, кырдырып, милләтебезне юк итәргә, һич югы көчсезләндерергә тырышкан. Гомер буе казаклык хезмәтендә йөргән татарның гаиләсенә төрле бәла-казалар күп килгән. Андый тол-ятимнәрнең бердәнбер яклаучысы итеп ислам дине, Аллаһ һәм аның рәсүле Мөхәммәд-Мостафа галәйһис-сәләм күрсәтелә. Бәла —Ал-лаһ тәкъдире белән килә, дип, мөселман җәмгыятенең аңа тарган кешеләргә теләктәшлеге булса да, ярдәм кулы сузучы каһарман образы дастанда юк. Анда протест белдерү дә бик пассив, көчсез кешеләргә хас рәвештә күрсәтелә. Мәсәлән, пәйгамбәрнең кардәшләре булган

Хәсән белән Хөсәен үзләренең гаделсез, шәфкатьсез эшләргә протестларын күз яшьләре түгеп, ялан баш, ялан аяк йөреп, мескенләнеп, чарасыз булып белдерәләр. Дин эшлеклеләре дә турыдан-туры бәлагә тарган кешеләрне якларга ашыкмыйлар.

Дастанда гаепле угланны мәйданга чыгарып утта яндырып җәзалау процессы тасвирлана. Мондый җәзаларга XVII—XVIII гасырларда колониаль властьлар «гаепле» дип табылган татар мөселманнарны тартканнар. Татарлар Мәскәүдә уздырылган кешеләрне җәзалап үтерү процессларын йөз еллар дәвамында күреп, күзәтеп килгәннәр, чөнки Мәскәү кенәзләренең вәхшилегенә чик-чама булмый. Татар риваятьләрендә дә карательләрнең йортларга мөселманнарны тутырып, яндырып үтерүләре хакында хәбәрләр сакланган.

Дастанда Идел буе мөселманнары өчен проблема булып килгән казага калган намаз (җәйнең озын көннәрендә ясигъ намазын үтәп булмау) темасы килеп керә. Әсәрнең идеясендә, Аллаһ мөселманнарны төрле авырлыклар белән сыный, авырлыклар — бар да тәкъдир язмышы, алар белән килешергә кирәк, гаделлек кем ягында булуын Аллаһ хәл итә, дигән буйсынып яшәү фәлсәфәсе уздырыла. Мондый идеяләр татарлар арасында XVII—XVIII гасырларда ныгый, чөнки күп санлы баш күтәрүләрдә җиңелүләр халыкта пессимизм тойгылары уяткан.

Дастанның теле дә яңа. Анда инде урта гасыр татар җәмгыяте өчен хас булган милли терминнар урынына *(бикләр, ханнар)* яңа заман атамалары — *патшалар, солтаннар* кулланыла башлый. Бер генә урында *бикләр* сүзе очрый, күбрәк *падишалар* кулланыла. Анда «болгаризм» (чувашизм) реликтлары юк. Дастанның сюжеты төрек әдәбиятыннан алынганга охшый. Анда госманлы теле өчен хас булган лексик берәмлекләр *әлем-айакым (кул-аягым), көнәш (кояш), дотмыш (тоткан), чәвереб (чөереп), дөшәрәм (егылам), дүндим (кайттым), өртдиләр (көйдерделәр)* һәм морфологик формалар очрый: *казайа (казага), күрмәз (күрмәс), әхмәдә (әхмәткә), кыйласән (кыласың).* Шулай ук анда татар теленең көнбатыш диалекты үзенчәлекләре дә күренеп китә, мәсәлән: *тормалы диде (тор диде), кузым сәңа (бәтием сиңа), киләчи (сорау, теләү), тукынды (бәрелде), катыйна (каршына), чагырдый (чакырды)* һ. б. Әмма әлеге дастанның теле XVII—XVIII гасыр татар әдәбияты истәлекләреннән аерылмый. Бу әсәр Касыйм ханлыгы татарлары арасында туган булып, аның тексты Идел буйларында татар-мишәр колонизациясе вакытларында таралган булырга охшый. Безнең тарафтан табылган текст күчермәләре шул фикер файдасына сөйлиләр.

«Ана белән угыл» дастаны татар халкы арасында шактый таралган булган. Аның күләме зур түгел, ләкин дастанны күчереп язучылар аны тагын да кыскартып күчергәннәр. Сакланып калган кулъязмаларда әсәрнең еш кына битләре югалган булуга фәкать кызгану белдерергә генә туры килә.

Безнең табышларыбыз арасында «Ана белән угыл» дастанының Кама аръягы көнчыгыш төбәкләрендә күчерелгән өч кулъязмасы бар.

Кулъязмаларның күчерелү вакытлары XIX—XX йөзләргә карый.

Бу кулъязмалар беркадәр бер-берсен тутыралар, берсендә булмаган юллар икенчесендә бар, берсендә күчерүчеләр җибәргән хаталарны икенчесеннән карап төзәтеп укырга мөмкин булды. Строфаларда бозып язылган юллар юк.

Кулъязмаларның өчесе дә Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Кулъязмалар һәм текстология мирасханәсендәге 39 нчы коллекциядә саклана. Аларга кыскача характеристика биреп үтәбез.

1

39 кол., 3254 нче кулъязма, 8а—13б битләр, кәгазь форматы 11ә18 см. 1830 елларда Әлмәт төбәге авылларының берсендә күчерелгән, күчерү елы, урыны, күчерүченең исеме сакланмаган, чөнки кулъязма тулы түгел. Дастанның бу күчермәсе матур почерк, яхшы кара белән эшләнгән. Ул Әлмәт шәһәрендә 1983 елда табылган булган.

2

39 кол., 2863 нче кулъязма, 1а—7а битләр, кәгазь форматы 10ә16 см. 1857 елда Әхмәт бине Габделҗаббар әл-Болгари тарафыннан күчерелгән, 1982 елгы археографик экспедиция барышында Татарстанның Лениногорск төбәге Кирлегәч авылындагы зират йортында табылды. Күләме 157 юл, баш өлеше һәм тагын берничә бите югалган.

3

39 кол., 2831 нче кулъязма, 1а—6б битләр, кәгазь форматы 10,5ә14,5 см. 1905 елда Зәй-Каратай авылындагы дамелла Җамаледдин бине дамелла Нигъмәтулла мәдрәсәсендә Мөхәммәдсадыйк әл-

Ормышлый тарафыннан күчерелгән, 1982 елгы археографик экспедиция вакытында пенсионер Гыймадетдинова Оркыя апа тапшырды. Күләме 158 юл, баш өлеше һәм тагын берничә бите юк.

Түбәндә «Ана белән угыл» дастанының өч кулъязмасы нигезендә тулыландырылып төзелгән уртак текст тәкъдим ителә. Дастанның бер нөсхәсендә исеме «Хикәйәте мөнәҗәт» дип бирелгән.

## Ана белән угыл

*(Хикәйәте мөнәҗәт)*

Бисмиллаһи-р-рахмани-р-рәхим

1. Вар иди Кагъбә шәһриндә бер хатун,
Дөнйасын вирүб ахирәтни алдый сатун.

2. Дөнйасын ахирәткә сатмыш иди,
Изгү ат берлә дөнйаный дотмыш иди.

3. Йавыз атлыйг ики җиһанда хәкыйрь,
Изгү ат берлә йөрүр иди ул фәкыйрь.

4. Намаз казайа куймаз иди,
Кемсәнең гайебени һәм күрмәз иди.

5. Хозыр-Илйас килүр иди катыйна,
Күрмәккә мөштак иди сөхбәтина.

6. Нәфесни үлтүрмәккә кадир иди,
Нә улдыгын, нә уласын белүр иди.

7. Ул хатынның хәлали улмыш иди,
Аның бер угланы калмыш иди.

8. Ул угланный остазга вирмеш иди,
Хак тагалә аңа гыйлем вирмеш иди.

9. Көнәша охшар иди аның йөзи,
Шикәрдән татлу иди ширин[5] сүзи.

10. Аның кеби күреклүм иди ул бала,
Күреклү йөзи биңзар иди көнаша.

11. Анасыйның айагын үбәр иди,
Ана тийү төрли гыйззәт кыйлур иди.

12. Ул углан «Коръән»гә кермеш иди,
Улган тәмам «Коръән»не укумыш иди.

13. Шул гаҗәйеб ул фәлакниң эшинә.
Күрнә килди ул угланның төшинә.

14. Ул углан уйкуйа йатмыш иди,
Күзи гафләт уйкусина вармыш иди.

15. Йаз көни ирди озун, төни кыска,
Татлы уйку вирмеш иди Аллаһ аңа.

16. Намаз вакыты булды, углан тормади,
Баң авази колагына кермәди.

17. Анасый әйтүр, әй углум, күзем нури,
Намаз вакыты булды, тормалы, диде.

18. Абдаст алыб намазыңа барсана,
Тәңри рәхмәт әйләсүн кузым сәңа.

19. Углан әйтүр, анам, күрдем мән сәни
Төшемдә, утка йакарсын сән бәни.

20. Тик торур иркән йөзем булды кара,
Йөз чәвереб ордым мән пәйгамбәра.

21. Рәсүл әйтүр, кит, катыма килмәгел,
Тәңри колый, миңа рәхмәт улмагыл.

22. Дөшәрәм бән рәсүлнең айагыйна,
Йалбардым ул пәйгамбәрләр бигина.

23. Углан әйтүр, йа рәсүл, Аллаһ бәндәйен
Нә дийәрсеңез мән кайыра дүнәйен.

24. Рәсүл әйтүр, рәва [5] өмид вир, йа гасый
Орыб анаң күзүни чыкаргучый.

25. Анаң чәрәх бирүр һәм бичара.
Хак дийәрин күрмәйәсен нә чара.
26. Бактым, күрдем анасының күзигә,
Кан булашмыш ул ай тик йөзигә.

27. Бәлки шул йирдин тордум үри,
Галәмәтдә дүндим, андан бири.

28. Анасы әйтүр, әй углым, чук сөйләмә,
Остазыңа дөшең бәнһан әйләмә.

29. Үтмәк алгыл, анда барыб йийәрсән ,
Бу дөшеңи остазыңа дийәрсән.

30. Углан әйтүр, үтмәк кайгуси дәгүл,
Җанымның кайгуси бәңа бу көн ул.

31. Кырык көн руза тотам , һич йимийән,
Һич кемәйә бер келәчи сүз [5] димәйән.

32. Анасый үтмәк суна , бәҗәд тотар,
Кайыра углан, шул сәгать кирү атар.

33. Алды углан, атдый анасый йөзинә,
Кодрәт берлә тукынды саг күзинә.

34. Анасыйның күзи шул даим чыкар,
Вай әнә кем, анасый күңлин йыкар.

35. Сәхабәләр калдый ул углан дөшинә,
Күрнә килди ул угланның башыйна.

35. Күрде углан анасыйның күзине,
Парә, парә әйләди кәндүзине.

37. Пычак алдый кәндүзине ормага,
Анасый өчүн кәндү җанын вирмәгә.

38. Пычакны углан кулыдин алдыйлар,
Ул дөшинә гаҗәйәбә калдыйлар.

39. Хәбәр улдый Мостафа-Мөхәммәдә,
Ике җиһан сәрвәри ул әхмәдә.

40. Килди хатун катыйна нурга бата,
Дүрт йар илә Мостафа бенди ата [5].

41. Мостафа ул хатунный белүр иди,
Аңа төрлү гыйззәтләр кыйлур иди.

42. Атдин тотди ике җиһан күнәши,
Хатун эчүн акдый күзендин йәши.

43. Чакырдыйлар ата-ана угланнарын,
Чарасы будыр, күрең бунларның.

44. Мостафа арданча түрт йар илә,
Күреклү сәлам бирдиләр җөмлә билә.

45. Рәсүл әйтүр ул хатунга, әй ана,
Равә күрмә , угланың утда йана.

46. Хатун әйдүр, мәнни ошандырмагыл,
Җөмлә галәмни утда йандырмагыл.

47. Хак белүр, аңа гизән кем әйләрәм,
Йаздыңча падишаһга сөйләрмән.

48. Кодрәти рәсүлнең — күреклү җаный,
Хатунга әйтүр, әй ахирәт солтаный.

49. Эстәйәсәң углуңый, тапмайасән.
Хак белүр кем кайгыларый йийәсән.

50. Каза ирди Тәңредин килди аңа,
Кил, аның гөнаһын багышла өммәтеңә.

51. Килмәдем кем, бән сәңа көч әйләйем,
Бән килдем кем, хак сүзени сөйләйем.

52. Чөн сәнең хатереңчә сөйләдиләр,
Утынный имди хазир әйләдиләр.

53. Угланыңный имди утга йакарлар,
Монафикълар гаһдинә кем бакалар.

54. Хатун әйдүр, нә кирәкдүр кыйласән,
Сөтем аңа хәрам улсын, беләсән.

55. Угланыны тәва буйнындин алдыйлар,
Сәйсәт мәйданинә килтүрдиләр.

56. Гали чагырдый, утун килтүрдиләр,
Һәрбери берәр кочак күтәрдиләр.

57. Йактыйлар ул утынный йавлык[5] катый,
Газиларның күккә чыкар форйадый.

58. Тотдыйлар ул угланны килтүрдиләр.
Ул утынның уртасыйга йаткурдыйлар.

59. Дүрт йаңадан бакыб ирләр тордыйләр,
Барчасы ул ут илендин өртдиләр.

60. Тоташа башладый ут ул кем йана,
Углан чагрур, әйтәдүр ул, әй ана!

61. Бири килгел, ахыр күргел халеми,
Кортар имди, ушбу утдин җаными.

62. Ут эчендә әлем[5]-айкыйм киселди,
Кил, рәхим кыйл, җаным анам, бәңа, тиди.

63. Нәмруд утыйн бәнем өчүн йакдыйлар,
Мән мескинни утка пыракдыйлар.

64. Ут эчендә тоташубән йанарам,
Чыгалмазам, түрт йаңа бакарам.

65. Күрнә килди аһ бәнем (бу) башыма,
Гомрүм, йекетлеким аз (бу) йашимә.

66. Бер кичә бәнем өчүн тордың ула
Углум тәйү бәни имездүң ула.

67. Ничә кем чагырдый, һич чара улмадый,
Анасы һәргиз шәфәгать кыйлмадый.

68. Хәбәр улды – ул Хәсән, Хөсәйенгә,
Әйдиләр, имди угланың утдә йанә.

69. Әйдиләр, кани йарымыз, карындашымез,
Хәлифәмез йирендә йардәшемез.
70. Нәмруд өчүн йакан утный йакдыйлар,
Ул мескинни ул утга пыракдыйлар.

71. Хәсән, Хөсәйен баш ачык, йалан айак,
Мостафа катыйна килдиләр йайак.

72. Мостафага әйдиләр, әй дәдә,
Кәндү әлең берлә безне атгыл удә.

73. Йыгладыйлар икеси, йаш сачдилар,
Мостафаның азакыйга[5] дөшдиләр.

74. Углан берлә без дә бергә йаналем,

Бу дөнйага без килмәдек саналем.

75. Зирә углан чөн – йармыз карындашмез.
Хәлифәмез йирәндә йиридашмез.

76. Углан өчүн җанымыз улсун фида,
Мостафайа Тәңредин килди нида.

77. Чөн ишетди Мостафа Хак сүзини,
Сүвенди, үбди ул икүниң йөзини.

78. Угланның анасыйна барың, тиди,
Ул хатынга баруб йалварың, тиди.

79. Хәсән, Хөсәйен баш ачык, йалан айак,
Ул хатун катыйна килдиләр йайак.

80. Бисмилла, дип капусыны ачдыйлар,
Йыгладыйлар, икеси йаш сачдыйлар.

81. Ул хатунга әйдиләр кем, әй ана,
Рәва күрмә угылың утда йана.

82. Деләрүз кем, бер капуга чыкасыз,
Угланчыгың халинә бер бакасыз.

83. Хатун боларның сүзин сындырмадый,
Буларның хатурләрин һич куймадый.

84. Сындырмадый хатун икениң сүзин,
Тышра чыкдый, күрди углани халин.

85. Күрди углан ут эчендә йанадур,
Үзи көйенди чырасын йакадур.

86. Күзләри йаш тулдый, хатун агладый,
Көйди бәгъри, йөрәкини дагладый.

87. Җөмлә галәм күзи улды кап-кара,
Ут эчендә күрди углан бичара.

88. Бер кизин чагырдый хатун, әй угыл,
Айрык ана димәгел миңа, куйгыл!

89. Ана дәгүл, сәңа әгйар улмышым.
Кыйлмайа кяфергә, сәңа кыйлмышым.

90. Канкый гаурәт угланын утга йакар,
Кәндү торуб[5], йыракдин ничә бакар.

91. Күтәрди кәнд үзени атдый удә,
Ут эчендә калдый угланый берлә йәнә.

92. Ордый йөзүн угланчыгы йөзинә,
Ут доташдый кем бадә кәндүзинә.

93. Утыз өч мең сәхабә кыйлдый зарый,

Йөкерди Мостафаның дүрт йарый.

94. Ут катыйнә кемсәнә бармадыйлар,
Боларны утдин кемсәнә алмадыйлар.

95. Калдый углан утдә анасы бийлә,
Ишет имди падишаһ канә кыйлә.

96. Ул солтаннар солтаны, кадир ишә,
Әмер кыйлды күкдәги очар кошә.

97. Килдиләр йөз мең, диңгезгә тулдыйлар,
Агызларыйлә, канатларыйлә су алдыйлар.

98. Падишаһ әмри бийлә килтүрдиләр,
Ул утның уртасыйга йагдурдиләр.

99. Аның кәби түктиләр Ход падрәһ [5],
Шул дәм сүнди ул ут, әмри падишаһ.

100. Хал тили берлә әйдүр, әй Кадир,
Бойрыгың берлә, кыйлмышлар хазир.

101. Сән йарый кыйл бу бичарә колларә,
Сән әл-айакны рузи кыйл бунларә.

102. Җөмләси канат канатыйга ордыйлар,
Күреклү тәкбир, хуш салават бирдиләр.

103. Чөнки инди Җабраил күкдин йирә,
Мостафайа Хак сәламин тигүрә.

104. Кодрәтемни күстәрәм бән бунларә,
Һәр кайсын күстәрди Хак пәйгамбәрә.

105. Күрди ирсә пәйгамбәр ачдый күзин,
Амин, тийүб йаранлар түкди йәшин.

106. Тәмам итди догасын силди йөзин,
Ул хатунга падишаһ бирди күзин.

* * *

1740 елларда Акай батыр җитәкчелегендәге татар азатлык сугышы хакында тарихи хикәятне бу якларда язганнар. Кызганыч ки, бу хикәят 1936 елларда урыс теленә тәрҗемәдә генә сакланган, аның татарча оригиналдән бер битлек фотокүчермәсе генә калган. Хикәят урыс теленә беркадәр бозылып тәрҗемә ителгән. Татарча бер бит текст белән урысча текстны чагыштырып карасаң, мәгънәви аермалар күзгә ташлана.

Хикәяттә Урал буенда башкорт сословиесен алган татарларның бер провокациягә тартылып, колониаль властьлар тарафыннан шәфкатьсез җәзаланулары тасвирлана. Һәрвакыттагыча, татар арасыннан колонизаторларга хезмәт итәргә ярашкан адәмнәрнең милләттәшләре канын коюда күрсәткән тырышлыклары фаш ителә.

«Акай явы хикәяте» — XVIII гасыр татар әдәбиятының «Батырша гарызнамәсе» кебек үк көчле публицистик үрнәге. Ул 1864 елда Татарстанның бүгенге Түбән Кама төбәгенә караган Шәнгәлче

авылында Нурмөхәммәд Мөхәммәджан улы тарафыннан төзелгән җыентык аша мәгълүм булды. Кульъязма Татарстан фәнни-тикшеренү марксизм-ленинизм институтында сакланган, бүгенге көндә язмышы билгесез.

*(Өзек «История Татарии в материалах и документах» исемле 1937 елда Мәскәүдә нәшер ителгән китаптагы текстан алып тәрҗемә ителде (402—403 б).*

## «Акай явы турында хикәят»

...Казан чувашлары, чирмешләр, мордвалар һәм Өрҗем халыклары, урыс изүенә чыдый алмыйча, туган җирләреннән качарга, яшеренергә керештеләр. Алар барысы да дәфтәрләргә «башкорт» дип язылдылар һәм шунлыктан берсе дә урыслар кулына кире кайтмадылар.

Күчеп килүчеләр башкортлар арасында бик күпләр, алар үзләрен башкортлар дип күрсәтәләр дә, шунлыктан боларның шәхесләрен билгеләү мөмкин булмаган эшкә әйләнде.

Старшина Күсембәт Үләкәй углының йорты Минзәлә шәһәреннән 50 — 60 чакрым ераклыкта иде. Ул вакытларда дүрт юл буена урнашкан халыкларның фикере бер иде, һич аерымлык булмады. Һәркем старшинаны тыңлады, башкорт булып йөрүчеләрнең тормышы иркен иде. Берчакта да урыслар сүзенә колак салмадылар, гаделлек өскә чыкты, вәсвәсә таралды, юк булды. Аллаһ бәла-казалардан имин кылды. Күсембәт Үләкәй углының өч ир баласы бар иде: берсе — Атха — явыз холыклы булды, икенчесе — Акай — урыс кулына төште, өченчесе — чуваш. Соңгысы күзгә күренерлек түгел, чуваш хатыннан туган, «чуваш» кушаматлы бер адәм иде.

Күсембәт үлгәч, бик елгыр караклар Акайның атларын урлыйлар. Ул караклар Казан чувашлары була. Ирнә елгасы буендагы Ураз авылы янында Акай ат каракларын куып җитә. Ләкин алар, Акай кулына эләкмәс өчен, ук һәм кылычлар тотып каршылык күрсәтәләр. Акай аларның барысын да кырып бетерә. Әмма каракларның берсе исән калып, Минзәләгә Акай өстеннән шикаять бирә. Шикаятьтә, Акай күпсанлы отряд белән килеп тыныч халыкны кырды, берни калдырмый талады, дип язылган була. Әлеге шика-ятьне урыс кенәзенә бирәләр. Кенәз зур гаскәр белән Акай авылына юнәлә. Отряд белән Румянцев командалык итә. Отряд Акайның авылын чолгап ала, һәм аны торткын итәләр. Бу хәлләрдән соң Акайны берәүгә дә күрсәтмиләр... Акайны асып үтергәннәр икән, ул чыбык белән кыйналудан үлгән икән, дигән хәбәрләр дә тарала. Бу хакта яхшы адәмнәр дә, яманнары да, бер-берсенә сөйләп, төрле сүзләр тараталар. Халык җыенга әзерләнә. Һәрбер ырудан вәкилләр килә. Тик кыр ягыннан канлылар һәм кубавиләр генә килми. Алар баш күтәрү белән риза булмыйлар. Шул вакытта, алар алдында байраклар күтәреп: «Сез көрәшкә хәзерме?» дип кычкыралар. Моннан соң алар теләсәләр-теләмәсәләр дә бердәм фикергә кушылырга мәҗбүр булалар. Болар арасында Букатин, Кыпчак, Тамьян, Бөрҗан, Пычкак, Уран, Каршин, Кури, Кубави, Карайлар, Шураннар, кыргызлардан өч төркем, дүрт төркем Еланнан һ. б. вәкилләр килә. Бар да килешеп, сугышка хәзерләнә башлыйлар. Әлбәттә, җыенга танылган батырлар, тәҗрибәле картлар, фикерле галимнәр дә чакырылалар. Алар арасында Пычкактан Уразман батыр, Тамьяннан Сәлим батыр, Еланнан Габдулла батыр, Байлардан Килмәк абыз бар иделәр. Алар бар да бер фикергә киләләр. Җыеннан соң, урыс хакименә хат белән вәкил җибәрү карар ителә. Хат түбәндәге сүзләр белән башлана: «Бисмиллаһир-рахманир-рахим. Беренчедән, безгә Күчем углы Акайны бирегез; икенчедән, Минзәләгә кире керегез һәм чик сызыгыннан бу якка чыкмагыз. Әгәр бу таләпләребезне үтәмә- сәң, Аллаһка тапшырып, сезнең белән сугыш кылабыз!..»

Моңа каршы җавабында урыс хакиме: «Миңа Җаек елгасына чыгарга юл бирегез. Мин анда, бөек падишаһыбыз кушуы буенча, кала кору өчен урын сайларга тиешмен. Шуннан соң Акайны сезгә кайтарырбыз, әлегә ул урыс арасында торып торсын», — ди. Бу җаваптан соң олы һәм кече, галим һәм гади кешеләр җыелып киңәшәләр. «Әгәр кяфер безнең илебезне басып алса, ул анда гаскәр куячак. Безнең балаларыбыз кяферләр кулына калыр һәм аларга хезмәт итәр», — дигән фикергә киләләр. Киңәшеп, урыска каршы сугыш белән барырга карар итәләр...

## ШАГЫЙРЬ МӘҮЛА КОЛЫЙ

XVII гасырда яшәп иҗат иткән атаклы татар шагыйре Мәүла Колыйның да гомере һәм иҗаты Әлмәт яклары белән бәйләнгән. Аның чын исеме Бәйрәмгали Колаев булып, ул 1676 елда Чыты дигән авылдан (бүгенге Татарстан, Питрәч районына карый). Биләр шәһәрендәге астәнәләр (төрбәләр) янына мәрхүм абыйсына алмашка күчеп килә. Бәйрәмгали Колаев та суфый

нәкышбәндиләр тарафдары; аның остазы Казан илендә мәгълүм, Бохарада укып кайткан Мамай мелла була.

Патша хөкүмәте татарларның борынгы мөселман шәһәрләре янына әйләнеп кайтуларын теләмәгән. Шунлыктан XVII гасыр ахырында, 1699 елда, ниһаять, татарларны Биләр шәһәре җимерекләре, каберлекләр арасыннан куып җибәреп, алар урынына урыс стрелецларын китереп утырталар. Бәйрәмгали Колаев һәм аның кардәшләре Сарабиккол, Иштирәк, Кизләү һ. б. шул як авылларга барып төпләнәләр. Бәйрәмгали Колаев укымышлы, галим кеше булып, халык арасында Бимкә суфый дигән кыскартылган исем белән мәгълүм була. Аның кайчан үлгәнлеге мәгълүм түгел, ләкин XVII гасыр ахырында аның исәнлеге билгеле. Ул шигырьләрендә үзенә, суфыйлар гадәте буенча, Мәүла Колый дип дәшә.

Мәүла Колыйның ике зур шигырьләр җыентыгы мәгълүм, аларның икесе дә Әлмәт якларындагы Зәй-Каратай (Лениногорск районы) һәм Камай (Бакалы районы) авылларында табылганнар. Соңгы елларда гына археограф Раиф Мәрданов Мәүла Колыйның фәнгә билгеле булмаган ике поэмасын тапты. Ул кулъязма Татарстанның Әгерҗе төбәге Яңа Аккуҗа авылында табылган. Бүгенге көндә Мәүла Колыйның 100 дән артык шигыре (хикмәтләре) һәм ике поэмасы мәгълүм. Аның Әлмәт, Зәй, Шушма буйларына килүе бу төбәктәге язма әдәбиятның саклануына һәм яшәвенә уңай тәэсир ясаган.

## Хикмәте хәким...

Яр/и/ мәңа бүләк измеш  акча яулык,
Ул яулыкны алмаклыга сундым илик ,
Ярым үзе халык эчендә олуг мәлик,
Хезмәтендә торайым мән башым салыб...

...Былбыл кошның артар гыйшкы кызыл гөлдин,
Нәүмид кыйлса  сүнмәз яр/и/ күңел сәндин,
Бу чыкар җан ахыр бер көн чыкар тәндин,
Сән гүзәл яр айрылмайын торгыл мәндин.

Яр мәни килсүн димеш, китәйен мән,
Ярның әйткән вәгъдәсинә, нитәйен мән ,
Бүләк табмай бардым ирсә, нәтәйен мән? [5]
Хәлем күреб әсиргәсә  рәхим андин.

Мәүла Колый, яр сүзини тота белмәй,
Гомрең заигъ үтде һәргиз юлга кермәй.
Иранлар тик  хакдин табыб, хәлгә килмәй,
Гайбемне ул кичергәй диб, өмид мәндин.

*(Мәүла Колый хикмәтләре.— Уфа, 1991.— 38 б.)*

## ШАГЫЙРЬ ҺӘМ ГАЛИМ
## ГАБДЕРАХМАН ТАЙСУГАНИ

Шагыйрь Габдерахман бине Туймөхәммәд бине Бикмөхәммәд бине Янбулат бине Ягъкуб бине Симән бине Илаз бине Габдулла бине Бикчура хан һиҗри 1102 елда, милади 1691 елда Мортыш-тамак авылында туган. Тырышлыгы белән гыйлем алып, заманында татар арасында галим буларак даны таралган. Хәзерге Әлмәт төбәгендәге Тайсуган авылында имам һәм ахун буларак көн иткән. Аның бабалары Алтын Урда татар ханнарыннан Габдулла ханга (Бикчура хан) барып тоташалар.

Габдерахман Тайсугани мәдрәсәләр ачып, анда күп фәннәрдән дәресләр биргән. Ул аеруча шәригать гыйлеменнән көчле белгеч булган. Аның мәдрәсәсенә атаклы татар батыры Батырша да килеп укыган. Халык хәрәкәте җитәкчесе Батырша (Баһадиршаһ Галиев, 1710—1762) белән Габдерахман Тайсугани фикердәш булганнар. Габдерахман Тайсугани 1753 елда үлгән.

Аның каләм мирасының бик аз өлеше генә безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Мөхәммәд пәйгамбәргә багышланган «Касыйдә» дип исемләнгән озын шигырен Ризаэддин бине Фәхреддин

табып, үзенең «Асар» исемле био-библиографик хезмәтенең икенче кисәгендә бастырып чыгара (46—49 битләр). Шигырь һижри белән 1140, милади 1728 еллар тирәсендә язылган.

## Касыйдә

1. Йа шәфигым, сәйдел-кәүнәйн
   Фәхрел мөрсәлин,
   Сәнең өчен йаратылды
   Җөмлә әфләк вә зәмин.
Мәһтәре гарәп гаҗәмсен,
Рәхмәте лил-галәмин.
Сән шәфагать әйләгел бу
Мәбтәлайә, йа шәфигъ!
2. Амир вә наһи нәбийемез
   Сән безем, и зөлкәрәм,
   Кимсә йук сәндин айурык,
   Димәде ля, вә нәгамь.
   Җөмле куркугъларда сәнсен
   Һәм шәфигы мөхтәрәм.
   Сән мәдәд әйлә бу мескин
   Мөбтәлайә, йа шәфигъ!

3. Дәгъвәт итдең халыкый.
   Һоб суйе сыйрат мөстәкыйм,
   Сәңа эстәмсак идән, бәс, —
   Хәбеләә улдый могътәсәм,
   Ул дорыр бер хәбле мәхкәм,
   Улмайа сәре мөнфасыйм.
   Сән шәфагать кыл бу мөҗрим
   Мәбтәлайә, йа шәфигъ!

4. Сурәт, сирәттә әгълаи.
   Рөсәлесән, йа рәсүл!
   Һичбери гыйлем кәрәмдә
   Сән кеби улмыш дәгүл.
   Мәгъдәне гыйлем кәрәмсән,
   Сән айә аслы ысул!
   Сән мәдәд әйлә бу мескин
   Мөбтәлайә, йа шәфигъ!

5. Сурәтең хөснең әна әмләхе,
   Дийу кылдың бәйан,
   Сирәтең улды «галә
   Холыкы Газыйм»дән һәм гайан,
   Шаныйлмендә «әләм нәшрах»,
   Диде ул би нишан.
   Сән шәфагать кыл бу мөхти
   Мөбтәлайә, йа шәфигъ!

6. Дәгъвәткә килде агачлар
   Сәнең, и бәхре җүд.
   Би кадәм балдырлары үзрә
   Идуб хакка сөҗүд.
   Улды пәйгамбәрлегеңә
   Җөмләсе анлар шөһүд,
   Сән мәдәд әйлә бу мескин
   Мөбтәлайә, йа шәфигь!

7. Ул мөбарәк башың үзрә
Парә болыт һәр заман
Саклайуб тәммүзиң эссесендин
Улды сайәбан.
Канда варсаң варыр иде
Ул дәхи сәнең белән.
Сән шәфагать кыл бу гасый
Мөбтәлайә, йа шәфигъ!

8. Бер дәхи бармакларыңдин
Чишмәләр улды рәван.
Эчте андин һәм тәһарәт
Әйләди пир вә җәван.
Дүним улды бармакыңдин
Дәхи маһи асман.
Сән мәдәд кыл бу сийаһруй
Мөбтәлайә, йа шәфигъ!

9. Сөйләди бирйан кузый
Дәхи сәңа дилә килүб.
Йимә, диде, килмешем бән
Йа рәсүл, мәсмүм улып.
Бу бәладә калмышым бән
Мөбтәла мәгъмүм улып.
Сән шәфагать кыл бу мескин
Мөбтәлайә, йа шәфигъ!

10. Могъҗизатың гәр мөнасиб
Ула иде кадреңә.
Исмең әмвәти дирелдүб,
Керер иде әмереңә.
Гаҗиз улдый, ирмәде һич
Мәдхе мәддах зикереңә.
Сән мәдәд әйлә бу мескин
Мөбтәлайә, йа шәфигь!
11. Могъҗизатыңа сәнең
Булынмады һич хәд вә гад.
Хәд вә гад(д)ен белмәс аның
Һич әхәд гайре әхәд.
Йазмайалар гәр фәләк,
Оурак ула дәрйа мәдәд.
Сән шәфагать кыл бу мескин
Мөбтәлайә, йа шәфигъ!

12. Рәхмәтең дүгүлүвенчә ничә
Хәстәләр улды шифа!
Соргы җендин ничәләр
Улды әфака һәм сафа.
Ничә мәгьлүл сыйхатә
Ирди әйгане вафа!
Сән мәдәд әйлә бу мескин
Мөбтәлайә, йа шәфигъ!

13. Ничә дилсез пор фәсахат
Булды сәндин, йа хәбиб!
Ничә күзсезләр бәсарәт

Булды сәндин, йа табиб!
Ничә мәгъмүмләр мәсарат
Булды сәндин, йа хатиб!
Сән шәфагать кыйл бу мескин
Мөбтәлайә, йа шәфигъ!

14. Әйтте Хак, «әсра бигабдиһи»,
Илә мигъраҗың бәйан!
Мәнзилеңдин «кабе кәүсәйин»
Илә вирди нишан.
«Ли мәгаллаһи» димәкеңдин
Мөхфилең улды гаян.
Сән мәдәд әйлә бу мескин
Мөбтәлайә, йа шәфигъ!

15. Һиммәтең моргыйна
Фирдәүес кәмейнә ашйан.
Нисбәт касреңә миграҗе
Мәләик астан,
Нуре вәҗәһеңдин вәҗүд улдый
Бу кәвен иле мәкян.
Фазлың әйлә сән шәфигъ.
Мөбтәлайә, йа шәфигъ!

16. Сәндин үзгә, йа шәфигыль,
Мөзнибин йукдыр гөнаһ.
Мөбтәлайә назил улдыкда
Биля бигяһ вә гяһ
Улмайа бәңа шәфигъ.
Улмагыйлә ноксан кадәр җаһ.
Сән мәдәд әйле бу мескин
Мөбтәлайә, йа шәфигъ!

17. Зирә галәм кян җүдеңдин
Сәнең, и бәхре җүд!
Гыйлем ләүхе илә каләм
Улды голүмеңдин вөҗүд.
Бәхре җүдең мәгъдәнендин
Бу кыйам, бу сәҗүд.
Сән шәфагать әйлә гел бу
Мөбтәлайә, йа шәфигъ!

18. Ничә мәдех итсүн сәни,
Бу мөбтәла, и бакәмал,
Чүн сәңа мәддах улубдыр.
Падишаһи зөлҗәлял!
Нәгатеңи зикер итмәдә
Һәб нотык натыйкнең лял.
Сән мәдәд әйлә бу мескин
Мөбтәлайә, йа шәфигь!

19. Даимә улсун сәңа Хакдин
Салатилә сәлам!
Һәм җәмигы Әль-Әсха
Бәңа, и хәйреләнам!
Мәлҗаэ мөэмүл сәнең
Сән мөбтәлайә бәрдәвам.

Сән шәфигь ул (Габдрахман)
Мөбтәлайә, йа шәфигъ!

## Касыйдә

*(Юлга юл тәрҗемә)*

1. Йа яклаучым, ике дөньяның хуҗасы,
   Пәйгамбәрләрнең горурлыгы,
   Синең өчен яратылды
   Җиде кат күк һәм Җир.
   Гарәпләрнең һәм гарәптән башка халыкларның да бөеге,
   Галәмнәрнең рәхмәте,
   Син шәфкать кыл
   Бу бәхетсезгә, йа яклаучы!

2. Боеручы һәм тыючы пәйгамбәребез
   Син безнең, и изгебез,
   Синнән гайре һичкемебез юк,
   Димә дә, юк һәм дөрес.
   Барча куркуларыбыз синсең.
   Һәм мөхтәрәм яклаучы.
   Син ярдәм ит бу мескен
   Бәхетсезгә, йа яклаучы!

3. Күндерден син халыкны,
   Озак итеп, туры юлга.
   Сиңа ияргәннәр бәйләндек сиңа,
   Бәйләнешле булды сыгыну урыны эзләүчеләргә.
   Ул торыр бер нык җеп,
   Өзелмәслек булып.
   Син шәфкать кыл бу гөнаһлы
   Бәхетсезгә, йа яклаучы!

4. Сурәт һәм гамәлдә
   Рәсүлләрнең иң бөеге син, йа рәсүл!
   Һичбере гыйльме изгелектә
   Синең кебек булмас.
   Син — гыйлемлек һәм изгелек гыйльменең чыганагы,
   Син барысының да асылы.
   Син ярдәм ит бу мескен
   Бәхетсезгә, йа яклаучы!
    5. Сурәтең матурлыгың — мин иң матуры,
       дип кылдың бәян.
       Гамәлең булды билгеле
       Синең олы холкың буенча.
       Синең гыйльмең бөеклегендә,
       без ачмадыкмыни, диде ул,
       Аллаһе тәгаләнең билгесен?
       Син изгелек кыл бу хата иясе
       Бәхетсезгә, йа яклаучы!

    6. Өндәвеңә килде агачлар
       Синең, и юмартлык диңгезе.
       Аяксыз, болытларында килделәр
       Сәҗдә итеп Хакка.
       Булды пәйгамбәрлегеңә

Барчасы аларның шаһит.
Син ярдәм ит бу мескен
Бәхетсезгә, йа яклаучы!

7. Ул мөбарәк башың өстендә
Бер кисәк болыт һәр заман,
Саклап җәйнең эссесеннән,
Булды сиңа чатыр.
Кая барсаң барыр иде
Ул тагын синең белән.
Син шәфкать кыл бу гөнаһлы
Бәхетсезгә, йа яклаучы!

8. Бер генә баруларында да
(аларның эзләреннән) чишмәләр ага торган булды,
Алардан эчте һәм юынды
картлары һәм яшьләре дә.
Узып барганыннан ике кисәк булды
Күк йөзендәге ай да.
Син ярдәм ит бу кара йөзле
Бәхетсезгә, йа яклаучы!

9. Сөйләде кыздырылган бәрән
Тагын сиңа, телгә килеп,
Ашама, диде, килдем мин,
Йа рәсүл, агуланып.
Бу бәладә калмышмын мин
Бәхетсез, авыру булып.
Син шәфкать кыл бу мескен
Бәхетсезгә, йа яклаучы!

10. Әгәр могҗизаларыңны үлчәп булса иде,
Булыр иде кадереңә.
Исемең үлеләрне терелтеп,
Керер иде әмереңә.
Гаҗиз булды, аптырады,
Мактаучы сүз тапмады мактарга.
Син ярдәм ит бу мескен
Бәхетсезгә, йа яклаучы!

11. Могҗизаларыңа синең
Булмады һич чик, хисап.
Чик һәм хисабын белмәс аның
Алладан гайре һичкем.
Язып бетерә алмыйлар аны, әгәр күк йөзе
Кәгазь булса, дәрьялары язу карасы булса.
Син шәфкать кыл бу мескен
Бәхетсезгә, йа яклаучы!

12. Рәхмәтең түгелүеннән ничә
Хәстәләр тапты шифа.
Җен сукканнан (эпилепсия) ничәләр
Тапты шифа һәм сафа.
Ничә авырулар сихәткә
Алдылар тәмам дәва.
Син ярдәм ит бу мескен
Бәхетсезгә, йа яклаучы!

13. Ничә телсез тәмле телле
Булды синнән, йа Алланың сөеклесе!
Ничә сукырлар үткен күзле
Булды синнән, йа табиб.
Ничә бәхетсезләр шатлыклы
Булды синнән, йа юатучы.
Син шәфкать кыл бу мескен
Бәхетсезгә, йа яклаучы!
14. Әйтте Хак (Алла) «Төнлә күчерде»
ул колың, дигән сүз белән
синең мигъраҗың бәян булды.
Алла сиңа торган җиреңнән
Ике ук ераклыгыннан хәбәр бирде.
«Мин Алла белән!» — дигәнеңнән
Серең билгеле булды.
Син ярдәм ит бу мескен
Бәхетсезгә, йа яклаучы!

15. Син эзләгән кошның урыны
Фирдәвес җәннәтендә.
Сиңа тиешле сарайның урыны
Фәрештәләр күтәрелгән җирдә
(Алланың тәхете янында).
Синең йөзеңнең нурыннан яратылды
бу галәм һәм Җир йөзе.
Яхшылыгың белән шәфкать кыл
Бәхетсезгә, йа яклаучы!

16. Синнән башка, йа гөнаһларны яклаучы!
Синнән башка сыгыну урыны юктыр,
Әгәр дә без бәлагә юлыкканда,
көтеп һәм көтелмәгәндә.
Булмас мине яклаучы
Һич кенә бер җирдә дә.
Син ярдәм ит бу мескен
Бәхетсезгә, йа ярдәмче.

17. Чөнки галәм кебек юмартлыгыңнан
Синең, и юмартлык диңгезе!
Коръән белән Каләм
Барлыкка килде синең белемнәреңнән.
Синең юмартлык диңгезе чыганагыңнан
Бу кыям , бу сәҗдәләр .
Син ярдәм ит бу мескен
Бәхетсезгә, йа ярдәмче.

18. Ничек кенә мактаса да сине
Бу бәхетсез, и бакәмал,
Чөнки сине мактыйдыр
Бөек Алла үзе.
Сине мактаганда,
Күп нотык сөйләүчеләрнең теле аксар,
Син ярдәм ит бу мескен
бәхетсезгә, йа ярдәмче!

19. Һәрвакытта булсын сиңа
Аллаһы тәгаләдән сәлам, фатиха,

Һәм үзеңә, һәм сәхабәләреңнең
барысына, йа кешеләрнең иң яхшысы.
Синең сыена торган урының, сиңа өмет.
Син яклаучы бул ул Габдрахманга,
Бәхетсезгә, йа яклаучы...

(Тәрҗемә гарәп-фарсы телләрен белүче Сәлим Гыйлаҗеддинов ярдәме белән эшләнде. Моның өчен аңа рәхмәтебезне белдерәбез.— *М. Ә.*)

## ШАГЫЙРЬ РӘХИМКОЛ БИНЕ ИСЛАМКОЛ

Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты каршындагы Кулъязмалар мирасханәсендә, 1969 елның 24 июнендә Ташкентта яшәүче Мөгаззәмә ханым Гатауллина тарафыннан тапшырылган 40 кулъязма (39 кол., сакл. бер. № 44—83) арасында, татар әдәбияты тарихы өчен мөһим информацияләргә ия булганнары күп. Шуларның берсендә (сакл. бер. № 48) XVII—XVIII гасырларда иҗат иткән Мәүла Колый, Габди, Рәхимкол бине Исламкол һ. б. шагыйрьләрнең әсәрләре теркәлгән. Кулъязмалар институт хезмәткәре, әдәбиятчы Шакир Абилов аркылы тапшырылганнар. Кабул итү кәгазендә кулъязмаларга кыскача тасвирлау бирелгән. Югарыда искә алынган кулъязмада Мәүла Колый һәм Габди хикмәтләре булу хакында язылса да, Рәхимкол бине Исламкол исемле шагыйрьнең исеме телгә алынмаган, шунлыктан аны бу хезмәттә әдәбият тарихына беренче мәртәбә кертелә дип санарга мөмкин.

Мөгаззәмә ханым — күренекле татар галиме Җәвад Алмазның апасы, алар Татарстанның Чистай төбәге Чиртүш авылыннан, дини гаиләдә туганнар. Димәк, алар кулында сакланган кулъязмалар да Кама аръягы төбәге белән бәйле.

Безне кызыксындырган кулъязмада Рәхимкол бине Исламколның бер әсәре — «Хикмәте Мәҗнүн» теркәлеп калган. Әсәрнең язылу тарихы күрсәтелмәгән. Кулъязманың кәгазенә караганда, ул җыентык XIX гасырның беренче чирегендә төзелгән, дөресрәге, күчереп яңартылган булырга тиеш. Җыентыктагы авторларның, әсәрләрендә искә алынган исемнәреннән тыш, тормышларына кагылышлы башка мәгълүматлар бирелмәгән. Ләкин анда күп кенә хикмәтләре теркәлгән шагыйрь Мәүла Колыйның тормышы Әлмәт, Лениногорск, Алексеевск, Норлат, Минзәлә төбәкләре белән бәйле булып, иҗаты нигездә шушы як кулъязмалары аша ачылганлыгын исәпкә алсак,

Рәхимкол бине Исламколның да бу өлкәдән чыккан шагыйрь икәнлеген фараз итәргә мөмкин. Моңа нигез булырлык кайбер дәлилләр дә бар. Мәсәлән, Әлмәт төбәгендәге Яңа Кәшер зиратында «Исламкол бине Туйкә хафиз» дип исемләнгән бер зур укымышлы, шагыйрь һәм галим кешегә XVIII гасыр урталарында куелган борынгы кабер ташы язмасы сакланган. «Хафиз» дип, гадәттә, XVIII гасыр ахырларына кадәр, татарлар арасында танылган галим һәм шагыйрьләрне атаганнар. Ихтимал, Рәхимкол бине Исламкол шушы Яңа Кәшер галименең баласы булса кирәк. Ни өчен дигәндә, «Хикмәте Мәҗнүн» авторының зур белемле шагыйрь икәнлеге әсәреннән үк сизелеп тора.

Рәхимкол бине Исламкол — XVIII гасыр урталарында яшәгән һәм иҗат иткән кеше. Ихтимал, киләчәктә аның әсәрләре тагы да табылыр әле.

«Хикмәте Мәҗнүн» әсәре суфыйлар арасында популяр булган «Ләйлә белән Мәҗнүн» мәхәббәте тарихыннан алып язылган. Бүгенге укучыларның суфыйлык йолаларыннан хәбәрләре булмауны исәпкә алып, Рәхимкол бине Исламкол әсәренә беркадәр аңлатма биреп үтү кирәк булыр.

«Хикмәт...» суфыйларның җомга көнне, гыйбадәт кылу максатында, хилкага (түгәрәкләнеп, бозра кебек тезелеп) утыру күренешеннән башлана. Анда Ләйлә белән Мәҗнүн дә килгән була. Хилкага килгән Ләйлә Мәҗнүннең мәхәббәтен кире кага, әмма егет аңа ачуланмый, сабыр гына тыңлап тора. Ләйлә, мин аның мәхәббәтен кире кагам, ул минем мәетемне дә күрергә тиеш кеше түгел, ди, һәм Аллага багышланган мөнәҗәтен укый. Халык бу эшкә хәйран калып тора.

Мәҗнүн исә, Ләйлә сүзләренә карамыйча, мәхәббәт — яхшы эштер, ул ризыклардан, җәннәттән дә өстендер, дип бәхәс итә. Халык аның сүзләренә дә хәйран кала.

Хилкада гыйбадәт башлана. Гыйбадәттә суфыйлар экстазга бирелеп көләләр, елыйлар, тәүбә итәләр, өч көн буена гыйбадәт бара. Шунда Ләйлә белән Мәҗнүн дә, туктаусыз, «Аллаһу» дип, дога кылудан һушсыз булып егылып яталар. Халык аларны һушсыз күреп, үлгәннәр, дип кайгыга

төшәләр, падишаларына хәбәр итәләр, ике кеше үлде, күмәргә ярыймы, дип сорыйлар. Падиша, сабыр итегез, күмми торыгыз, ди. Тагын өч көннән соң, Ләйлә белән Мәҗнүн акрынлап аңнарына киләләр. Икесе келәмдә утырып калалар да, Мәҗнүн Ләйләдән сорый, ни телисең, ди. Ләйлә, җәннәт телим, ди. Мәҗнүн аны тирги, ахмак син, Аллага якынлык хисең юк, әүвәл иман теләргә кирәк, байлыклар кирәкми, Хода каршында ярлы-юксылдан да якын кеше юк, дип, хәдис китерә.

Ике гашыйк шушы мәсьәләдә кайгырышып, җан-бәгырьләре көеп, җан бирәләр. Димәк, әсәрдә, мөселман кеше өчен иман — барлык ләззәтләрдән дә югары, дигән фикер уздырыла. Бу — Русия империясендә христиан диненә көчләп, мөселманнарны иманнарыннан аерырга тырышканда әйтелгән иң актуаль фикер булып саналган. Рәхимкол бине Исламкол, XVIII гасыр татар фикер ияләре Батырша, Әбүбәкер Теләчев, Бәхтияр Канкаевлар белән бер авыздан, «Иман — байлыктан бөегрәк» дип оран сала.

«Хикмәте Мәҗнүн» татар әдәбиятының XVIII гасырдан калган югары фикерле һәм көн темасына язылган кыйммәтле үрнәкләреннән берсе булып тора.

## Хикмәте Мәҗнүн

Хак Тәгалә итди мәрфуг ,
Ләйлә — Мәҗнүн улдый мәгъшук,
Бунлара булмадый мәсбук ,
Һу дәрди йады белән.
Сөйләшдиләр бер җомгада,
Ултырдыйлар коруб хилка ,
Дүндүрдиләр халүне хальга,
Һу дәрди йады белән.
Икүси мотыйгыйм улдыйлар,
Көлли госеркяри җыйдылар.
Дәвер кичиб улдурдыйлар,
Һу дәрди йады белән.
Килүб керди монда Мәҗнүн,
Зареб кыйлдый Ләйлә мескин,
Ачыйгланмый сабыр кыйлдый,
Һу дәрди йады белән.
Халайыклар калдый хәйран,
Сорашдыйлар хали заман,
Ләйлә кыйлдый хали игъләм ,
Һу дәрди йады белән.
Зареб кыйлдым ул мәхбүбем ,
Күрмәсен ахырда мәйтем,
Идәр Хакка мөнәҗәтүн,
Һу дәрди йады белән
Мәҗнүн әйди хушдур мәхбүб,
Тәгамдан әфзаль будыр мәзруб ,
Сиңа җәннәт булусун мәлсук ,
Һу дәрди йады белән.
Пелди бу хикмәти бәйан.
Халайыклар кыйлдый хәйран,
Биһуш улдыйлар мәкяндан 0,
Һу дәрди йады белән.
Халайыклар кайсы көлә,
Кайсы йыглап йәшен түгә,
Бәгъди хакка тәүбә кыйлә,
Һу дәрди йады белән.
Ул арада өч көн кичди.
Халыкларга кайгу төшди,
Ләйлә — Мәҗнүн вафат, дийү,
Һу дәрди йады белән.
Падишаһга килди хәбәр,

Ики кеши вафати вар,
Дәфен кыйлайыкму зинһар,
Һу дәрди йады белән.
Падишаһ айди , сабыр кирәк,
Дәфен кыйлу мөшкүлүрәк ,
Көйнеч илә йанмыш йөрәк,
Һу дәрди йады белән.
Өч көн андан тәмам кичди,
Гакыл гакыл өзә килди,
Икүләси келәм кыйлди,
Һу дәрди йады белән.
Диди Мәҗнүн, нә деләрсен?
Нә деләп, нә күрүрсән?
Ләйлә диди, кирәк җинан ,
Һу дәрди йады белән.
Мәҗнүн әйди, йук көтүнең,
Әһли бетмәй ахмаклыкың,
Йукдыр хакка мәкърунатың ,
Һу дәрди йады белән.
Әүвәлендә кирәк иман,
Теләмәдең ахмак инсан,
Барму сәндин фасикъ , гыйсьйан ?
Һу дәрди йады белән.
Диди, имди нә деләрсән?
Кирәкмү байлык, фәкыйрьлек?
Бу ирад , нә ихтыйар?
Һу дәрди йады белән.
Ләйлә әйдер, фәкыйрьмез милүк,
Уруның булыр түбәнчелүк,
Талак кыйлу һәм ноксанлук 0,
Һу дәрди йады белән.
Мәҗнүн әйдер, ахмак инсан,
Тукыйлгыл торма заман,
Эшең килебләрдин йаман,
Һу дәрди йады белән.
Хәлал малга хисабы вар,
Хәрам малга газабы вар,
Шөбһәлегә гыйтабы вар,
Һу дәрди йады белән.
Ишүт рәсүлнең хадисең,
Фәкыйрьдер бәнем шадлыгум,
Анлар иләдер сохбәтем .
Һу дәрди йады белән
Ишедди бәс Ләйлә моный,
Икәүси дийү йандый,
Бәгъри көйүб, чыкдый җаный,
Һу дәрди йады белән.
Анла моный гафил инсан ,
Йарлыкайа сәни гофран
Ләйлә — Мәҗнүн дик йан Локман
Һу дәрди йады белән.
Ушбуны йаздым фәкыйрь,
Рәхимкол бине Исламкол.

## ТАРИХЧЫ ПЕТР ИВАНОВИЧ РЫЧКОВ

Русиядә XVIII гасырда татар тарихына мөрәҗәгать иткән галимнәрдән Петр Иванович Рычков

истәлеге Әлмәт ягы белән бәйләнгән.

П. И. Рычков 1712 елның 1 октябрендә Вологда шәһәрендә туган. Ул гаиләдә бердәнбер бала була, зирәклеге белән аерылып тора. Сигез яшендә аны укырга бирәләр. Ул укырга-язарга, математикага, немец, голланд телләренә өйрәнә. Укуын тәмамлагач, аны Петербургта таможняда эшләргә калдыралар. Монда ул күренекле географ һәм картограф И. К. Кириллов белән таныша. Бу вакытларда Русия Казахстанны басып алуга хәзерлек алып бара, Урал елгасы буенда хәрби калалар кору кампаниясе башлана. Шуңа хәзерлек йөзеннән, Көньяк Уралга төрле фәнни экспедицияләр оештырыла. И. К. Кириллов яңа җирләрне колонизацияләүне оештыручыларның берсе буларак та мәгълүм. Ул үзенең эшләренә П. И. Рычковны да җәлеп итә. Бу дәвердә Ор елгасының Җаекка кушылган җирендә хәрби кала — Оренбургны салуга хәзерлек барган.

П. И. Рычков, шул дәвердә оештырылган экспедицияләрдә катнашып, күп кенә кызыклы мәгълүматлар туплый. Ул аларны «Оренбург тарихы», «Казанның борынгы һәм урта гасырлар тарихын язу тәҗрибәсе», «Оренбург топографиясе», «Татар-калмык лексиконы» һ. б. хезмәтләрендә бәян итә.

Шушы фәнни хезмәтләре өчен П. Рычковны зур исемнәргә тәкъдим итәләр. Ул 1759 елда Петербург Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы дигән фәнни дәрәҗәгә лаек була.

П. И. Рычков 1750 елда Академиягә татарлар турындагы фәнни хезмәтен язып җибәрә, татар-калмык мәктәпләре оештыра, алар өчен уку ярдәмлекләре төзи һ. б.

Ул 1760 елда отставкага чыга һәм Бөгелмә янындагы үзенә бүләк итеп бирелгән җирдә Спасское утарын төзетеп, килеп урнаша. Шул чорда П. И. Рычков җирле нефть ятмаларын өйрәнү эшен дә башлап җибәрә.

Петр Иванович Рычков 1777 елның мартында Екатеринбург заводлары идарәсенә башлык итеп җибәрелә, ләкин өлкән яшьтә булуы аңа эшләргә ирек бирми, һәм ул 1777 елның 15 октябрендә үлә. Васыяте буенча аны Бөгелмә янындагы Спасское утарына кайтарып күмәләр.

## «История Оренбургская» исемле китаптан

...Бу вакыйганың язмасын миңа старшина Кадрәс Муллакаев «Татар тарихы» дигән китаптан күрсәткән иде. Әлеге тарих башкорт чуалышлары вакытында югалган.

...Кырым ягындагы Кече Татар илендә Басман исемле нугай ханы яшәгән. Кайчандыр (аның кай вакытларда булуын инде хәтерләмиләр), илдә үләт зәхмәте чыгып, ул хан, үзенең җәйләүләрен ташлап, унҗиде мең тирмәдән торган халкы белән Җаек елгасы буена күченеп килә һәм аңа койган Сакмар елгасы тамагындагы тауда Актүбә исемле кала корып яши башлый. Бу урын хәзерге Оренбург шәһәреннән алты чакрым ераклыкта, маяк урнашкан җирдә була. Шунлыктан бу тауны хәзер дә, борынгы шәһәр исеме буенча, Актүбә дип атыйлар, һәм анда борынгы корылмаларның җимерекләре әле дә саклана. Бу урында ханның төп җәйләве булып, тирмәләре Җаекның һәм аның төрле кушылдыкларының буйларында түбәннән алып югарыга кадәр күченеп йөргәннәр. Алар, аерым алганда, Бирде, Сакмар, Салмыш, Йушатыр, Ор, Таналык, Кызыл һ. б. елгалар буенда җәйләгәннәр. Кышын исә, Урал тауларын үтеп, урманлы һәм җылырак (ышыграк) урыннарда —Агыйдел, Сонеле, Ашкадар, Куганак, Шкадер, Дим буйларында кышлаганнар.

Басман хан кул астында ике атаклы нугай морзасы — Алтакар һәм Битүрәк яшәгән. Көннәрдән бер көнне әлеге ике морза арасына дошманлык уты төшеп, һәр ике тарафны да яндыра-көйдерә башлый. Морзалар ханга шикаять бирәләр, хан, бәхәсне карап, Алтакарны гаепле дип хөкем чыгара. Морзаның моңа бик ачуы чыгып, үзенең берничә йөз тирмәсе белән ханнан аерылып, Җаек елгасының аръягына чыгып китә һәм Җим суы буенда ил тотып яши башлый. Алтакар анда бик нык көчәеп китеп, Басман хан җәйләүләренә даими һөҗүм итә: аның илен бөлдерергә тотына. Шундый һөҗүмнәрнең берсендә күп кенә нугайларны һәм ханны да үтерә. Аларның мәетләре хәзерге Оренбург шәһәре урнашкан тауда күмелгән. (Ул урын хәзер «Верхняя Губернская улица» дип атала.) Хан кабере өстенә ташлардан төрбә корылган булган. Аның эзләре тау буенда әле дә беленеп тора. Оренбург каласын корган вакытта ул каберлек яхшы сакланган, һәм анда гарәп язулы төрле ташлар шактый булган.

Безгә бу мәгълүматларны биргән старшина Кадрәс Муллакаев сүзләренә караганда, Басман ханның туганы Түрә хан була. Ул хан хәзерге Уфа шәһәре тирәсендәге җирләрне биләп торган, һәм аның кул астындагы халык, Казан юлы буенча, Дим тамагыннан алып Агыйделнең түбәнге агымы, Карамасан, Чирмешән, Куюш, Базы, Сөн елгалары һәм Әй елгасының югарыгы агымы буйлап күченеп йөреп гомер иткәннәр. Чуалышлар вакытында Түрә хан да үтерелә, һәм Алтакар морза барлык нугайларның хакиме булып кала. Шуннан соң берничә ел үткәч, Алтакарны

борынгы ханнар нәселеннән булган Акйазар солтан үтерә. Аннан Акйазар солтан көчәеп китеп, нугайларны гына түгел, башкортларны да үзенә буйсындыра. Моннан тыш ул Казан, Себер, Әстерхан ханлыкларын, Бохара, Хива, Ташкент һәм башка бик күп шәһәрләрне басып ала һәм үзенә ясак түләтә. Акйазар солтан үзенең бертуган сеңлесен Шәйех Мамай исемле бер шөһрәтле нугай морзасына кияүгә бирә һәм алар кул астына берничә йөз тирмә нугайларны да тәгаенли. Шәйех Мамай морза үзенең кешеләре белән Кириллов тарафыннан башта Оренбург каласы буларак корылган Ор (хәзерге Орский шәһәре) каласы эчендәге Преображенское тавында яшәгән. Ул тау әүвәлге заманда изге саналып, анда намаз укыла торган урын була, шунлыктан бу җирне «Намаз тавы» дип йөргәннәр...

## ШАГЫЙРЬ ҺӘМ ГАЛИМ
## ГАБДЕРӘХИМ УТЫЗ ИМӘНИ ӘЛ-БОЛГАРИ

Габдерәхим Утыз Имәни — татар әдәбияты тарихында зур эз калдырган шәхес. Аның әсәрләре, кулъязмалар рәвешендә, халык арасында XIX гасырның беренче яртысында ук киң таралганнар, шагыйрь турында төрле риваятьләр, мәзәкләр әле бүген дә халык телендә яши, китаплары да басылгалаган.

Аның турында татар әдәбиятының беренче тарихчылары Шиһабеддин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Ризаэддин бине Фәхреддин, Гали Рәхим, Г.Газиз һәм соңгырак дәвердә Үлмәс Биляева, Әнвәр Шәрипов кебек галимнәр күп хезмәтләр калдырдылар.

Аларның хезмәтләренә карап фикер йөрткәндә, Габдерәхим хәзрәтләре шагыйрь, философ, табиб, китаплар күчереп язучы, татар әдәбиятының беренче текстологы, дин эшлеклесе һәм педагог буларак күз алдына килә. Габдерәхим хәзрәтнең тормышы һәм иҗаты хакындагы бу кечкенә генә мәкаләне без әдәбият галиме, мәрхүмә Үлмәс Биляева хезмәтеннән файдаланып яздык .

Шагыйрьнең бабалары Лениногорск төбәге Тимәш авылы халкыннан булганнар.

Габдерәхим бине Госман бине Сәрмәкәй бине Кырым 1754 елда, ул вакыттагы Казан губернасы Чистай өязе Утыз Имән (хәзерге Татарстан җөмһүриятенең Чирмешән төбәге Яңа Кади) авылында туган. Аның әтисе Тимәш авылыныкы булып, улы туганчы үлеп китә. Әтисе үлгәч, әнисе туган авылы Утыз Имәнгә китеп, Габдерәхим шунда дөньяга килә. Озак та тормый анасы да үлеп, ул тулы ятим булып кала. Авыр тормыш яшь баланы, гәрчә ул туганнары арасында булса да, әйләнеп узмый. Кыенлык белән үскән Габдерәхимне, уку яшенә җиткәч, Утыз Имәндәге Вилдан мулла мәдрәсәсенә бирәләр.

Габдерәхим бик зирәк бала булып, белемнәрне җиңел үзләштерә. Ул үз якларындагы атаклы мәктәпләрне укып чыга да Оренбург Каргалысындагы мәдрәсәгә барып керә.

Габдерәхимнең 1788 елга хәтле булган тормыш юлы да, иҗаты да җитәрлек мәгълүм түгел. Ихтимал, ярлы, ятим егет Пугачев хәрәкәте вакытында кулына корал алып ирек өчен көрәшкәндер. Халык кузгалышы бастырылгач, Габдерәхим, күп меңләгән татар егетләре кебек, Урта Азиягә китә. Ул анда озак еллар дәвамында яши: Һиндстан, Әфганстан, Иран якларында тора, укый, табиблык эшенә өйрәнә. Аның шул ук вакытта берничә тапкыр туган якларына кайтып килүе дә мәгълүм. Шагыйрьнең язмаларыннан күренгәнчә, ул 1788—1789 елларда Бохарада, Сәмәркандта, Акчада, Туфида, Мәзаре Шаһимәрдан шәһәрләрендә, 1796 елда Һиратта, 1798 елда Бәлехтә була. Бәлех шәһәрендә хатыны Хәмидә үлгәч, Габдерәхим Утыз Имән авылына кайта. Атасы Тимәш авылыныкы булганга күрә, анда аңа җир бирелмәгән. Ул шуннан соң Исләй, Сарабиккол, Куакбаш авылларында мәдрәсәләр ачып укытып йөри. Габдерәхим хәзрәт картлык көннәренә кадәр иҗат эше белән шөгыльләнеп, укытып, китаплар күчереп язып көн иткән һәм 1834 елда сиксән яшендә үлгән.

Габдерәхим Утыз Имәнидән татар, гарәп, фарсы телләрендә язылган зур мирас калган. Ул шагыйрь һәм шул ук вакытта фикер иясе буларак та эш иткән. Габдерәхим хәзрәт, Габденнасыйр Курсави кебек үк, кешенең дөньяны танып белүдә мөмкинлекләре чиксез, дигән караштa торган. Аның бу фикерләре урта гасырчылык белән миләре катып калган консерватив муллаларның ярсуын чыгарган. Галимнең бу фикерләрен бәян иткән «Мөһиммәт-эз-заман» («Заманның мөһим билгеләре»), «Тәнзиһ әл-әфкяр фи нәсаих-әл-әхйар» («Фикерләрне сафландыручы кирәкле киңәшләр»), «Фасыл фи фазыйләт әл-гыйлем вәл-гакыл» («Гыйлем һәм гакылның өстенлеге турында бүлек») әсәрләрендә һ. б. тасвирлана. Шагыйрьнең 1798 елда хатыны Хәмидә үлүгә карата язылган мәрсиясе, чәй эчүгә карата язылган шигырьләре һ.б. әсәрләре халык арасында кулъязмалар рәвешендә киң таралган. Әдәбият галиме Әнвәр Шәриповның эзләнүләре

нәтиҗәсендә, шагыйрьнең 3 поэмасы, 15 чәчмә әсәре, 10 гыйльми хезмәте текстлары мәгълүм. Әле табылмаган 12 әсәренең исеме сакланган. Моннан тыш тагы 12 исемдәге әсәрнең Габдерәхим Утыз Имәни кулы белән язылганлыгын дәгъвә итүчеләр бар.

Шагыйрьнең шигырьләре тирән фикерләргә, образлы тасвирлауларга бай. Мисалга аның «Мөнәҗәт» шигыреннән берничә юл:

Илаһи, әйләмә мохтаҗ
Шул дүрт адәм капусына:
Бери — казый, бери — вәли,
Бери — мөфти, бери — солтан.

Яки «Әбйате төрки фи фазыйләте гыйлем» шигырендә гыйлемлекне югары күрсәткән юллар бар:

Һәркемнең кем гыйльме чукдыр — байдыр ул,
Барчалар йолдыз кебидер — айдыр ул.

Шагыйрьнең дөньяны, тормышны яратуын раслап язган шигыре:

Бонча еллар йилмәк илән
Дөньядан һич туймадым.
Нәфес хәззын ихтиарән
Бер минутка куймадым.

Хәзерге телгә тәрҗемәсе:

Никадәр еллар яшәп тә,
Дөньядан һич туймадым.
Нәфсемне үз иркенә
Бер минутка куймадым.

Габдерәхим Утыз Имәнинең иҗаты әдәби мирасыбызның алтын хәзинәсенә керде.

## Мәрсия

Кичәләрне йите бүлгән,
Мәнем өчен уйагъ торган,
Кечеклекдә сөтен биргән
Шәфикамдин җөда булдым.

Намаз куйма, дәйү сүккән,
Сабак куйма, дәйү орган,
Уен өчен каһәр кыйлган
Миһербандин җөда булдым.

Нәсихәт сүзләрен айган,
Бәңа яхшы дога кыйлган,
Нәчә йөз мең хәтем кыйлган
Шәфикамдин җөда булдым.

Тәгаммени пешек кыйлган,
Либасемни төзек кыйлган,
Черек җәмам алып юган
Шәфикамдин җөда булдым.

Күзем нуры — балам, дигән,
Мөлаемлык бәңа кыйлган,
Яман эшдин мәнгъ иткән
Миһербандин җөда булдым.

Кичә-көндез гамем йигән,

Күңел эчрә нурым, дигән,
Бәгъәл эчрә дөррем, дигән
Гъәлафемдин җөда булдым.
Шигырьнең хәзерге татар әдәби теленә юлга-юл күчермәсе:

Кичәләрне җиде бүлгән,
Минем өчен уяу торган,
Сабый чакта сөтен биргән
Шәфкатьлемнән аерылдым.

Намаз калдырма, дип сүккән,
Сабак калдырма, дип орган,
Уен өчен каһәрләгән
Миһербанлымнан аерылдым.

Нәсыйхәт сүзләрен әйткән,
Миңа яхшы теләкләр теләгән,
Ничә йөз мең боерык биргән
Шәфкатьлемнән аерылдым.

Азыгымны пешереп торган,
Киememне төзәтеп торган,
Керле күлмәгемне алып юган
Шәфкатьлемнән аерылдым.

Күзем нуры — балам, дигән,
Мөлаемлык миңа кылган,
Яман эштән мине тыйган
Миһербанлымнан аерылдым.

Кичә-көндез мине кайгырткан,
Күңелемнең нуры, дигән,
Куенымдагы энҗем, дигән
Караучымнан аерылдым.

## ТАҖЕДДИН ЯЛЧЫГОЛ УГЛЫ ӘЛ-ИШТӘКИ ӘЛ-БОЛГАРИ

Таҗеддин Ялчыгол углының яшьлек еллары һәм кай якта туган булуы тарихның бер сере булып калган. Үз гомерендә ул берничә китап язып, татарлар арасында шактый шөһрәтле язучы булып танылып калды.

Әдәбият галимнәренең язуларына караганда, ул 1767—1768 елларда Әй буе башкортлары арасында туган булып санала. Ләкин аның нәсел ягыннанмы, әллә катлау (сословие) ягыннанмы башкорт булып саналуын ачыклап булмый. Үзенең «Тарихнамә-и Болгар» исемле әсәрендә Таҗеддин Ялчыгол углы нәселе турында «болгарлык иштәкмен» дип атый, башкорт дип санамый. Әл-Башгори исемле тәхәллүс, аның бары тик Башгор дип аталган географик төшенчәгә нисбәтен белдерә. Таҗеддин Ялчыгол углы тарафыннан язып калдырылган «Тарихнамә-и Болгар» исемле хезмәттә Идел — Урал арасында XV—XVII гасырларда яшәгән Нугай Урдасы татарлары нәселенә кагылышлы информацияләр саклanган. «Тарихнамә-и Болгар» әсәре Таҗеддин Ялчыголның нәсел шәҗәрәсе рәвешендә язылган. Академик М. Госманов, әлеге язманы тикшереп, аның төрле уйдырма фактлардан торганлыгын исбатлады.

Таҗеддин Ялчыгол углының балалык һәм яшьлек еллары ачык түгел. Бу дәвердә ул әтисе белән хаҗ юлында йөргән, Төркиядә, Кавказда яшәгән кеше итеп санала. Ләкин бу язмаларны өйрәнүчеләр Таҗеддин хәбәрләренең очы очка ялганмаганлыгына игътибар итәләр.

Аның тормышының реаль сәхифәләре XVIII гасыр ахырыннан башлана. Алар «хаҗ»дан кайтып килгәндә, Таҗеддиннең атасы Ялчыгол Нократ буендагы Кече Сөн авылында үлеп кала. Атасы

үлгәч, улы Минзәлә ягындагы Җирекле, Кызыл Кыпчак, Мәлем, Тымытык авылларында укыту, дәвалау-табиблык эшләре белән көн күрә. 1838 елда, авырулар дәвалап йөргәндә, Зәй елгасы буендагы Имәнлебаш авылында үлеп кала, кабере шунда.

Таҗеддин Ялчыгол углының халык арасында иң таралган әсәрләре — «Рисаләи Газизә» һәм «Һәфтияк тәфсире» китаплары. Болардан «Рисаләи Газизә» әсәренең күпсанлы кульязма нөсхәләре археографик экспедицияләр дәверендә табылды. Әсәр дистәләрчә мәртәбә басылып та чыккан.

«Рисаләи Газизә» әсәре XVII гасырда Бохарада яшәгән татар шагыйре Суфый Аллаһиярның «Сөбател-гаҗизин» исемле әсәренә язылган тәфсилле аңлатмадан гыйбарәт. Таҗеддин, үз әсәренә төрле гыйбрәтле хикәяләр кертеп, авыр аңлаешлы әсәрнең фикерен җиңел һәм мавыктыргыч итеп шәрехли. «Рисаләи Газизә» — татар арасында суфыйчылык агымының тарихын ачарга ярдәм итүче әдәби-публицистик әсәр. Анда шулай ук татар әдәбияты тарихына, иҗтимагый хәрәкәткә караган мәгълүматлар да очрый.

Таҗеддин Ялчыгол углының моннан башка да язган хезмәтләре бар, ләкин алар әлегә өйрәнелмәгәннәр. Язучының мирасы хакында Ш. Мәрҗани, Р. Фәхреддин, Г. Газиз, Гали Рәхим, М. Гайнетдиновларның фәнни хезмәтләре мәгълүм.

## «Рисаләи Газизә» әсәреннән

*(хәзерге телгә күчермә)*

...Мәккәнең Хаҗаҗ исемле падишасы бер көнне атка менеп сәхрәгә чыкты. Юлда бер кешенең бакчасы яныннан үтеп бара иде, бакчаның хуҗасы бакчасына су җибәреп, ул ташып урамга чыкты. Юлның кайбер җирләре сазлыкка әйләнеп торды. Хаҗаҗның аты сазга таеп егылды да, патша шунда аягын сындырды. Вәзирләр Хаҗаҗны күтәреп сараена алып кайттылар.

Патшаның мондый күңелсез эшкә кәефе кырылып: «Билләһи газыйм, ул бакча иясен үтерәм мин, чөнки бу кеше мөселманнар юлына су агызып, зыян ясады», — дип фәрман чыгарды.

Бакча иясен кулга алып, патша каршына китереп бастырдылар. Хаҗаҗ аңа: «Ни өчен мөселманнар юлына су агызып баткак ясадың?» — диде. Бу кеше: «Бакчадагы суны мин махсус чыгартмадым, аннан артык су агып ташыган», — диде. Хаҗаҗ: «Бу адәмне барыбер үтерергә кирәк», — дип кырт кисте. Бакча иясе елап: «Өч кечкенә балачыгым хакына гафу әйлә», — дип ялварды. Патша:«Балаларыңа казна малы биреп тәрбияләрбез», — дип җаваплады. Бакча иясе: «Пәйгамбәрләр нәселеннән мин, аның хакына гафу ит», — диде. Хаҗаҗ аның бу сүзен ишеткәч, гафу итте.

Шул вакытларда Хаҗаҗның бер вәзире үлеп, ул аның урынына бакча иясен вәзир кылды. Вәзирне тәрбияләп, эшкә өйрәтте. Ул бакча иясеннән вәзир булган кешенең исеме Шәмгун иде...

...Көннәрдән бер көнне Хаҗаҗның ишек төбенә бер теләнче килеп: «Ходай хакы өчен ни дә булса бирегез, ачмын», — дип ялварды. Патша ул вакытта хәлвә ашап утырыр иде, башындагы таҗыннан бер асылташ алып, аны хәлвә эченә яшереп, Шәмгунга: «Бар, боларны теләнчегә бир», — диде. Шәмгун, теләнче янына килеп: «Падишаһ сиңа бер йомарлам хәлвә бирде, син моның белән нишлисең инде! Мин хәзер сиңа көн буена җитәрлек ризык бирермен, ә хәлвәне миңа бир!» — диде. Теләнче риза булды, көнлек ризыгын күтәреп чыгып китте. Шәмгун хәлвә эченнән асылташны алып, ризыкны ашап бетерде.

Икенче көнне теләнче яңадан Хаҗаҗ падишаһ йортына килде, Хода хакына ризык сорады. Патша, баягы кебек, таҗыннан тагын бер асылташны алып, хәлвә эченә салып, Шәмгунга: «Теләнчегә боларны бир», — диде. Шәмгун исә яңадан бер көнлек ризык биреп, асылташлы хәлвәне алды.

Теләнче шуннан соң патша катына өченче мәртәбә килеп, Хода хакына, ашарга ни дә булса бирүләрен сорады. Хаҗаҗ теләнчене күреп, аңа: «Ни өчен һаман теләнеп йөрисең, мин бит сиңа бер падишаһ милкенә торырлык хәзинә бирдем?» — диде. Теләнче: «Нәрсә бирдең?» — дип сорады. Патша: «Хәлвә эченә ике асылташ салып бирдем», — диде. Теләнче Шәмгунның аларны үзеннән алдап алганлыгын әйтте. Хаҗаҗ, нык ачуланып: «Бу кеше пәйгамбәрләр нәселеннән түгел, андый нәселдән булса, дөрес сөйләшүче һәм гадел булыр иде. Ул ялганчы һәм хыянәтче икән!» — дип, вәзиренең башын кистерде. Шуннан соң патша Мәккәдә булган барлык пәйгамбәрләр нәселеннән мин дип дәгъва итүчеләрнең, ялганчылар дип, башларын кистереп, кырып бетергән...

## ХИСАМЕДДИН МӨСЛИМИ ҺӘМ АНЫҢ «ТӘВАРИХЕ БОЛГАРИЯ» ӘСӘРЕ

Татар язма культурасының бер ядкәре булган «Тәварихе Болгария» әсәре узган гасырның беренче яртысыннан бирле зыялы җәмәгатьчелегебезнең игътибарын үзенә җәлеп итеп килә. Бу игътибарның төп билгесе — әсәрнең дистәләрчә кулъязма нөсхәләрдә саклануы, таралуы дип уйларга һәм күрсәтергә тулы нигез бар.

XIX гасырның икенче яртысында аңа урыс тарихчысы С. Шпилевский һәм бераз соңрак татар тарихчысы Ш.Мәрҗани игътибар итәләр. Беренчесе бу әсәргә чын тарихи чыганак дип якын килсә, икенчесе аның тарих икәнлеген инкярь итеп чыга. Тарихчы галимнәрнең капма-каршы фикерле бәяләренә дә карамастан, «Тәварихе Болгария» әсәренә карата укучының игътибары кимемәде. Казан басмаханәләрендә аның 1870, 1887, 1902 елларда өч мәртәбә басылып чыгуы, укылуы татар китап репертуарында әсәрнең саклануы хакында сөйли.

Озак еллар дәвамында «Тәварихе Болгария»гә карата бәядә әдәбият белгечләребез Ш.Мәрҗани дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә алмадылар, аның материалына сукырларча иярү генә булды. Шулай ук Татарстан тарихчылары да аңа карата бернинди тәнкыйди якын килү мөнәсәбәте күрсәтмәделәр. Моны безнең гасырның 40—60 нчы елларында чыккан фәнни басмалар мисалында күрергә

мөмкин . Билгеле, бу өлкәдә «Тәварихе Болгария»нең текстологик яктан эшләнгән фәнни-тәнкыйди тексты булмау да торгынлыкка сәбәпче булгандыр.

1927 елда татар графикасы өстән кушып, мәҗбүри рәвештә латин (яңалиф) язуына алыштырылганнан соң да, ул дәвердәге татар укучылары «Тәварихе Болгария» китапларын үзләренең кадерле «Коръән тәфсире», «Мөхәммәдия», «Кыйссаи Йосыф», «Һәфтияк», «Ясин», «Бәдәвам» китаплары белән бергә саклыйлар, укыйлар һәм үзләре төзегән авыл тарихларына тарихи чыганак итеп файдаланалар. Бу китап, шулай итеп, чыганак буларак кимчелекле булса да, 1927 елдан соң бөтен яктан: фәннән, язма мирастан мәхрүм ителгән татар халкының тарихи, иҗтимагый һәм дини-фәлсәфи аңын саклауга ярдәм иткән китапларның берсе булды. Шул әсәргә карап, халкыбыз үзенең әлмисактан бирле мөселман икәнлегенә ышанды, тоталитар режимның иң караңгы елларында да иманын ташламады. «Тәварихе Болгария»нең Ш.Мәрҗани күрсәткән әсасле (нигезле) кимчелекләренә карамастан, әсәр сакланды. Ул вакытларда «Тәварихе Болгария»гә карата яшәп килгән каршылыклы карашлар әсәрнең жанры ачык билгеләнмәгәнлектән һәм халык алдында куелган проблемалары ачылмаганлыктан гына тудылар.

«Тәварихе Болгария» әсәрен Ш.Мәрҗанидән соң фәнни тикшеренү объекты итеп өйрәнү 1960 еллар ахырында гына башланды. Бу эшкә башлап керешүче тарихчы галим Миркасыйм Госманов булды. Аның тарафыннан әсәр тарихи чыганак буларак тәфсилле һәм этрафлы өйрәнелеп, әсәрнең кайсы жанрга керүе ачыкланды. Бу тикшерүченең хезмәте «Тәварихе Болгария» әсәре тарихмы, юкмы, дигән сорауга ачык җавап бирде. Әсәр — тарих түгел, ә бәлки әдәби-тарихи жанрга мөнәсәбәтле, дигән нәтиҗәгә килендe.

Ләкин, бу хезмәттә дә, «Тәварихе Болгария» әсәрендә нинди проблемалар күтәрелгән, ул ни өчен язылган, дигән сораулар җавапсыз калды. Хәер, аларны ачу тикшерүче тарафыннан максат итеп куелмаган да иде.

Үзенең структур төзелеше һәм исеменә уелган дәгъвасы белән «Тәварихе Болгария» әсәре беренче карашка тарихны чыннан да бик нык боза. Ләкин бу әле аңа карата әйтелгән соңгы хакыйкый фикер дигән сүз түгел.

«Тәварихе Болгария»нең кайсы дәвердә һәм нинди максат белән язылу сәбәбе киная белән «икълим»нәргә, ягъни географик урыннарга күзәтү ясалган бүлегендә ачыла. Әсәрдә тасвир ителгән географик тарихи мохит яңа дәвергә — XVIII йөзгә тәңгәл килә. Автор үзенең Русия империясе составындагы җирдә яшәгәнлеген сиздереп тора. Ул Себер, Кытай якларын, Балтыйк буен, Европаны тасвирлаганда, топономик атамаларны күбрәк урыс телендәге тәгъбирләр белән бирә. Мәсәлән: Пекин, Лена елгасы, Архан кальгасы, Кытай диңгезе, Рим, Латыш кальгасы, Киев кальгасы, Волга елгасы, Ока елгасы һ. б. Идел—Урал, Көнбатыш Себер географиясенә караган гидронимнар һәм топонимнар татар телендәге атамалар белән бирелгән.

Мөслими үзенең әсәрен, Ташбилге авылында (хәзерге Әлки районында), һиҗринең 992 елында яздым, дисә дә (1584 елга туры килә), аның сюжетындагы XVII—XVIII гасырларга караган тарихи фактлар (мәсәлән Идрис хафизның Өфе йортыннан кыйнап җибәрелүе, 1584 елда әле исән булган Касыйм бине Ибраһимны үлде дип раслау, XVIII гасырда гомер иткән Надир шаһны Аксак Тимер белән бәйләү, 1791 елда үлгән татар язучысы һәм педагогы Ирнияз (Ишнияз) бине Ширниязны

«Тәварихе Болгария» әсәре язылганчы ук (1584) үлде дип искә алу, ниһаять, бу әсәрнең фәкать XIX гасырның 30 нчы елларыннан соң гына кульъязмалары мәгълүм булу һ.б.) аның 1796 еллардан да иртә язылмавы ягын куәтлиләр.

«Тәварихы Болгария» әсәренең нинди максат белән язылганлыгын тәфтишләү өчен, тагын бер өстәмә сорауга җавап бирергә кирәк.

XVIII гасырда яшәгән татарлар тарихларын шулкадәр буталчык рәвештә, мантыйкка сыймаган хронологик дәвердә күз алдына китерделәр микәнни соң, дигән сорау туа. Шул сорауга җавап эзләп карыйк. Татар галимнәре кулында XVIII гасырда ук Әбелгазый Баһадир ханның «Шәҗәрәи төрек», Кадыйр Гали бәкнең «Җамигъ әт-тәварих», «Дербентнамә», «Угызнамә» әсәрләре; Адәм галәйһиссәламнең, Чыңгызханның, фарсы, төрек солтаннарының шәҗәрәләре, татар биләренең, тарханнарының зур шәҗәрәләре, елъязмалар, «Дәфтәре Чыңгызнамә», дастаннар, ярлыклар, документлар булу — бу халыкның тарихтан нык хәбәрдар булуы хакында сөйли. Урыс тарихчыларыннан Петр Рычков һәм Карл Фуксның әсәрләре дә шул фикергә куәт хасил

итәләр, һәм әлеге тарихчыларның хезмәтләре 1817 елга хәтле басылса да, «Тәварихе Болгария»не искә алмаулары Мөслими хезмәтенең соң төгәлләнүен һәм бүтән максатны күз алдында тотып язылуын күрсәтә. Мөслиминең замандашлары бу тарихның нәрсә икәнен һәм ни өчен язылганын яхшы аңлаганнар. Шунлыктан ул әсәрне тарихи тәнкыйтькә дә дучар итмәгәннәр диярлек. «Тәварихе Болгария» әсәренең максаты XVIII гасыр ахыры — XIX гасыр башында зур галим һәм шагыйрь Габдерәхим Утыз Имәнине һ. б. борчыган көчләп чукындыру, мөфтилек оешу, шәригать, Коръән кушкан сөннәт фарызларның үтәлешенә мөнәсәбәтне ачыклау була. Әлбәттә, Мөслими үзенең хезмәтен патша самодержавиесе ялчысы булган Мөхәммәдҗан әл-Борындыкый кебек мөфтиләрнең күзенә чалынмаслык итеп эшләгән.

XVIII гасырның ахырына мөселман татарларда дини белем бик йомшара. Мәчетләр тотарга ярамагач, күп фарыз эшләр үтәлми киленә. Җомга һәм гаед намазлары укуларга мөмкинлек булмагач, халык инде аларны үтәүне авырсына башлый. Моның бик ачык мисалын Габдерәхим Утыз Имәни хакында язып алынган бер тарихи риваятьтән күрергә мөмкин:

«...Габдерәхим хәзрәтне Тимәш авылына имам итеп чакыралар. Ул анда барса, мәчеткә өйлә намазына да йөрүче булмый. Шуннан соң, Габдерәхим хәзрәт мәчеттән чыга да кешеләрне күзәтә башлый. Авыл ирләре якындагы кабакка йөри торган булалар. Габдерәхим хәзрәт шунда бер Ибрай дигән кешенең кабакка таба барганын күрә дә аны үз янына чакыра. Аңа әйтә: «Әйдә, Ибрай, минем белән өйлә намазын укырга кер!» — ди. Тегесе: «И хәзрәт, тәһарәтем юк бит минем»,— ди. Габдерәхим аңа: «Әйдә, тәһарәтсез генә укырсың!» — ди. Шулай итеп Габдерәхим хәзрәт Ибрай белән өйлә намазын тәһарәтсез укыйлар. Әкренләп, хәзрәт бөтен Тимәш халкын мәчеткә туплап, тәһарәтсез генә намаз укыта башлый. Аның дошманнары мөфтигә шикаять язалар: «Габдерәхим хәзрәт халыкны тәһарәтсез генә намаз укырга өйрәтә», — дип. Хәзер мөфти бер яшь кешегә указ тоттырып, хат язып, Габдерәхим хәзрәтне алыштырырга җибәрә. Теге кеше килә, Габдерәхим хәзрәт аны кабул итә, язуларын укый да әйтә: «Менә хәзрәт, халыкны мәчеткә йөрергә мин өйрәттем, тәһарәт алырга син өйрәт инде алайса», — дип, үзенең урынын указлы имамга бирә...»

Мөселманнар яшәгән авыл-шәһәрләрдә тәртипле эшләп килгән мәдрәсәләр булмагач, халык арасында дини тәгълиматтан, аның йолаларын аңлаудан мәгълүмат кими, наданлык көчәя. Яңа ачылган мәдрәсәләрдә укыту өчен хәзерлекле хәлфәләр булмый, кем ничек, нәрсә белсә, шулай укыта.

Пугачев күтәрелеше бастырылгач, дини хөррият бирелсә дә, колониаль администрация ул «хөррият»нең дилбегәсен үз кулында тота: Оренбург мөселман дини идарәсе оештырып, аның мөфтие итеп үзенә турылыклы кешене билгели. Киләчәктә шул ялчы агент аркылы мөселманнарны империя колы ясарга карар бирә. Һәрбер мулла, үзенең вазифасын башкару өчен, мөфтидән указ алырга тиеш була. Әлбәттә, мөселманнар бу дини идарәнең ни икәнен шундук сизеп алалар, һәм татар җәмәгатьчелегендә моңа каршы хәрәкәт башлана, әсәрләр языла. Килеп туган яңа сәяси вәзгыять шартларында татар ислам руханилары ике лагерьга бүленәләр: указлы муллалар һәм мөфтигә буйсынырга теләмәгән — указсыз муллалар төркемнәре барлыкка килә.

«Тәварихе Болгария» авторы мөфтилек оештыру һәм аның башына надан руханилар билгеләүдә указлы муллалар лагеренда татар мөселманнар өчен куркыныч күрә, динне бозу дип кабул итә. Бу кризистан чыгу юлын ул Урта Азия мөселманнары ярдәме белән генә мөмкин дип саный. Урта Азия мөселманнарының куәтен ул җыелма образ — Миртимер мисалында күрсәтә. Миртимер (Аксак Тимер) образы мөселманлыкның төп сакчысы — символы итеп тасвирлана. Аңа каршы булган Рум солтаны — Мәһди образы аша Хисамеддин Мөслими Русия империясенең

мөфтиен күз алдында тота. Мәһди исеме бу очракта үзе генә дә гыйсьянчы, исламга каршы дигән мәгънә төсмере ала.

Мәһди (мөфти) образы оппонентларны гаепләүдә мөселман дөньясы өчен хас булган ысуллар аша күрсәтелә, тасвирлана. Мәсәлән, «Тәварихе Болгария»дә Истанбул солтаны Мәһди һәм аның яраннары пәччәбазлык (гомосексуализм) белән шөгыльләнәләр, дип бәян кылына. Әлеге теманың тамыры феодализм дәвере төрек әдәбиятының классик әсәре «Кыйссаи Сәйед Баттал газый» романына барып тоташа. Ул әсәрдә дә ислам диненең сафлыгы һәм даны, аны тарату өчен көрәшүче Сәйед Баттал газый пәччәбазлык белән шөгыльләнүче Румдагы Милатия каласы солтаны Миһри Йайыл һәм аның бикләрен һәлак итә. Андый шәригатькә сыймаган эшләр белән мөселманнар түгел, кяферләр шөгыльләнә, дигән фикер үткәрелә.

«Тәварихе Болгария»дә дә мондый эш белән шул ук Румның башкаласы Истанбулдагы Мәһди солтан һәм аның егерме биге шөгыльләнгән итеп сурәтләнә. Аларны җәзага тартуны бу юлы Алла тарафыннан миссия йөкләнгән Сәйед Баттал газый ролен, шулай ук Алла кушуы буенча пәччәбазлыкны һәм кяферлекне юк итүче Аксак Тимер (Миртимер) башкара. Аксак Тимер үзе йөргән башка урыннарда мондый гадәткә тап булмый, хәтта аны танымаган Әндрәй (Тафтазан) каласы биген сугышып җиңсә дә гафу итә, аны кяфер санамый. Ул бик Миртимергә туп-туры: «Син — юлбасар, сиңа галимнәр, китаплар кирәкми, юк сүз сөйлисең», — дип әйтсә дә, аны җәзага тартмый.

«Тәварихе Болгария»дәге Мәһди солтан, аның бикләре образын тасвирлаганда, автор Русия империясе тарафыннан татар халкын күзәтеп, хәбәр җиткереп һәм халыкны авызлыкта тоту өчен куелган мөфтине, аның казыйларын күз алдында тота. Аларның бәтчәләрендә мөфтигә буйсындырылган указлы муллаларның йөзләрен танырга мөмкин.

Миртимерне Владимир шәһәренә җибәреп, анда аны туктатып, Мөслими әсәрнең максатына бераз ачыклык кертә. Миртимер христиан диненә каршы җибәрелмәгән, ул мөселманнарның иманнарын саклап, аларны «пәччәбазлар һәм бәтчәләр» тарафыннан уздырылган гөнаһлы эшләрдән аралау, коткару өчен җибәрелгән, дигән фикер уздыра. Русиянең мөфтилек оештыруын «сәяси фахишәлек» дип бәяли, һәм бу гөнаһлы эштән бары Төркестан (Урта Азия) мөселманнары ярдәме белән генә котылырга мөмкин дип нәтиҗә ясала. Мөслими Болгар вилаятендәге мөселманлык һәм аның изге урыннары Урта Азия мөселманнары өчен дә мөһим дигән сәяси, алдан күрүчелек фикере уздыра. Шунлыктан, әсәрдә язылганча, Миртимердән аларның күбесен зиярәт иттерә.

Шул вакытта Болгар вилаятендәге суфый каберләренең Әхмәт Йәсәви шәкертләренеке икәнлеген дә күрсәтә. Әсәрдә суфыйлар һәм аларның мөридләренең чын ислам тарафдарлары булуларына басым ясала.

Археографик экспедицияләр вакытында, Әхмәт Йәсәвидән алып XIX — XX гасырларгача язылып киленгән суфыйлар силсиләләре табылды. Бу силсилә төргәкләре битләрендә Урта Азия суфыйларына, аларның силсиләләренә XVIII—XX гасырларда яшәгән татар суфыйлары һәм аларның пирләре(яклаучылары) исемнәре дә килеп ялгана. Силсиләләрдә татар суфыйларының иң әүвәлгесе итеп XVIII йөзнең беренче яртысында яшәгән филолог-галим һәм дин эшлеклесе Гобәйдулла Болгари (Мансур Борындыкый) исеме күрсәтелгән. Әлбәттә, Идел—Урал буйларында Гобәйдулла Болгарига хәтле үк суфыйлар булган, тик хәзергә татарда суфыйлык хәрәкәте бик аз өйрәнелгән әле.

Татар суфыйлары рәтенә XV гасыр шагыйре Исмәгыйльне (Өмми Камал), XVI гасыр шагыйре Мөхәммәдьярны, XVII гасыр шагыйре Мәүлә Колыйны, XVIII гасыр шагыйре Габдине һ.б. кертергә мөмкин. XVIII гасырда татар суфыйларының эшчәнлегенә караган мәгълүматлар Таҗеддин Ялчыголның «Рисаләи Газизә» исемле 1796 елда язылган әсәрендә дә бар. Әлеге китапта да хакимият таянычы булган имамнарның гыйлем һәм әхлак ягыннан суфыйлардан түбән булуларына ишарә ясала. Ул әсәрдә язылган Идрис Хафиз, Шәех Хәбибулла кебек тарихи шәхесләр «Тәварихе Болгария»гә дә килеп керәләр. Шунлыктан, бу ике әсәр арасында ниндидер бер эчке бәйләнеш барлыгы сизелә. Бу ике хезмәтнең дә авторлары мөселман татарларда килеп туган проблемаларны бәян кылалар һәм аларның иманнарын ныгытырлык мәгълүматлар тәкъдим итәләр.

«Тәварихе Болгария» әсәрендә нинди проблемалар барлыгы түбәндә бәян ителер:

I. Әсәрнең авторы, XVIII гасыр ахырындагы татар мөселманнарның бабалары Болгар дәүләтендә Мөхәммәд пәйгамбәр сәхабалары заманында ук (ягъни VII гасырның беренче чирегендә) ирекле рәвештә ислам динен кабул иттеләр, дип яза. Моңа дәлил итеп, Айдар ханның кызы Туйбикәне терелткән өч сәхабаның миссионерлык эшен китерә. Әлеге сәхабалардан икесе

кире Мәдинә шәһәренә кайтып киткәч, өченчесе — Зөбәер бине Җәгъдә — ислам таратуда эшли. Аның өйрәтүләреннән Болгар җирендә мөселманлык кабул итүчеләр, һиҗри 195, милади 881 елга кадәр яшәп, дин таратканнар, аларны табигыйннәр дип атаганнар. Әлеге табигыйннәрнең 38 е — Болгар шәһәреннән, Әй буе башкортларыннан да 6 кеше килеп сәхабадан ислам кабул итәләр һ. б. Шунысы кызыклы, бу табигыйннәрнең үзләренә караганда аталары күптән мөселман булганга охшый. Мәсәлән, Кадерлекол Өмидлекол углы, Ишбулат Шәмгун углы, Байбакты Әмир углы, Котлыбай Дәүләтбай углы, Аеткол Зәет углы һ. б. Моңа тагын башкортларның Ибн-Фадлан килгән вакытта да әле мөселманлыкны танымыйча фаллоска табы-

нуын өстәсәң, сәхаба һәм табигыйннәрнең чынбарлыкта яшәүләренә зур шөбһә уяна.

«Тәварихе Болгария»дә санап үтелгән табигыйннәрнең исемнәренә этимологик һәм морфологик анализ ясасаң, аларның абсолют күпчелеге татар мөселманнар арасында таралган ярым татар, ярым гарәп һәм фарсыдан кергән исемнәр икәне күренә. Мондый тип исемнәр XVII—XVIII йөзләрдә татар халкы арасында популяр булганнар.

Әлбәттә, монда эш шөбһәле тарихтагы фактларда түгел, ә төп акцент төркиләрнең шактый борынгыдан тыныч юл белән ислам динен кабул итүләренә юнәлтелә. Урта гасыр кешесенең аңында яңа һәм иске диннәр арасындагы каршылыклы карашларны кичү зур психологик җиңү булган. Шунлыктан «Тәварихе Болгария» авторы ислам кабул итүне алдынгы мәдәниятләргә юлга чыгу дип саный. Колонизатор миссионерларның мөселманнарны көчләп чукындыруына каршы автор «безнең иманымыз сез килгәнче күп йөз еллар элек калыплашкан инде» дигән фикер үткәрә. Димәк, Мөслиминең әсәре — басып алучыларга каршы юнәлдерелгән публицистик-полемик әсәр. XVIII — XIX гасырда бу фикерне бөтәнчә белдерү мөмкин дә булмаган.

II. Проблемаларның икенчесе мөселман татарларның тарихи ватаннарын һәм аңа хокукларын раслауга юнәлтелә. Русиянең дөньяви һәм рухани феодаллары Идел—Урал буйларын кан коеп яулап алгач, җирле халыкларның җирләрен тартып алып, ул җирләрне үзләренең боярларына, воеводаларына, чиркәү-монастырьларга бүлеп биргәннәр. Илен-динен сатып колонизаторларга хезмәткә күчкән кайбер татар морзалары, тарханнары да майлы калҗадан коры калмаганнар. «Тәварихе Болгария» авторы, бу яулап алынган җирләр барысы да — безнең изгеләребез, табигыйннәребез күмелгән урыннар, дип, халыкның ватанга һәм җиргә хокукын яклап чыга, тарихи ватанның чикләрен билгели. Көнбатышта ул җирләр Зөя елгасы бассейнын, ә көнчыгышта Тубыл каласын эченә ала. Төньякта Шушма, Нократ, Туймы, Бур елгалары бассейннарыннан алып көньякта Сарайчыкка хәтле Җаек елгасы буйлары кертелә. Моның чикләре XV—XVII гасырларда яшәгән Бөек Нугай урдасы территориясенә туры килә. Автор XVIII гасыр татар мөселманнары бабаларының кайсы кавемнәрдән формалашуын да киная белән генә әйтеп санап үтә. Шушы зур географик киңлектәге табигыйннәрнең каберләре таралышын билгели һәм исемнәрен атый. Аларның үзәкләре итеп Казан, Өфе, Алатыр, Сенбер, Сарытау, Саричин, Тубыл калаларын күрсәтә. Мөслиминең XVIII гасырдагы зуррак татар авыллары исемнәрен дә әсәренә кертүе кызыклы. Табигыйннәр белән бәйле рәвештә, административ бүленеш зуррак елгалар буенча күрсәтелә:

1. Авторның Идел елгасын Вулгы Иделе дип атавы тарихи-хронологик җәһәттән күп нәрсәләр сөйли. Идел ярына урнашкан Болгар шәһәренә зур игътибар биреп тә, Бүләр шәһәренә артык тукталмавы да күп сораулар уята. Бүләргә караганда Тубылгы атавы һәм Кашан шәһәренә әһәмиятлерәк урын бирелү дә кызыклы.

2. Урал тауларының көньяк-көнбатышыннан килгән башкорт кабиләсеннән чыккан табигыйннәр Әй елгасы буеннан килгән дип саналалар. Табигыйннәр дип Зөбәер бине Җәгъдә сәхабадан иманга кергән кешеләр саналган.

3. Өфе Иделенең Агыйделгә кушылган җиреннән, нугай ханы Байчура ханның кешеләреннән чыккан табигыйннәр. Шулай ук нугайлардан Дим елгасы буеннан килгән табигыйннәр да бар. Бу урында бер Тирмә исемле авыл гына искә алына.

4. Урал буендагы Сәрмәсән, Карамасан елгалары буйларыннан килгән табигыйннәр санала. Анда да авыллар искә алынмый.

5. Ык елгасы буеннан килгән табигыйннәр күрсәтелә. Ык елгасы буендагы Тугаш хан авылыннан чыккан табигыйннәр башкорт һәм башка таифәдән чыккан кешеләрне ислам әһле кылалар.

6. Минзәлә елгасы буендагы болгари табигыйннәр санала. Минзәлә суыннан ерак түгел, Ыкның Агыйделгә койган җирендә Дәвеш хан белән Кәләл хан табигыйннәр булганнар. Бу фактлар бүгенге көнгә кадәр сакланган кайбер эпитафик истәлекләр белән бәйле. Мәсәлән, Минзәлә төбәгенә караган Бикбау авылыннан 3—4 чакрым җирдә 1657 һәм 1689 елларда Нократ татарларыннан булган Бикбау Йосыф улы һәм Сөлек Бикбау улы (аталы-уллы) кабер ташлары

тарихлары бу очракта кызыклы, аларның беренчесен Дәвеш хафиз исемле кеше язып куйган. Бу ике таш Мөслими язган Ык елгасы тамагында урнашканнар. Әсәрдә шул каберләр истә тотыла, күрәсең. Минзәлә елгасы буенда Дүсем авылы искә алына. Бу авыл бүгенге көндә Сарман төбәгенә карый. Мөслими язуы буенча, бу тирәләрдә башкорт һәм мишәр таифәләре яшәгән. Автор өчен катлау (сословие) бүленеше ыру-кабилә бүленешенә тәңгәл булып чыга. Бу мәсьәлә аерым өйрәнелә, һәм ул хакта матбугатка чыккан фикерләр бар инде.

7. Агыйделнең төньягыннан аңа койган Туймы елгасы буе табигыйннәре санала. Туймы елгасы тамагында Алабуга (Садум) шәһәре искә алына. Аны Искәндәр Зөлкарнәйин салган дигән риваять китерелә. Алабугадан ерак түгел Мәләкәс, Субай, Шәңгәлче авыллары санала.

8. Зәй елгасы буе табигыйннәре санала.

9. Кичү елгасы буе табигыйннәре санала.

10. Агыйделгә (хәзер аның бу өлеше Кама дип йөртелә) койган Чушмә (Шушма) елгасы тамагындагы табигыйннәр санала. Алар Тубылгы атау каласыннан булалар.

11. Чирмешән елгасы буенда табигыйннәрнең күп күмелгән булуы языла, ләкин аларның исемнәре саналмый.

12. Нократ елгасына койган Шушма суы буендагы табигыйннәр санала. Анда, нигездә, бүгенге Татарстанның Балтач төбәгендәге Балтач, Салавыч, Смәел авыллары белән бәйле табигыйннәр атала.

13. Казансу буендагы Курса, Кәче, Әйшә (Гайшә) авылларында булган табигыйннәр санала. Шунысы игътибарга лаек, хәзерге халыкта Әйшә һәм Кәче авылларындагы табигыйннәрнең каберләрен иске зиратларда сакланган XVI—XVII гасыр кабер ташлары белән бәйләү тенденциясе бар.

14. Зөя суы буендагы Әҗем, Күккүз, Мулла иле, Тәтеш, Шырдан, Бикшит авылларындагы табигыйннәр санала. Соңгы ике авылның табигыйннәре мишәр таифәсеннән икәнлеге күрсәтелә.

Югарыда китерелгән табигыйннәр бүленешенә күз төшерсәң, шул күренә: «Тәварихе Болгария» авторының иң яхшы белгән урыннары бүгенге Татарстан җөмһүриятенә караган елгалар һәм авыллар була. Китерелгән ундүрт бассейнның унбере — шулар. Калган өчесе Урал буена карый. Икенче төркемгә кергән елгалар буенда авыл атамасы да бер генә.

Гомумән алганда, бу бүлекләрдә искә алынган географик нокталарның барысы да татарларның таралып яшәгән урыннарын тәшкил итәләр һәм әүвәлге Нугай урдасының тарихи мәйданын эченә алалар. Бу Нугай (татар) дәүләтенең идарәчеләре итеп Идегәй токымыннан булган әмирләр, морзалар түгел, ә Алтын Урда идарәчеләренең титулы — ханнар күрсәтелә.

III. Мөфтилек оешып, дин эшләре Идел—Урал өлкәсендә урыс кулына кергәч, аларга оппозиция булып XII гасырда Хәрәзмдә яшәгән атаклы төрки шагыйрь Әхмәт Йәсәви тарафыннан нигезләнгән Нәкышбәнди суфыйлары идеологиясе тарафдарлары кала.

Суфыйларның төзеп калдырган силсиләләреннән күренгәнчә, Әхмәт Йәсәви Мөхәммәд пәйгамбәр нәселе белән бәйләнгән. Бу факт аның өйрәтүләренең рәсми ислам өйрәтүләренә каршы килмәгәнлеген күрсәтә. Һәрбер суфыйның яклаучысы (пире) була. «Суфый» исеме алу өчен, остаз пиреңнең таныклык (иҗазәт) бирүе фарыз. Суфизм — исламның бик хәрәкәтчән, конспирациягә ия булган, аерым мәчет биналарының булуы шарт итеп куелмаган яшәүчән формасы. Ул күчмә тормыш белән яшәгән төркиләр өчен уңайлы дини система булган. XIV— XVIII гасырларда нугай атамасы белән мәгълүм булган күчмә татарларда суфыйчылык төп дини идеология булмадымы икән, дип уйларга тулы нигез бар. Хәзерге Башкортстан һәм Татарстанның күп өлешендә Нәкышбәнди тарафдарлары нык тамыр җәйгән булган. Казан шәһәрендә үзләрен «җәзбә» дип атаган суфый һәм аларның мөридләренең хилькага, ишанга йөрүләре әле 1970 елларда да мәгълүм иде. Казанның татар бистәләре сүтелүе һәм өлкән буыннарның сүнүе сәбәпле, бу «җәзбә»ләр 1980 елларда тәмам беттеләр шикелле. Суфыйларның хилькага җыелып Аллага гыйбадәт кылу рәвешен Казанның камчылы ишаны (Хуҗаев) мисалында XX гасыр башларында Габдулла Тукай да күреп чыккан[1]. Таҗеддин Ялчыголның XVIII гасыр ахырында язылган «Рисаләи Газизә» китабында да Казанда «җәзбә»ләрнең булуы хакында язылган[2].

Әхмәт Йәсәви, Сөләйман Бакырганый һ. б. суфый шагыйрьләрнең хикмәтләре («Бакырган китабы»ндагы шагыйрьләр күздә тотыла) белән һәм Суфый Аллаһияр әсәрләре аркылы бу караш татар дөньясына киң тарала.

Идел—Урал буе татарлары һәм татар-мишәрләрнең консолидациясе нәтиҗәсендә, татар милләте Алтын Урда дәүләтенең утрак һәм күчмә кавемнәре варисы буларак барлыкка килде, һәм XIX гасырда татар милләтенең ике этник төркеме өчен дә кабул ителгән шәкелдә ислам йолаларын үтәү ныгыды, суфыйчылык татар арасында бетүгә йөз тотты.

II. Татарлар арасында исламның суфыйчылык рәвешендәге мәзһәбе үсә баруын һәм

бетүгә йөз тотуын аларның «Силсилә» исемле документларыннан күрергә мөмкин. Бу документ һәм зур ишаннарның татар зиратларында саклanучы каберташ язмалары, кулъязма китап битләрендәге мәрсияләр — суфыйчылык тарихы өчен алыштыргысыз

чыганаклар булып хезмәт итә. Урта Азия һәм Госманлы Төркия аркылы суфый дәрвишләрнең идеологиясе камилләшә барган. Кулъязмаларда һәрбер һөнәрнең яклаучы пирләре күрсәтелә. Мәсәлән: елкычылар пире, бакырчылар пире, алтынчылар пире һ. б.

Хисамеддин Мөслиминең әлеге «Тәварихе Болгария»сендә күп кенә суфыйларның исемнәре санап үтелә. Алар арасыннан аеруча Идрис хафизга зур урын бирелгән. Аның турындагы истәлек татар халкында бай фантазияләргә уралып бүген дә яши әле. Әлбәттә, аның турында аннан-моннан ишетелгән имеш-мимешләргә таянып язылган һәм басылган язмалар Идрис хафиз турында буталчык информацияләрне генә тәшкил итәләр».

Шунысы кызык, Мөслими Суфый Аллаһияр турында бер сүз дә язмый. Гомумән алганда, «Тәварихе Болгария» әсәре, күп фантазиясе булуга карамастан, татардагы суфыйлык тарихына карата, якынча булса да, кызыклы чыганак булып хезмәт итә ала.

Әсәрдәге суфыйлар мотивы — Әхмәт Йәсәви шәкертләренең махсус куелган мөфти, казыйлар һәм указлы муллалардан өстенлеген раслау өчен уздырыла.

IV. Мөслими христиан миссионерларының башбаштаклыклары чорында ислам таләпләреннән читенергә туры килгән бидгатьлекләрдән (кимчелекләрдән) арынуны катгый таләп итеп куя.

Динне кысу, мәчетләрне-мәдрәсәләрне җимерү дәверендә мөселман мәхәлләләрендә җомга һәм гаед намазларын мәхәлләнең барлык әһле белән уздыру кыен эшкә әйләнә. Озак еллар дәвамында исламның бу фарызларын үтәми килү халыкта аларга карата инертлык тәрбияли.

Болгар дәвереннән бирле, «Болгар вилаятендә ясигъ намазы уку фарызмы, юкмы?» дигән бәхәс өстенә, җомга һәм гаед намазларын үтәү турында бәхәсләр кабынып китә. Кайбер кеше, бездә Мисыр түгел, дип, җомга, гаед уку, җомганың сөннәт азанын укымау турында бәхәсләр кыздырган. «Тәварихе Болгария» авторы, моңа каршы чыгып, «Тимерташ» (?) китабыннан, Багдад имамы Әбү Йосыфтан (ул Имам Һарун әр-Рәшит хәлифә идарә иткән 786 — 809

елларда яшәгән) әлеге фарызларны үтәргә тиешлек турында фәтвалар таба. Әлеге авторлар булгандырмы, юкмы, анысы безнең өчен анык түгел. Эш шунда ки, Хисамеддин Мөслими бидгатьләрне ислам белгечләре авторитетлары белән төзәтергә омтыла. Менә «Тәварихе Болгария»дә Әбү Йосыфтан китерелгән фәтваның татарчасы: «Әй минем шәригем, ни өчен бу турыда минем фәтвамны сорыйсың? Имам Әгъзам мәзһәбе буенча синең фәтваң җитә. Әмма инде Имам Шафигый сүзе, Алланың рәхмәте төшсен үзенә, — ястү намазы турында һәм Хаҗаҗ бине Йосыф фәтвасы, — җомга намазының сөннәт азаны турында — минем мәзһәбемнең сүзләре. Синең Болгар җирендә шушы фәтвалар белән гамәл итәргә тиешләр. Туры юлга ияргән бәндәләренә Алланың рәхмәте яусын». «Тәварихе Болгария» авторының бу мәсьәләләрдәге фикерләре Шиһабеддин Мәрҗани тарафыннан язылган «Назурәтел-хак» әсәрендә күтәрелгән проблемаларның куелышын хәтерләтә. Ул, җомга уку өчен имамнан башка өч кеше булу җитә, дигән фикерне уздыра. Бу фәтва гаед намазлары өчен яраклы була. Ястү намазы кояш баеп бер сәгать үткәч укыла, дип хәл ителә. Җомганың сөннәт азанын үтәү тиеш, фарыз эш, дип раслана.

Урта гасырларда мондый бәхәсләр мөселманны мөселманга өстерүгә кулай булганнар. Мәсәлән, Касыйм ханы Шаһ Гали һәм аның сәйеде, Казан дәүләтенә походка бару өчен, үз кул астындагы халыкны шундый коткы белән агулаганнар булса кирәк. Аксак Тимер дә, Болгарда исламга ревизия белән шөгыльләнәләр, дип, Идел буе шәһәрләрен җимереп бетерә. Аның бу агрессив асылын Хисамеддин Мөслими «Алла җәзасы» дип бәяли һәм, динне бозулар китсә, шундый җәза киләчәк, дип, узган тарих фаҗигасы белән татар мөселманнарны искәртә. Әлбәттә, «Тәварихе Болгария»дә тасвирланган Миртимер Әмир Тимердән нык аерыла. Әсәрнең бер бүлегендә автор үзе дә Аксак Тимергә карата Әндрәй (Тафтазан) каласы ханы авызыннан «Син — карак, сиңа гыйлем, дәрес кирәкми» дип әйттерә.

V. «Тәварихе Болгария» әсәре белән танышып чыккач, аның тарих түгеллегенә инансак та, авторның фактларны үзенең максатына яраштырып, аларга фантазия кушуы икенче мәсьәлә. Хәзер инде, аның тарих түгеллеге раслангач, әсәр авторының нинди мәгълүматларга ия булганын да ачыкларга кирәк. Аларны түбәндәге төркемнәргә аерып күрсәтергә мөмкин:

1. Автор Болгар җирендә мөселманлыкның тыныч юл белән бик борынгы заманда кабул ителгәнен белгән. Ләкин төгәл кай вакытны ислам керә башлавын билгели алмаган. Ул Болгар дәүләте вакытындагы әмирләрнең берсенең дә исемнәрен белми.

2. Мөслими Чыңгыз империясе төзелүен, аның нәсел шәҗәрәсен яхшы белә, шулай ук Дәшти

Кыпчак татар дәүләтен һәм аның идарәчеләрен (мәсәлән Бирдебәк хан исеме телгә алына), дәүләтнең биләгән мәйданын да белгән.

3. Нугай урдасы тарихын да белгән.

4. Аксак Тимернең тормышыннан һәм аның вәхши походларының тарихыннан да хәбәрдар булган (Дәшти Кыпчакка, Болгар, Төрек йортларына, Кавказга һ. б.).

5. Алтын Урда дәверендәге Сарайчык, Тубылгытау, Болгар, Бүләр, Кашан шәһәрләренең исемнәрен, урыннарын яхшы белгән.

6. Татар мөселманнар арасында суфыйчылыкның бик ерактан килгән тарихын белә.

7. Байчура исеме астында татарларны XIV гасырның икенче яртысында Урта Идел һәм Урал буйларына алып килгән Бикчура ханның шәҗәрәсе, аның Аксак Тимер явы килгәндә Болгар җирендә һәлак булганы да авторга мәгълүм була.

8. Татар тарихында XIV — XVIII гасырларда күренгән тарихи шәхесләрдән Мөхәммәт Тафтазанины, Касыйм бине Ибраһимны, Идрис хафизны, Ишмөхәммәд бине Тукмөхәммәдне, Ишнияз бине Ширниязны белә. Тик, үзенең әсәре тарих булмагач, аларның кайберләренең исемнәрен бераз үзгәртеп бирә.

Югарыдагы фактлардан аңлашылганча, «Тәварихе Болгария» авторы надан кеше түгел, ул тарихны үз карашларына фон итеп кенә файдалана, дигән фикер нигезле булыр.

VI. Иң соңгы фикер «Тәварихе Болгария» авторы турында. Алда язып үтелгәнчә, әсәрнең авторы үзен Хисамеддин бине Шәрәфеддин Мөслими дип тәкъдим итә, әсәрнең язылу вакыты борынгылаштырыла, ә вакыйгалар һәм проблемалар XVIII гасыр ахыры белән тәмамлана. Бу фактлар авторның, эзәрлекләнүдән куркып, псевдоним астында язганын күрсәтергә җитәрлек.

Хисамеддин — диннең кылычы, Шәрәфеддин — диннең хөрмәтлесе, Мөслими — мөселманнар тарафдары дип тәрҗемә ителә. Бу исемнәргә әсәрнең кемнәргә һәм ни өчен атап язылуы фикере салынган. Аннан соң авторның «Болгар тарихы» дип тәкъдим иткән риваятьләре бара.

«Тәварихе Болгария»дә күтәрелгән проблемалар һәм файдаланылган тарихи фактларның байтагы икенче бер татар язучысы Таҗеддин бине Ялчыголның «Тарихнамәи Болгар» (кульязмада) һәм «Рисаләи Газизә» исемле әсәрләрендә кабатлана. Соңгы ике әсәр дә XVIII гасыр ахырында язылганнар. Мөслиминең бигрәк тә Ык, Минзәлә, Зәй төбәген яхшы белүен исәпкә алсак һәм Әйдән табигыйннар күрсәтүен дә санасак, аның күп кенә параметрлар буенча Таҗеддин бине Ялчыгол әл-Иштәки әл-Болгарига туры килгәнлегенә игътибар итәрбез. Таҗеддин Ялчыгол да үзен Әй буеннан чыккан «башкорт» итеп күрсәтә, ләкин үзе җир алу мөмкинлекләре җиңеллеге белән кызыктырган «ватанына» бер дә кайтмый, Имәнле авылында үлеп кала. «Тарихнамәи Болгар» авторының үзенең дә узган тормышы бик серле. Шунлыктан ул үз иҗатының башлангыч чорында псевдонимнар куеп язуы белән гаҗәпләндерми.

## «Тәварихе Болгария» китабыннан

...Әлкыйсса. Кыш көне булды. Кар йагар вакыт булды, Ирнә суының тамагы Зәйгә койгандыр. Ул урында Байраш хан Колый ханның углы ирде. Аксак Тимер аңа хат язды: «Бән сиңа кышламага барырмын»,— дәйү. Байраш хан хат язды: «Әйа солтаным хәзрәте Миртимер, башым өстендә атамыз-анамыз сиңа фида булсын, кабулым вардыр, разикъ Аллаһыр»,— диде. Байраш хан Баграш суы буйында Ирнәгә койгандыр. Ул суның бер бийек тагы вардыр. Ул тагның башына бер олуг сарай дөзеделәр. Ул сарай тәмам улгач, Миртимер хәзрәтени өндәде. Гаскәре илә килде. Баграш суының буйы гаскәр булды. Байраш хан Зәйдән гаскәре илән истикъбал идеп, ул таг башындагы сарайә килтерде һәм кергезде. «Колың Байраш синең хәзрәтеңә кышлак сарай төзеде, кабул итсәңез, торасыз»,— диде. Аксак Тимер сарайны хуплады, Байраш ханә күп хәзинәләр бирде.

Әлкыйсса. Ул кыш анда кышлады: мелла Хафиз әд-Дашкинди каберенә зийарәт әйләде. Минзәлә суының тамагы Ык суына койгандыр. Анда Мостафа ханә кунак булды. Гариф биллаһи каберенә зийарәт әйләде. Чаллы суы тамагында Акидел йарында Мәүлүд хуҗага зийарәт әйләде. Андан Байчура чирмеш авылында хуҗа Әмир Кәланә зийарәт әйләде.

Әлкыйсса. Кайтыб Баграш суының буйында Байраш хан төзегән сарайына керде.Кышладылар. Җәүзәнең уникенче көнендә Аксак Тимер гаскәре илә кузгалды. Байраш хан илә видаглашдылар. Байраш хан аңа ияреп, Ыкның Тугаш хан авылында ике әкбәр табигыйн каберләре вар ирде, бери — Морадым хафиз, икенчеси Мохсин хафиз Йулдаш угланларыдыр. Андача бергә барып зийарәт әйләде. Андан Миртимер хәзрәтләре, видаг итеп, Сәмәркандка китде. Байраш хан Зәйгә кайтды.

Әлкыйсса. Аксак Тимер хәзрәтләре, Уралны чыкып, кыргыз халкына керде. Анларны өндәде.

Вә һәм төрекмән халкыни өндәде, ислам кабул иткәнләринә йортларын бирде, үзләрендин хан тикде. Кабул итмәгәнләрне кол итеп, әсир кыйлды.

Әлкыйсса. Хәзрәте Аксак Тимер Сәмәркандка өч йыл солтан улды. Түртенче Маһи рамазан мөбарәкнең йикерме йитенче кичәсендә фәтваи җәмһүр голәма хәнәфийә илә ләйләте керделәр. Хәзрәте Миртимер дар-е бәкайа рихләт әйләде. Галләмәи Тәфтәзани гайед көнендә вафат булды (колю иннә лиллаһи вә иннә иләйһи раҗигун). Тарих һиҗрәтен тукызынчы йөз икенче йылы ирде, эт йылы ирде...

## ШАГЫЙРЬ ӘХМӘТҖАН ТУБЫЛИ

Иҗат эшчәнлеге XIX гасыр уртасыннан ук башланып 1890 елларга кадәр дәвам иткән шагыйрь Әхмәтҗан бине Шәмседдин әл-Әбеви әс-Самари әл-Болгари әт-Тубыли хакында сөйләү өчен чыганаклар юк иде; соңгы елларда уздырылган археографик экспедиция йомгаклары нәтиҗәсендә генә бу талантның иҗат эшчәнлеге турында сүз алып барырга мөмкин булды. Аның бер кулъязма китабын 1973 елда филология фәннәре кандидаты Әнвәр Шәрипов хәзерге Татарстан җөмһүриятенең Лениногорск төбәгенә караган Сарабиккол авылыннан табып алып, Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты Мирасханәсенә тапшырды. Зур күләмле бу кулъязма китапта ислам дине мәсьәләләренә караган прозаик әсәрләр һәм Әхмәтҗан бине Шәмседдиннең улы Мөхәммәтҗанга Тубыл (Тобольск) шәһәре төрмәсеннән язылган васыять-намәсе теркәлгән.

1982 елгы археографик экспедиция вакытында Сарабиккол авылында Хөснетдинов Хәтиф (1909 елда туган) агада Әхмәтҗан Тубылиның 209 кәгазьдән торган зур кулъязма җыентыгы табылды. Бу җыентыкта шагыйрьнең дистәләрчә шигырьләре, шигъри хатлары, поэма, мәрсия һ. б әсәрләре бар. Андагы шигырьләрдә авторның тормыш сәхифәләрен ача торган күп мәгълүматлар очрый. Шул ук елда Сарабикколда Әхмәтҗан Тубыли тарафыннан 1885 елда төзелгән күләмле кулъязма календарь табылды.

1984 елда Лениногорск шәһәрендә яшәүче Галимҗан Әхмәтҗанов Әхмәтҗан Тубылиның Себердән язган бер хатын тапшырды. Менә шул кулъязмаларда сакланган мәгълүматларның беркадәре-сен тәртип белән искә алып үтик. Телләрдә сөйләнгән хәбәрләр буенча, Әхмәтҗан бине Шәмседдин Тубыл шәһәренә төрмәгә җибәрелгән. Бу хәл чыннан да булганмы? Әлеге сорауга аның Ту-былдан дусларына һәм улы Мөхәммәтҗанга язган хатында җавап табарга була.

Хат тексты:

«Хөрмәтле вә гыйззәтле Камалетдин абзыйга һәм нурдидәм Мөхәммәтҗанга бигаять сагынып, сәламләремнең гөзидәсене әбилаг идәм һәм кадерле вә хөрмәтле талибем Җамаледдинга һәм күземнең нуры углың адаш Әхмәтҗанга сәламләремнең халисене күндердем. Үзем сәламәтмен, хәйер догаларыгызда, һәмишә догада уласыз. Хак сөбханә вә тәгалә Сезне, газиз балаларыңыз илән афәт дөньяви вә ахирилардән имин вә мәхфүз әйләсен, вә ахры дәмдә хөсне хатимә илә мөшәррәф вә мөкәррәмо әйләсен... Хөрмәтлеләрем, үтенәмен сезләрдин, бәнем бу хатымны углым Мөхәммәтҗанга тапшырсагыз ла. Аллаһу тәгалә разый улсын сезләрдин, һәрвакыт сезне мәшәкатькә саламын, зинһар, рәнҗи күрмәңез, хезмәтеңез сәдәкайә язылсын. Һәнүз безне онытмайсыз, Аллаһу тәгалә җәннәт илә түләсен, амин... 79 нчы елны апрельнең 15 ендә язылды. Тубылдан. Һичбер хәүфләнмәңез, мондагы губирански ахунд мелла Габделбакый шәриф безнең өчен чук ригаять идәчедүр һәм начальниклар катында сүзе өстен, кадре зур һәм бәне гаять йакын дуст күрәдүр, яхшы утырганым өчен һәм эсматрителнең рапорты буйынча губирански сәвитникнең әлемә хвальный лист бирде, эшкатулкамда тотамын. Аныңчүн һичбер сигез ел эчендә замечаниядә улганым юк, үз динемезне мөстәкыйль тотканымыз өчен. Урысның хвальный листындан безгә ахирәт өчен һич файда юк, мәгәр «дөньяви сафама хаҗәт» диеп, блакатны әлемә вирелде. Чөнки халикы Гайса улып, үз диненең кадрине белеп камилләсе бийлә идәләр: «Тапшырдым Аллаһу тәгаләгә»...»

Хаттан күренгәнчә, Әхмәтҗан Тубыли 1879 елның 15 апрелендә төрмәдә тугызынчы ел утыра булып чыга. Димәк, аны 1871 елны утырткannар. Бу вакытка кадәр инде аның улы Мөхәммәтҗан туган була. Аның ничә яшьтә икәнен тәгаенләү кыен. Тоткынны губерна ахуны мелла Габделбакый белеп, аңа ярдәм итеп һәм хәлен җиңеләйтеп торган.

Әхмәтҗан Тубыли Сарабикколдагы баласының кайда, кемдә калганын белмәгәнме яки аңа гаиләсе белән хат алышу тыелган булгангамы, никтер хатны үзенең дусларына язган.

Шагыйрьнең Габдерәхим Утыз Имәнинең улы Әхмәтҗан үлеменә карата язган мәрсиясендә дә

кызыклы хәбәрләр бар. Әхмәтҗан бине Габдерәхим Утыз Имәнинең шагыйрь булуы мәгълүм. Аның турында беренче хәбәр бирүче кеше борынгы әдәбият белгече Сәгыйть Исәнбаев булды. Ләкин ул хезмәттә Әхмәтҗан бине Габдерәхимнең кайсы елларда туган-үлгән булуы хакында мәгълүматлар юк иде. Әхмәтҗан бине Шәмседдин язган мәрсиядә үлгән елы күрсәтелгән:

«Тәварихдә вафаты мең сигез йөз
Кырык тукызынчы йыл, июньди йолдыз.
Тәмам иттем сүземне, и агалар,
Ки сезләрдин өмидемдер догалар.
Белерсеңез язанның наме Әхмәт,
Зам идүб ләфзы җанны чикте зәхмәт.
Дәхи Шәмсетдин ирүр һәм атасы,
Гафу идең, әгәр булса хатасы».

Әхмәтҗан бине Габдерәхим үлгән вакытында бик яшь булмаганлыгы аңлашыла. Мәрсия авторы аны үзенең хөрмәтле остазы итеп тасвирлый. Моннан чыгып, Әхмәтҗан Тубыли Габдерәхим Утыз Имәни кызына түгел, ә бәлки Әхмәтҗан бине Габдерәхим кызына өйләнгән булса кирәк, дигән фараз куярга була.

Сарабикколда табылган зур күләмле җыентыкның 21 битендәге шигырьдә Әхмәтҗан Тубыли үзен 55 яшь тулган кеше итеп саный. «Мәрсия»дән соң килгән шигъри хатлары ахырында үзе турында болай ди:

«Йазылан тарихдыр мең сигез йөз,
Йылы йитмеш сигез, гыйнварди йолдыз.
Йазубән өчендә итде тәскин.
Буны мәнзүмидән Болгари мескин.
Дәхи мәхбүс улырда кылды тәмам,
Хибес эчрә бәләдидер Тубыл нам.
Йазалем кәнди худ канидыр дийарын0.
Белең Болгар ватан, аслын йирин.
Губернасы Самар, Бөгелмә өязе,
Әбидер карьясе, Мәүлид нази.
Намы Әхмәт зам идүб ләфзы җанны,
Атасы Шәмсетдиндер, куймыш җиһанны.
Ая дустлар, сезә юктыр бүләгем,
Биһишт вирсүн сезә будыр теләгем».

Бу адрес буенча күрсәтелгән урын бүгенге көндә Сарабиккол авылы дип атала (Татарстан җөмһүрияте, Лениногорск районы).

Әхмәтҗан Тубыли Тубыл якларындагы Кызыбай, Ишәй, Карагай, Кырйатан дигән татар авылларында була. Аңа Ишәй иленең Гавазбакый бине Мөхәммәдкасыйм әт-Тубыли исемле кешесе күп ярдәм иткән, шуңа ул аны «Мәдехнамә»сендә сәхи-юмарт дип атый.

Үзенең мөнәҗәтендә ул Чистай мөдәррисе Мөхәммәдзакир Камаловны (1818—1893) хөрмәт белән искә ала:

«Дәхи бер галим вә фазыйл галәмдә,
Ватан тотмыш ки ул Чистай илендә.
Тәвабигъ Казан-Болгар дияре,
Аның дәрсе ирер һәр фәндә җари.
Шәриф намы Мөхәммәд-Закир ирер,
Ки холкы исменә муафикъ ирер.
Мөдәррис, гыйльмү заһир һәм батыйнда
Ничә талиб, ничә яран катында.»

Шигырьдән Әхмәтҗан Тубылиның Мөхәммәдзакир Камалов белән танышлыгы, аңа табынуы анлашыла. Димәк, ул Чистайда, Мөхәммәдзакир Камалов мәдрәсәсендә укыган булса кирәк, һәм үзе дә нәкышбәндиләр тарикатендә торган суфый булган.

Бу озын мөнәҗәтен шагыйрь 1879 елда язган, ул түбәндәгечә тәмамлана:

«Аныңчүн йаздыгым җай тарик иде,
Дәхи гомерем биш ундан артык иде.

Күзем йәшле улыб нуры түгелмеш,
Бәдән сулмыш, йегет вактым төкәнмеш.
Халә белдем, бу гомрем чук үтебдер,
Төшеп тешләр, бетеп, куәт китебдер.
Халә мөмкин йазарга улдыкында,
Диван йаздым, бу күзләр күрдекендә,
Бихәмед Аллаһ бу назмы кыйлдым итмәм.
Ки гаунеңлә0 дәхи кыйл фазыйль әнгам.
Газыймдыр фазлың иллә кәримә,
Васыгдыр рәхмәтең күп, йа Рәхимә.
Мөдаим эшләрем җөрмү хатадыр,
Дәвам сәндин гафу фазыйль гатадыр.
Хаталарым дөрестләр әйлә, бәхеш ит,
Дәхи тасхих идәне фазлу бәхеш ит.
Йазардә мистарым0 һәм улмады бер,
Шунынчүн сатриләр кәҗ улды ирер.
Кыйлам таәлиф назмым вактын әгълам,
Белеп дога кылсалар әһле ислам,
Биһиҗрәт туксан алты мең ике йөз,
Язылды кич эчендә, дәхи көндез.
Би-милади тарихи мең сигез йөз,
Сәнәи йитмеш тукыз, саратан ки йолдыз,
Убруҗының йитесендә кыйлдым тәмам,
Хибес эчрә бәләдидүр Тубыл нам...»

Бу өзек шагыйрьнең яшен ачыклауга ярдәм итә. Ул яшен бу урында «биш ундан», ягъни илледән узган дип күрсәтә. Икенче бер шигырендә инде ул яшен «илле биштән узган» ди. Әлеге шигырь белән янәшәдә аның 1878 елның гыйнварында язылган шигъри хатын да чагыштырсак, Әхмәтҗан Тубыли 1823 елларда туган кеше булып чыга...

Шагыйрьнең кызы Хөсникамал бинтү Әхмәтҗанның Себер якларында 1886 елның 23 сентябрендә үлүенә багышланган мәрсиясе тәэсирле язылган (118а — 119б бит.).

Әхмәтҗан Тубыли җыентыгында Габдерәхим Утыз Имәнинең хатыны Хәмидәгә багышланган мәрсиясе һәм Габденнасыйр Курсавига эпиграммасы да китерелә.

Китерелгән кадәр мәгълүматлар нигезендә Әхмәтҗан Тубылиның яңа билгеле булган шигырьләр җыентыгын XIX гасыр татар әдәбияты тарихына кирәрлек бай сәхифәле мирас дип карый алабыз. Җыентыкта 1889 елда аның соңгы яшәү урыны итеп Ишәй авылы күрсәтелә (170 бит). Бу авыл Тубыл шәһәре янында булып, юкка чыкканга ошый.

Шагыйрьнең 1973 елда табылган кульязма китабында 1890 елда язылган васыятьнамәсе бар. Ул анда барлык милкен улы Мөхәммәтҗанга васыять иткән. Аның шушы елдан соңгы язмышы әлегә караңгы. Тубыл шәһәре архивына язылган хатыбызга да канәгатьләнерлек җавап килмәде.

Әхмәтҗан Тубыли мирасы ныклап өйрәнелүгә лаек. Аның шигырьләре, поэмалары гына түгел, шигъри җыентыгына кергән башка авторларның поэзия үрнәкләре дә фән өчен мөһим. Анда шактый кызыклы исемнәр бар. Мәсәлән, 1870 елның 28 августында үлгән Мөхәммәтгалим бине мелла Әхмәтҗанның йорт диварына язып калдырган ике шигыре генә ни тора... (139 бит). Шигырь һәм поэмалардан тыш, Сарабикколдан чыккан татар шагыйренең дини-фәлсәфи язмалары, кулъязма җыентыкларда очрый торган әдәби табышмаклар үзләренең җаваплары белән кызыклы.

Әхмәтҗан Тубыли Идел буйларыннан Тубылгача булган күп укымышлылар белән таныш булып, татар иҗтимагый тормышының үзәгендә кайнаган шәхескә охшый. Ул Чистайдан Закир Камалов, Троицкидан Зәйнулла бине Хәбибулла, Казан янындагы Бакырчыдан Шаһиәхмәт Бакырчи, Тубылдан Гавазбакый Тубыли, Бәшир Тубыли һ.б. белән хәбәрләшеп яшәгән. Фарсы, татар телләрендә шигырьләр иҗат итүе, ислам дине проблемалары буенча язмалары, Габдерәхим Утыз Имәни, Әхмәтҗан Болгарилар мирасы, эшчәнлеге белән танышлыгы Әхмәтҗан Тубылиның тирән белемле, киң карашлы шәхес булуы турында сөйли. Кулъязма календарьлары шагыйрьнең астрономия, математика фәннәреннән хәбәрдар кеше булуын раслый.

Әхмәтҗан Тубыли татар әдәбиятын Тубыл, Тара якларында үстерүче һәм пропагандалаучы буларак әһәмиятле мирас калдырган. Себер якларыннан аңа язылган шигъри хатлар — шуның бер үрнәге.

Бер уңайдан шагыйрьнең әдәби псевдонимы турында да фикер белдереп китү урынлы булыр.

Шагыйрь үзен әт-Тубыли, Әбеви, Самари, Болгари тәхәллүсләре белән атый. Без бу тәхәллүсләрнең беренчесен генә алдык. Чөнки «Әби» авылы исеме инде күпләр өчен мәгълүм түгел. Габдерәхим Утыз Имәнинең улы Әхмәтҗан да «Болгари» булып йөргәч, әлеге тәхәллүсне кабатлау буталчыклык кына кертәчәк. Шунлыктан, иҗаты нигездә Тубыл шәһәре белән бәйле булгач, бу тәхәллүснең сирәклеген дә искә алып, кыскалык өчен дә, әдәбият фәнендә шагыйрьне кыскача Әхмәтҗан Тубыли дигән псевдоним белән йөртүне кулай күрәбез. Киләчәк галимнәре аның мирасын ныграк өйрәнеп, башка тәкъдимнәр белән дә чыгарлар әле.

## Мәрсия

...Мөйәссәр итди безгә бер балачык,
Күзи нурлу иде һәм йөзү ачык.
Бәңа юлдаш иде һәм чук мөләйем,
Бихәмде Аллаһ безгә вирде ходайым.
Дибән шатлык шәрабен әйләдем нуш,
Кичә-көндез гизәрдем һәм халим хуш.
Дәхи йук ирди һич хәсрәтем һич,
Шуныңчүн шат йөрердем иртә вә кич.
Бала ирер, күңелләрнең зыйасы,
Бала ирер һәммә дәртнең дәвасы.
Кочагында йатыр кан гөл кеби ул,
Тотар нагяһ кара тупрак, сары йул.
Кочагы буш, ана биһуш улыр ул,
Күренмәс һич бакар һәм сагы сул.
Ки нагяһ улды бер көн ул рәнҗүр,
Мәрыйз парә-парә әйләде зур.
Көнә-көндин зийадә улды рәнҗүр,
Әлемдән салмадым назәр вә мәнзүр.
Белерсең — Мәрвәрел-җәнандыр0 исме,
Җаны очып, күмелде, синә җисме.
Бу күзләр күрмәде туйанча йөзен,
Сәвер идем, атасы сәвәрди үзен.
Күңелем хуш иде Мәрвәр-җәнаным,
Синеңлә нурлы иде бу җиһаным.

## ШАГЫЙРЬ ӘХМӘТ УРАЗАЕВ-КОРМАШИ

XIX гасырның соңгы чирегендә татар әдәбиятында иң популяр авторларның берсе булган Әхмәт Мөхәммәдзариф улы Уразаев XIX гасыр урталарында хәзерге Актаныш төбәгенә караган Иске Кормаш авылыннан чыккан Мөхәммәдзариф мулла гаиләсендә Звериноголовск шәһәрендә (хәзерге Курган губернасы) туган. Ул башлангыч белемне Звериноголовск мәдрәсәсендә ала. Аннан соң укуын Кызылъяр (Казахстандагы Петропавловск исеме белән йөртелгән шәһәр) мәдрәсәсендә дәвам итә. Мәдрәсәнең мөдәррисе булып Габделбарый Габбас хәзрәт улы Яушев торган. Бу кешенең гыйлемлеге зур булып, аны мөфтилеккә дә тәкъдим иткәннәр, ләкин, карашлары патша администрациясенеке белән туры килмәгәнлектән, ул сайлаулардан уздырылмый. Габделбарый хәзрәт Кызылъярда ахунлык вазифаларын да башкара.

Әхмәт Уразаев үзенең татар арасында киң танылган «Кыйссаи Бүз егет» дастанын 1874 елның 25 апрелендә Габделбарый ахун мәдрәсәсендә укыганда төгәлли.

Дастан авторы аны, казах катнаш нугай (татар) телендә яздым, ди. Ул әсәр, шулай ук, казах арасында да популяр булып киткән.

Кызылъярда зур белем бирерлек мәдрәсә булмаганлыктан, Габделбарый ахун, үзенең улы Габделваһабка иптәш булыр дип, ике яшь шәкертне Казан артындагы Кышкар мәдрәсәсенә укырга җибәрә. Анда алар алты-җиде ел чамасы укыйлар. Җәй көннәрен Габделбарыйның Күшәрдәге туганнарында үткәрәләр.

Кышкарда укыган вакытта, 1879 елда, Әхмәт Уразаев-Кормаши «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» исемле дастан төгәлли. Автор аны язганда, сюжеты хакында, госманлы теленнән нугай (татар) һәм

казах катнаш теленә күчереп яздым, дип искәртә. Әдәбиятчыларыбыз әлеге сюжетның «госманлы» чыганагын белмиләр иде, ул хакта язучы булмады. Бу көндә әлеге «госманлы» чыганагының нинди әсәр икәне мәгълүм булды. Ул 1850 елдан бирле Истанбулда «Мәгариф» нәзарәте каршындагы литографиядә басылып килә торган «Хикәйәте Таһир илә Зөһрә» исемле әдәби халык дастаны басмасы нигезендә язылган әсәр икән.

Әхмәт Уразаевның җиңел кулыннан «Таһир илә Зөһрә» дастаны да татар, казах, башкорт арасында популярлык казанды. Аны Казанда кат-кат басып чыгардылар. Ул иҗат иткән һәр ике дастанны да халык күчереп алып, кулъязмаларда тараткан. Археографик экспедицияләр вакытында шагыйрьнең һәр ике әсәренең кулъязма килеш халыкта таралуына дәлил булырлык материаллар табылды. Шагыйрьнең башка язган әсәрләре дә булган, ләкин алар басылмыйча югалып калганнар.

Әхмәт Уразаев-Кормаши 1880 елларда Кышкарда укуын тәмамлап, Кызылъярга кайтып укыту эшенә керешә. Ләкин бик яшьли —1883 елда үлеп китә. Аның иҗат иткән әсәрләре әлеге темага бүтән татар әдип-шагыйрьләрен дә язарга дәртләндерделәр. Мәсәлән, драматург Фәтхи Бурнаш «Таһир белән Зөһрә» темасына мәңге үлмәс трагедия язып калдырды.

## «Кыйссаи Бүз егет»тән

...Сәне монда яратты, мәне анда яратты,
Сәне мәңа каратты, мәне сәңа каратты.
Тиз табарым кандадыр, арада дәрья яратты,
Чүлдә йөрдем су тапмай, суда йөрдем юл тапмай.
Дүрт ел булды юлыңда хәйран булып йөрдем мән,
Күп хәсрәтне күрдем мән, табаннарым уелып,
Кул тиреләрем суелып, нә сәргөрдан йөрдем мән.
Атамны да күрмәдем, анамны да күрмәдем,
Һичкем берлә йөрмәдем, сәне эзләп йөрдем мән.
Сәне күрер көн булса, җаным корбан кыйлгаймын,
Ни булсам да булгаймын, мән бер миһман килүбән.
Нурыңны төшемдә күрепмән, хәйран булып йөрепмән,
Сәне күрер көн булса, ни булса да булыпмән.
Таудин, ташдин үтепмән, бу шәһәргә җитепмән,
Йөзең күрер көн булса, ата-анадин китепмән.
Атым мәнем Бүз егет, кашымда бар дус егет.
Чын хакыйкать яр булсаң, өйгә керсәм кирәкти.
Җаным сөйгән җанымның йөзен күрсәм кирәкти.

## «Таһир илә Зөһрә кыйссасы»ннан

... Әлкыйсса. Зөһрәнең зар еглап бер назым әйткәне:

Гашыйк булган ярымны күрер көнем булырма?
Чын хакыйкать ярымны күрер көнем булырма?
Карагайлы кара урман үтәр көнем булырма?
Кара болыт башымнан китәр көне булырма?
Кайгыларның башымнан китәр көне булырма?
Михнәт китеп, рәхәтләр җитәр көне булырма?
Җиде елдыр булды зар, дидарыңа интизар,
Миһербаным, вафадар, күрер көнем булырма?
Кара нәркис күзләрең, ширин данә күзләрең,
Кызыл гөлдәй йөзләрең күрер көнем булырма?
Синсез йигән ашларым кызыл канга охшайды,
Якты көндә йөргәнем кара төнгә охшайды.

Әлкыйсса. Таһир бичара, күңелен юатып, зарилык
кыйлып әйткәне:

Еглама, күңелем, еглама, төннәр үтәр, көн булыр,

Михнәт үтеп, гарипкә рәхәт җитәр көн булыр.
Кайгу биргән Алламыз алса кирәк, иншалла,
Аера белгән Алламыз кушса кирәк, иншалла.
Михнәт биргән иямез рәхәт бирер, иншалла,
Хәсрәт биргән иямез шатлык бирер, иншалла,
Һәр михнәткә бер рәхәт булса кирәк, иншалла,
Гыйшык биргән Алламыз кушса кирәк, иншалла.

## РИЗАЭДДИН БИНЕ ФӘХРЕДДИН

Энциклопедист галим һәм күренекле татар язучысы Ризаэддин бине Фәхреддин 1859 елның 17(4) гыйнварында Татарстан Республикасының Әлмәт төбәгенә караган Кичүчат авылында зыялы гаиләдә дөньяга килгән. Аның ерак бабаларыннан булган Юлдаш баба Татарстанның Яшел Үзән төбәгенә караган Шырдан авылында туган. XVII гасыр урталарында, Нугай урдасы җирләрен колонизацияләү максатында, урыс хөкүмәте Кама аръягына чыгып төрле хәрби терәк пунктлар кора башлый. Ул терәк пунктларга төрле тарафлардан казаклы татарларны («служилые татары» дип тә атала) куып китереп утырта. Юлдаш баба шулай күчерелгәннәрнең җитәкчесе булганга шөбһә юк, чөнки аның белән Шырданнан килгән кешеләр дә Кичүчат һәм янәшәдәге Мәмәт авылында төпләнеп калалар.

Ризаэддин Кичүчат авылының игенчелек белән көн күрүче мәхәллә мулласы гаиләсендә — күп балалы гаиләдә үсә. Башлангыч белемне әнисе Мәһүбәдән ала, аннан соң малайны ул вакытларда атаклы булган Түбән Чыршылы (яки Чәшеле) мәдрәсәсенә укырга бирәләр (бу авыл Татарстанның Лениногорск төбәгендә урнашкан). Шул вакытларда Ризаэддин, Түбән Чыршылы мәдрәсәсен ташлап, бер ел Чистай шәһәрендәге атаклы Закир ишан Камалов мәдрәсәсендә дә укып ала.

Ул гаҗәп тырышлык белән күп укый, һәм үзе дә дәресләр бирә. Мәдрәсәдә укуының соңгы елларында аның гарәп теле, шәригать хөкемнәре мәсьәләләренә багышланган хезмәтләре басылып чыга.

1887 елны Ризаэддин бине Фәхреддин мәдрәсә курсын тәмамлап, 1889 елга кадәр Түбән Чыршылыда укыта.

1889 елны аны Илбәк авылына (хәзерге Татарстанның Азнакай районы) имам итеп чакыралар. Ул анда 1890 елга кадәр эшли.

1891 елның февралендә Ризаэддин бине Фәхреддин Уфа шәһәрендәге Диния нәзарәтенә казый булып сайлангач, хезмәтләрен башкару өчен анда күчеп килә. Дини үзәкнең бай китапханәсе һәм кульъязмалар хәзинәсе кызыксынучан Ризаэддинне үзенә суырып ала. Аның күңелендә яңа фикерләр туа, һәм ул аларны китаплар рәвешендә халыкка җиткерү юлында эшкә керешә. 1899 елда аның беренче әдәби әсәре — «Сәлимә яки гыйффәт» басыла. 1900 елдан атаклы «Асар» био-библиографик белешмәсенең кисәк-җөзьәләре басыла башлый һ.б.

1906 елны Ризаэддин хәзрәтләрен «Шура» журналын оештырып чыгару өчен мөхәррир итеп Оренбургка чакыралар. Гәрчә әле казыйлык вазифасын ул 1909 елга кадәр үтәргә тиеш булса да, хезмәтен калдырып, Оренбургка китеп бара.

Яңа урында галим һәм язучының талантына мөмкинлекләр киң ачыла. «Шура» битләрендә аның публицистик, тарихи мәкаләләре күпләп басыла. Журнал, аның каләме сәбәпле, татар дөньясы өчен генә түгел, ә бөтен төрки-мөселман дөньясының мохитен, үткәнен, бүгенгесен чагылдырган басма буларак шөһрәт ала. Шул ук вакытта аның иң күп басылган китаплары Оренбургта эшләү дәверенә туры килә. Әхлак, тәрбия темаларына багышланган «Нәсыйхәт», «Тәрбияле ана», «Тәрбияле ата», «Тәрбияле бала», «Тәрбияле хатын», «Шәкертлек әдәбе» кебек китаплары хәтта унбер-уникешәр басма нәшер ителгәннәр. Шунысы игътибарга лаек: Ризаэддин бине Фәхреддин «Сәлимә яки гыйффәт» исемле беренче хикәясендә үк әхлак, нәсыйхәт тәрбиясен, белем алу системасын яхшырту фикерен алга сөрә. 1903 елда басылган «Әсма» повестенда да шул ук җәдитчелек фикерләре күтәрелә. Әсәрдә искелек белән яңалык арасындагы конфликт тасвирлана. Автор, явыз эшнең һәрчак җәзасы булыр, дигән фикер үткәрә. Әлбәттә, XX йөзгә кереп килгәндә татар әдәбиятында мондый типтагы әдәби әсәрләр саны аз булганга, Ризаэддин бине Фәхреддин прозасы татар укучысын әсәрләндергән.

Моннан тыш галимнең Ш.Мәрҗани, Ибне Фадлан, Ибне Баттута, Ибне Гарәби, Ибне Таймия, Имам Газали һ.б. көнчыгыш галимнәренең мирасларын өйрәнүгә багышланган хезмәтләре әле бүген дә милләтебез өчен файдалы, белем чишмәләре булып саналырлык кыйммәткә ия.

1918 елны «Шура» журналы һәм «Вакыт» газетасы шул чордагы башка татар матбугаты язмышына тап булалар — ябылалар.

Ризаэддин хәзрәтләре эшсез һәм ашсыз кала. Уфага күчеп кайтып, Диния нәзарәтенә эшкә урнаша.

1921 елның декабрендә мөфти Галимҗан Баруди, ачларга ярдәм оештыру юлында йөргәндә саулыгын югалтып, үлеп кала. Аның урынына, бердәм рәвештә, Ризаэддин бине Фәхреддин сайланып куела.

1925 елны Ризаэддин хәзрәтләре Русия Фәннәр академиясе оештырылуга 200 ел тулу мөнәсәбәтендә Ленинград шәһәрендә уздырылган юбилей тантаналарына чакырыла. Ул анда Көнчыгышны — мөселман культурасын өйрәнүче галимнәр белән таныша, аралаша.

1926 елның җәендә Ризаэддин хәзрәтләре Мәккә шәһәрендә уздырылган Мөселманнарның Бөтендөнья конгрессында катнаша.

Бу елларда Ризаэддин бине Фәхреддин Дини идарә архивын тәртипкә китерү буенча зур эш башкара, китапханәне тәртипкә сала, фәнни хезмәтләр яза. Бүгенге көндә аның Уфадагы архивында 40 томлык басылмаган хезмәтләре саклана. Бу хезмәтләр арасында аеруча татар әдәбиятына, тарихына караган кульъязмалар һәм башка документлар бик мөһим.

XX гасыр башы татар мәдәнияте тарихына Ризаэддин Фәхреддин ясаган тәэсирне Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Г. Тукай, Г. Исхакый иҗатлары белән генә тиңләштерергә мөмкин.

Ризаэддин бине Фәхреддин илдә барган кызыл-көрән террорның күтәрелеп барган чорында — 1936 елның 12 апрелендә 77 яшендә вафат була.

## «Рәсми тәрҗемәи хәлем»

*(Ризаэддин Фәхреддиннең*
*үзе язган тәрҗемәи хәленнән)*

...Иң соң мәртәбә буларак Оренбург Дини Идарәсе тарафыннан 1903 елда язылган тәрҗемәи хәлем бу рәвешле:

Ахун Ризаэддин бине Фәхреддин бу көндә Оренбург Дине мөхәммәди мәхкәмәсендә әгъза, 44 яшендә. Мәзһәбе — Ислам. «Тырышлык өчен» дип язылган, муенга аса торган көмеш вә алтын медальләре бар, Станиславский лента белән. Хезмәтенә тәгаен ителгән еллык вазифасы — 800 сум. Бөгелмә өязе Кичүчат авылында агач йорты булып, шуннан башка ни үзенең, ни хатынының милекләре юк. Бөгелмә өязе Түбән Чыршылы авылында булган мәдрәсә хозурында укыган. Бөгелмә өязе Илбәк авылы халкының сайлауларына күрә, Самара вилайәт мәхкәмәсе (губерна идарәсе) тарафыннан 1889 ел 11 июльдә имам дип расланды.

Ошбу дәрәҗәсенә 1891 ел 24 августта ахунлык исеме кушылды. Кичүчат халкының сайлавы буенча, Эчке эшләр министрлыгының рөхсәте илә Самара вилайәт мәхкәмәсе тарафыннан, җамигъ мәчете имамы буларак, 1892 ел 8 гыйнварда расланды. Падишаһ мәрхәмәте буларак, 1894 ел 30 гыйнварда көмеш вә 1897 ел 1 гыйнварда алтын медаль бирелде. Дәүләт Советы тарафыннан күтәрелеп, император 1890 ел 9 гыйнвардараслаган канун буенча Оренбург мөфтие тарафыннан тәкъдим ителеп, Эчке эшләр министрлыгыннан Оренбург Дине мөхәммәди мәхкәмәсенә өч елдан өч елга ошбу рәвешчә билгеләнде:

1891 ел 12 гыйнварда 1891—1893 еллар өчен;
1893 ел 19 ноябрьдә 1894—1896 еллар өчен;
1896 ел 11 декабрьдә 1897—1899 еллар өчен;
1899 ел 10 декабрьдә 1900—1902 еллар өчен;
1902 ел 5 октябрьдә 1903—1905 еллар өчен.

Хәрби походларда һәм сугышта булмады, хөкем астында калганы юк, хезмәтеннән бушанып отпуск алып йөргәне юк, гражданский чины да юк...

## ШАГЫЙРЬ КӘШШАФЕДДИН МИНЗӘЛӘВИ

Кәшшафеддин Шаһимәрдән улы Минзәләвинең исеме әдәбият тарихында күренгәләп китсә дә, аның турында төпченеп, зурлап беренче язучы Сарман журналисты һәм шагыйрь Дамир Гарифуллин булды. Шуннан соң бу шагыйрь хакында әһәмиятле фикер әйтеп язучылар күренмәде әле.

Кәшшафеддин 1864 елда хәзерге Сарман төбәгенә караган Сөлек авылында таза хәлле игенче

гаиләсендә туып үсә. Башлангыч белемне Мәрҗани шәкерте булган авыл имамы мәдрәсәсендә ала һәм укуын, Казанга барып, Шиһабеддин Мәрҗанинең үзеннән дәвам итә. Анда тугыз ел укыгач, 1892 елны тәмамлап, Уфага барып имамлыкка имтихан тотып, указ ала. Шуннан соң ул Семипалат губернасындагы Каркаралы мәчетенә имам һәм мөдәррис итеп җибәрелә.

Кәшшафеддин үзен Шиһабеддин Мәрҗани шәкерте дип саный, җәдид ысулы белән укыта. Ул имам булган Каркаралы мәчетен казах акыны Абайның әтисе Конанбай салдырган була.

Кәшшафеддин бине Шаһимәрдән бине Габдулла бине Фәтхулла әл-Минзәләви әс-Сөлүкинең балалары да укытучы булып киткәннәр. Аның иҗат эшчәнлеге XIX гасыр ахырында башланган, ул, йөзгә якын кыйсса китаплары бастырып, татар һәм казах телләрендә иҗат иткән.

Кәшшафеддин Минзәләви 1919—1920 елларда исән була. Әмма соңгы язмышы мәгълүм түгел. Аның иҗади эшчәнлегенә казах әдәбиятчылары югары бәя бирәләр. Якташыбыз — татар һәм казах халыкларын әдәбият өлкәсендә якынайтуга зур хезмәт куйган кеше.

Кәшшафеддин Минзәләвинең иҗатында балаларга рух һәм әхлак тәрбиясе, дини һәм дөньяви белем бирү, иман ныклыгы һәм дөньяга караш киңлеге мәсьәләләре күтәрелә.

## «Әдәпле бала» китабыннан

Яраткан Аллаһ тәгаллем,
Балаларга әдәб телим.
Шәригатьтә сөбат телим,
Кабул кыйлгыл рәхмәт әйләп.
Балаларның арасында,
Бу фәкыйрьгә рәхмәт әйлә,
Язганларым кабул әйлә,
Ихсан кыйлгыл фазыл әйләп.
Моны язган Кәшшафеддин,
Каркаралы мөгалиме иҗтиһаддин.
Остазы Мәрҗани Шиһабеддин.
Нисбәтдә әйтәде Сөлүки дип,
Әйтмәк җаиз Каркаралы мөгалиме дип...

## ТАРИХЧЫ ҺАДИ АТЛАСОВ

Һади Мифтахеддин улы Атласов (Атласый) 1876 елда Сембер губернасы Буа өязе Чәке авылында мулла гаиләсендә туган. Башлангыч белемне атасыннан ала. Аннан Буа шәһәрендәге Нургали Хәсәнов әл-Морзави мәдрәсәсендә укуын дәвам итә. Андагы схоластик укытудан канәгатьләнмичә, Оренбург янындагы Сәгыйть бистәсендә ачылган яңа методлы Гани бай мәдрәсәсенә күчеп укый башлый. Бу мәдрәсәдә Һади Атласовның остазы Фатих Кәрими дә була. Ул яңа мәдрәсәдә дөньяви фәннәрдән белем алып, канәгатьлек белән, 1898 елда Буага кайтып, укыту эшенә керешә. Ләкин Буадагы иске фикерле хәлфәләр белән аның арасында көрәш башлана. 1900 елны Һ. Атласов, дөньяви белемнәр өйрәнүне дәвам итү өчен, яңадан Сәгыйть бистәсенә китә. Анда белемен тагы да күтәреп Буага кайта һәм, җиң сызганып, яңадан укыту эшенә керешә. Бу елларда дөньяви белемнәрне пропагандалап «Гыйльме һәйәт» («Астрономия фәне») һәм «Тарихе табигый» («Табигать тарихы») исемле әсәрләр язып бастырганы мәгълүм.

1903 елда Һади Атласов Бөгелмә өязе Әлмәт авылына (хәзерге Әлмәт шәһәренең башлангычы) имам һәм мөдәррис итеп чакырыла. Ләкин Әлмәттә дә искелек тарафдарлары аның яңалык яклы эшләренә каршы чыгып, матди һәм мәгънәви зыяннар китергәннәр. Шулай да ул язу эшләрен ташламый. Тикшеренүче галимнәр аның бу елларда «Ахырзаман ишаны», «Идел буе», «Мәктәп вә мелла» исемле әсәрләре басылуын язалар.

1905 ел революциясен Һади Атласов хуплап каршылый. Аның 1906 елда көчле публицистик рух белән язылган «Яңа низам вә голямаларымыз» исемле китабы басыла. Китап татар халкының культура хәзинәләрен һәм мәктәбен юк итүгә хәзерлек алып барган карагруһлар планының 1905 ел революциясе шартларында барып чыкмавына шатлык белән язылган. Бу китап өчен, революция җиңелеп, кара реакция еллары башлангач, 1909 елда аны җавапка тарталар, һәм ул берничә ай төрмәдә утырып чыга. Аннан чыккач, ул муллалык урыныннан һәм мөдәррислектән мәхрүм ителә.

Һ. Атласов шул вакыттан соң тарих фәннәре буенча тикшеренү эшләренә чума. 1912 елның беренче яртысында аның иң әүвәлге зур тарихи әсәре «Себер тарихы» басылып чыга. 1914 елда «Сөен-бикә» һәм «Казан ханлыгы» кебек зур күләмле тарихи хезмәтләре дөнья күрә. Татар тарихчылары бу хезмәтләрнең бай фактик материал нигезендә язылуын билгеләп узалар. Аның «Сөен-бикә» һәм «Казан ханлыгы» китаплары, фәнни кыйммәте булу сәбәпле, 1922, 1924 елларда кабаттан басылганнар.

Һади Атласовны 1913 елны археология җәмгыятенә әгъза итеп сайлыйлар.

Тарихчының иҗтимагый эшчәнлеге революциягә кадәр чыккан татар матбугаты битләрендә басылган дистәләгән мәкаләләрендә дә чагыла. «Әл-ислах», «Йолдыз», «Кояш», «Вакыт» газеталары, «Шура» журналы битләрендә аның мәктәпләр реформасы, иске тарих, тел, татар халкына карата милли һәм дини рәнҗетүләр һ.б. темаларга язылган мәкаләләре басылып чыккан.

Октябрь инкыйлабыннан соң Һади Атласов халык мәнфәгатьләренә хезмәт итүен дәвам итә. Ул вакытларда аклар, чехлар кулында калганда да азатлык, бәхет өчен көрәшүчеләрне үлемнән коткара: берничә большевикны 1918 елны атып үтерелү куркынычыннан йолып алуга ирешә.

Һади Атласов 1921—1929 елларда Бөгелмә шәһәрендәге икенче баскыч мәктәптә тарих, немец телләре укыта; 1925 — 1928 елларда фарсы әдәбияты ядкәре «Гөлстан»ны татарчага тәрҗемә итү белән шөгыльләнә һ.б.

1929 елда СССРда укымышлы кешеләрне юк итү буенча яңа кампания чорында, Һади Атласов, солтангалиевчелектә гаепләнеп, ун елга лагерьга ябылуга хөкем ителә. Аны Карелия сазлыкларында Беломор-Балтыйк каналын казуда файдаланалар. Үзе белән 1928 —1929 елларда кулга алынган сәяси тоткыннар рәтеннән, Һади Атласовны бу лагерьдан 1933 елда чыгаралар. Ул, Казанга килеп, олы кызы янына пропискага керә. Озак вакытлар эш таба алмый йөргәннән соң, бер мәктәпкә география һәм немец теле укытырга урнаша. Ләкин озакламый аны эзәрлекләү яңадан башлана. Һади Атласовны эшеннән бушаталар, авыр көннәр килеп җитә. 1936 елның 27 июлендә аны кулга алу турында ордерга кул куела. Коточкыч газапларга дучар ителгән Һади Атласовны 62 яшендә, 1938 елның 15 февралендә, Казандагы власть башында утырган палачлар боерыгы белән атып үтерәләр. Русия империализмының татар халкына карата кылган меңләгән канлы җинаятьләре исемлегенә Һади Атласов һәлакәте дә өстәлә. Үз халкына фидакарьләрчә эшләү үрнәге белән, Һади Атласов истәлеге мәңге сакланырга тиеш.

## «Сөен-бикә» китабыннан

Шәехгали чын рус колы вә шуның илә бәрабәр сөйкемсез һәм булымсыз кеше булганлыктан, Сөен-бикә аны яратмыйдыр иде. Аның болай булуы Шәехгалине дә Сөен-бикәдән суыткан, ул Сөен-бикә илә чын татар ирләречә эш итә башлаган иде. 1553 елның җәендә «Шәехгали, Иванның кушуы буенча, Сөен-бикәнең борыныны кискән, аны зур сыйсызлыклар күрсәтеп үлтергән икән» дию нугай йортында бер хәбәр таралды. Бу хәбәр Сөен-бикәнең атасы илә анасына чиктән тыш агыр тоелды. Болар, Сөен-бикәнең Шәехгали илә тату тормауларыны белгәнгә күрә, теге хәбәргә ышанганнар иде. Ул хәбәр нугай йортында байтак шау-шуга сәбәб булды. Исмәгыйл, Касай, Юныс мирзалар да 1553 елда Иванга ярлык язганнар, шул эш тушмасендә Иваннан сорашканнар иде. Шәехгалинең Сөен-бикәгә сыйсызлык итүе бөтенләй төпсез түгел иде исә дә, Сөен-бикәне үлтерүе дөрест түгел иде. Иван, Юныс мирзаның Зин-Гали исемле илчесе илә Гали мирзаның Бәхет-килде исемле илчесене Касым шәһәренә җибәреп, үз күзләре илә Сөен-бикәне күрергә боерды. Аның болай итүе теге хәбәрнең төпсезлегене нугайларга белдерү өчен иде... Урыс патшасының Юныс мирзага язган ярлыгында: «Бөтен русның падишаһысы һәм олыгъ кенәзе булган Иваннан Юныс мирзага сүз шул: син үзеңнең егетең Җангалине безгә ярлык илә җибәргән, агаң Исмәгыйл ушандак үзеңнең 8 туганың илә безгә яхшылык теләгәнеңне, атаңызны безнең илә дошман булудан тыйганлыгыңызны, аның яман уйларына баш бирмәгәнлегеңне язган идең... Без синең тугъры булучылыгыңны үземезнең казакларымыз Бәхет-Яр илә иптәшләреннән дә ишеткән идек. Синең шушы тугърылыгыңны без бик яратып, сине мәңгелеккә дуст итеп тотарга булдык. Сине үземезнең олыгъ багышлавымыз илә багышламакчы буламыз... Хатыннар сүзе буенча йөреп, синең атаң безгә үпкәлидер. Аның кызы Сөен-бикәнең Казанда чагында безгә күпме әшәке

лекләр кылганлыгы синең үзеңә мәгълүм. Алла безнең кулымызга аны биргәч тә, атаңыз һәм сезнең өчен, аның әшәкелекләрен онытдык. Сезнең дустлыгыгызны искә төшереп, аңа зур сыйлар күрсәттек. Зур багышлаулар илә багышлап, Шәехгали ханга бирдек. Углы Утамышгәрәйне исә, үземезнең дингә кертеп, үз янымызда угыл итеп тотамыз. Аның исеме, безнең динемезчә, Александр булды. Алла боерып үскәч тә, аны яхшы йорт илә багышлаячакмыз. Дошман булган

кеше безнең яхшылыкларны итәме?..» — дигән сүзләр бар иде...

Шушындый эчтәлектәге ярлыклар 1554 елның гыйнварында Йосыф, Гали, Касай, Шәехгалиләргә дә язылганар иде.

Шушы елдан соң тарихларда Сөен-бикә төшмәсендә хәбәрләр киселәдер. Аның кайсы елда вә кайда үлгәнлеге ачык билгеле булмаса да, 1554 елдан соң озак тормаган, үлүе Касым шәһәрендә булган икәнлеге аңлашыладыр. Казанлылар Сөен-бикәне Иван кулына тапшырулары илә тынычланмакчы булганнар иде дә, эш алар теләгәнчә барып чыкмады. Сөен-бикә канлы яшьләрене агызып Казаннан аерылдыгы кеби, аның китүеннән бер ел соң казанлыларның үзләренә дә Казаннан еглап аерылырга туры килде.

Сөен-бикәнең агыр үлем илә вакытсыз үлүендә казанлыларның нә чаклы гөнаһлары булса, нугай мирзаларының да шул чаклы гөнаһысы булды. Нугай мирзаларының һич берсендә дин, милләт кайгысы булмадыгы кеби, туганлык кайгысы да юк иде...

## ЯЗУЧЫ ҺӘМ ЖУРНАЛИСТ ФАТИХ КӘРИМИ

Егерменче гасыр башы татар әдәбияты һәм публицистикасының күренекле вәкиле, әдип һәм журналист Фатих Гыйльман улы Кәрими Әлмәт шәһәре янындагы Миңлебай авылында 1870 елның 30 мартында ахун-мулла гаиләсендә туа. Башта атасында укый, аннан соң Чистай шәһәрендәге атаклы Закир Камалов мәдрәсәсендә белем ала, гарәп, фарсы телләрен үзләштерә.

Фатих Кәрими 1891 елда Төркиягә китеп Истанбул университетында укый, француз телен камил үзләштерә. Анда укуын 1896 елда тәмамлап, Кырымда яңа методлы мәдрәсәдә укыта башлый. 1898 елда Бакчасарайда яңа методлы мәктәп укытучылары өчен оештырылган курсларга җитәкчелек итә, әдәбият, педагогия дәресләре укыта. Нәкъ шушы елларда атасы Гыйльман ахун, муллалыгын ташлап, Оренбургка күчеп килә. Ул анда бакчачылык белән шөгыльләнә, нәшрият, типография эшләрен оештыруга хәзерләнә. Атасы Фатихны Оренбургка чакырта һәм аның үз планы буенча Мәскәүгә бухгалтерия курсларына укырга җибәрә. Ул анда бухгалтерлыкка да, типография эшләренә дә өйрәнеп кайта. Күп телләр белгән әзерлекле егетне алтын приискасы хуҗасы Шакир Рәмиев Европа сәяхәтенә иптәш итеп ала. Европа буйлап дүрт ай сәяхәттән соң, Фатих Кәрими Оренбургка кайта. Сәяхәт аның өчен гаять тәэсирле була. Ул үзенең күргәннәрен «Аурупа сәяхәтнамәсе» исемле китабында тасвир итә. Бу китабы Петербургта 1902 елда басылып чыга. Сәяхәттә күргәннәре Фатих Кәримине үз халкының язмышы турында тирән уйларга этәрә.

Фатих Кәрими 1905 елгы революциядән соң актив журналистлык эшенә чума. Ул 1906 елның 21 февраленнән Оренбургта чыга башлаган «Вакыт» газетасының мөхәррире булып эшли башлый.

«Вакыт» газетасы ул чордагы татар басма органнарының иң абруйлысы һәм тарала, укыла торганы була. Газета, Зәки Вәлиди тарафдарлары кулы белән, 1918 елның 26 гыйнварында погром юлы белән ябыла. Башкорт милләтчесе Шамигулов, «Вакыт»ка бетәргә вакыт, дип, редакцияне мылтыклы солдатлары белән туздыра, пычрак итекләре белән аның архивын таптата.

«Вакыт» газетасы редакторы булып эшләгән вакытта Фатих Кәрими, 1912 — 1913 елларда Балкан сугышына дучар булган Төркиягә барып, аннан сугыш хәрәкәтләре хакында тирән эчтәлекле хәбәр-мәкаләләр җибәреп тора. Алар газетада «Истанбул мәктүбләре» исеме астында басылып торалар. Фатих Кәрими язмаларында бу сугышның асылын фаш итеп, аның төрек дәүләтен юк итәргә теләгән Европа империалистлары максатыннан чыгып алып барылуына ачынып яза. «Истанбул мәктүбләре» татар язучысының гасырларга калдырган мәңгелек әсәре булып тора.

Фатих Кәрими 1919 елда Оренбургта татарлар өчен ачылган мәгариф институтында укыта башлый. Бу елларда ул Оренбургта чыга торган «Эшчеләр дөньясы», «Юл», «Сабан», «Яңа вакыт» газеталарында язышa.

Оренбургтагы мәгариф институтында Фатих Кәрими әдәби түгәрәк оештыра. Бу түгәрәктә Муса Җәлил дә йөреп, аның җитәкчесе Фатих Кәрими фатихасы белән Казанга укырга китә.

1925 елның гыйнварыннан Фатих Кәрими Мәскәүдә яши. Анда оештырылган СССР халыкларының үзәк нәшриятында эшли. 1930 еллардан башлап Фатих Кәрими властьлар тарафыннан эзәрлекләнә башлый. Ул, иҗат эшен ташлап, Мәскәү югары уку йортларында укыту эше белән генә шөгыльләнергә керешә. НКВД органнары Фатих Кәримине барыбер тынычлыкта калдырмыйлар. Аңа «халык дошманы» дигән нахак ярлык тагыла, 1937 елның 27 сентябрендә ул атып үтерелә. Патша охранкасы тарафыннан XX гасыр башында ук җентекле, даими күзәтү астында яшәгән язучы һәм галимнең тормышы шулай фаҗигале рәвештә өзелә.

Фатих Кәрими XIX гасыр ахырында ук язучылык эшенә керешә. Аның 1898 елда язылган «Җиһангир мәхдүмнең авыл мәдрәсәсендә укуы» хикәясе 1900 елда Петербургта басыла. Бу хикәя, шул чорның татар укымышлылары тормышын оста чагылдыруы сәбәпле, әдәбиятчы галимнәр тарафыннан югары бәяләнә.

Казанда 1899 елда басылган «Бер шәкерт илә бер студент» хикәясендә XIX гасыр ахырында татарлар арасында күренә башлаган прогрессив карашлы кеше тибын тасвирлый.

Гомумән алганда, Фатих Кәриминең бөтен иҗат эшчәнлеге мәгърифәтчелек идеяләре белән сугарылган. Аның тарафыннан XX гасыр башында ук татар шәкертләре өчен мөһим булган дөньяви фәннәрдән дәреслекләр — география, тарих, уку китаплары, атласлар бастырыла. Урыс теленнән тәрҗемә итеп, дөньядагы 26 халык турында тарихи-этнографик очерклар сериясен нәшер итә. Аның Европага, Кырымга ясаган сәяхәтләрен тасвирлаган китаплары, «Истанбул мәктүбләре» кебек документаль-публицистик әсәре, замандашларына язган хатлары, атасы Гыйльман ахунның үлеменә багышланган китабы, дистәләрчә хикәяләре татар әдәбиятының беркайчан да кыйммәтен югалтмый торган сәхифәләрен тәшкил итәләр.

## «Аурупа сәяхәтнамәсе» китабыннан

*(бүгенге телгә күчереп бирелде)*

...Алманияле Жан Гутенбург тарафыннан матбагачылык сәнгате ачылганнан бирле биш йөз еллар вакыт кичсә дә, Русиядә безнең мөселманнарның бу һөнәрдән шәхсән файдалана башлаулары күптән түгелдер. «Коръән Кәрим» һәм башка мөселман китаплары Русиядә байтак вакытлардан бирле басылып киләләр инде. Матбагачылык фәннең һәм гыйлемнең иң бөек ярдәмчесе булганлыктан, матбагачылар да гыйлем вә мәгарифнең хезмәтчеләре булып саналалар. Русиядә мөселманнардан иң беренче мәртәбә матбага ачу кемгә насыйп булгандыр, минем аннан хәбәрем юк, әмма Петербургта иң беренче мөселман матбагасы ачу бәхете Ильяс морза Бораганский исемле бик тырыш затка туры килә. Ильяс морза Кырым татарлары нәселеннән булып, асыл ватаны — Бакчасарайдыр. Сабыйлык гомерен Кырымда уздырганнан соң, ул, Русиянең кайбер өлкәләрен урап йөреп, Петербургка килеп төпләнә. Үзенең хезмәтенә мөнәсәбәтле рәвештә бөек урыс галимнәреннән күп белемнәр алып, көннән-көн галимлеге арткан һәм фикере ачылган. Ниһаять, бер матбага ачып, басмачылык эшенә керешә. Билгеле бер вакыт узгач, Бораганскийның бу эшләре урыс халкының күренекле кешеләре игътибарына лаек була. Шул сәбәптән ул Петербург император университетының Көнчыгыш телләре бүлегенә госманлы теле укытучысы итеп билгеләнә...

4 март, якшәмбе көнне ошбу Ильяс морза белән күрешергә бардык. Аның яшәү урыны һәм матбагасы Петербургның бер тарафында булган Волков дип исемләнгән авылдагы мәхәлләдә иде. Ак йөзле, мөлаем чырайлы, ачык күңелле Ильяс морза безне бик матур кабул итте. Матбагасында басылып чыккан «Мишкәт шәриф», «Җәлал», «Мохтасар», «Фәраиз» һәм башка китапларны күрсәтте, басмаханәсен тамаша иттерде. Анда ул урысча, французча, немецчә һәм башка телләрдә китаплар бастырырга җыена икән. Соңыннан бу басмаханәдә корректорлык хезмәтен башкаручы Госман Нури әфәнде Акчукраклызадә исемле бер яшь кеше белән күрештек. Бу зат мөселманча һәм урысча яхшы белемле кеше булып, аның каләм осталыгын күрсәткән «Бакчасарай чишмәсе», «Нәнкәҗан ханым», «Мөляхаза» исемле әсәрләре белән танылган иде. Ул да — Кырымның Бакчасарай өлкәсеннәндер.

Кире борылып кайткан чагыбызда «Исаковская» исемле чиркәүне һәм Нева елгасы ярында «Казанский собор» исемле кафедраль чиркәүләрне тамаша иттек. Боларның гүзәл архитектурасы, эчләрендә булган кыйммәтле металлардан, ташлардан бизәп эшләнгән җиһазлары чынлыкта тәэсирле тамашалар иде. Боларның беренчесен эшләү өчен егерме миллион сум акча тотылганлыгын сөйлиләр...

Ахшамнан соң «Александровский» исемендәге театрга бардык. Бу тамаша йортында фаҗигале вакыйгаларга бәйле уеннар куела. Без барган ахшам кичендә «Икенче яшьлек» исемле уен күрсәтелде...

## КӘБИР ТУЙКИН

Кәбир Кәрим улы Туйкин 1878 елның 13 мартында Зәй-Каратай авылында дин эшлеклесе гаиләсендә туган. Ул — шагыйрь, драматург һәм фольклорчы Фазыл Туйкинның бертуган агасы. Башлангыч белемне туган авылында ала, соңрак Казанга килеп «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга керә. Мәдрәсәне тәмамлагач, Кәбир Туйкинны армия хезмәтенә алалар. Хезмәт итеп

кайтуга, ул үз авылында укытучы булып эшли башлый. Укыту дәверендә ул авыл халкына яңача укыту кирәклеген аңлата. Кадимче элементлар Кәбир Туйкинның эшчәнлегендә үзләренә куркыныч күрәләр, өстеннән язып, төрмәгә яптыруга ирешәләр. Кәбир Туйкин 10 ай чамасы төрмәдә утырып чыга. Төрмәдән чыккач та аны тынычлыкта калдырмыйлар, физик юк итү белән яныйлар. 1909 елда Кәбир семьясын алып Оренбургка күчеп килә. Анда ул «Шура» журналы редакциясенә эшкә урнаша. Язган әсәрләреннән Казанда 1912 елда басылган «Яман юлдаш» хикәясе мәгълүм. Ләкин реакцион көчләр Кәбирне эзәрлекләүне дәвам итәләр.

1914 елны Кәбир Туйкинны герман сугышына алалар.

Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң ул яңадан укыту эшенә керешә.

Колхозлашу чоры башлангач, Кәбир Туйкин, туган авылына кайтып, колхоз оештыруда актив катнаша. Аның иҗтимагый эшчәнлеге укыту белән генә чикләнми, ул татар мәгариф системасының актуаль мәсьәләләре буенча мәкаләләр, татар мәктәпләре өчен дәреслекләр язып бастыра, хикәя һәм шигырьләре дөнья күрә.

Кәбир Туйкинның гомере шәхес культы елларында өзелә. Аны 1937 елда кулга алып, хөкем итеп, 1938 елның 11 февралендә Казанда атып үтерәләр. Аның тормышы һәм иҗат эшчәнлеге өйрәнелмәгән диярлек. Безгә аның 1918 елда Оренбургта энесе Фазыл Туйкин белән берлектә язылган «Төрек тарихы» дәреслеге генә билгеле.

## ФОЛЬКЛОРЧЫ, ӘДИП ҺӘМ ПЕДАГОГ
## ФАЗЫЛ ТУЙКИН

Фольклорчы, язучы һәм педагог Фазыл Кәрим улы Туйкин (Туйкә) мирасы да безнең өчен кадерле. Ул 1887 елның 22 июнендә Зәй-Каратай авылында дин эшлеклесе гаиләсендә туган (хәзерге Лениногорск төбәге). Башлангыч белемне туган авылында ала, Уфа мәдрәсәсендә укый һәм соңыннан, Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен 1904 елда тәмамлап, Зәй-Каратай авылына укытырга кайта. Анда 1909 елга кадәр эшли, 1909—1911 елларда исә Ташлы авылында укыта (Баулы районы).

Мәдрәсәдә укыткан вакытында, Габдрахман авылында яшәүче язучы Афзал Таһиров белән берлектә, «Тегермән» исемле кулъязма журнал чыгаралар.

Ташлыдан соң, 1911—1912 елларда Уфада «Хәкимия» мәдрәсәсендә эшләп ала. Уфадан Бөгелмә ягындагы Кәкре Елга авылына укытырга килеп, монда 1917 елгача кала. Февраль революциясеннән соң, Бөгелмә мәктәпләрендә эшли башлый.

Илдә 1930 елларда башланган репрессияләр кампаниясе Фазыл Туйкинга да кагыла. Аны эзәрлекләү, әйберләрен бастырмау еллары башлана. 1937 елны Фазыл Туйкин Һади Атласов белән берлектә халык дошманы итеп игълан ителә һәм 1938 елның 11 февралендә Казанда атып үтерелә.

Ул үзенең эшчәнлеген шагыйрь буларак 1906 елда башлый. Аның беренче шигырьләре Җаек (Уральск) шәһәрендә татар телендә чыга башлаган «Фикер» газетасында басыла. 1912 елда «Сугышчы Сатыш әфәнде» хикәясе, «Ватан каһарманнары», «Тормыш корбаннары» пьесалары, «Җырлар әхтәрисе» исемле фольклор җыентыгы нәшер ителә. Уфада 1915 елда «Нардуган» исеме белән шигырьләр җыентыгы дөнья күрә. 1919 елда абыйсы Кәбир Туйкин белән берлектә язылган «Төрек тарихы» дәреслеге басыла, Казанда 1922 елда балалар өчен язылган «Салих бабай» пьесасы нәшер ителә.

Фазыл Туйкин татар фольклорын — җырлар, мәкальләр туплаган, бастырган, алар хакында фәнни мәкаләләр язган.

Ул әдәбият тарихы буенча да кыйммәтле хезмәтләр калдырган. Мәсәлән, Мәүла Колый әсәрләрен табып, өйрәнеп, бу хакта «Кызыл Татарстан» (1926, 9 апрель, № 81) газетасында һәм « Безнең юл» (1928, № 9) журналында мәкаләләр бастыра. Мәүла Колый шигырьләре җыентыгы Ф.Туйкин тарафыннан тулысынча күчерелә, һәм шуның аркасында шагыйрь иҗаты татар әдәбияты тарихына кереп китә.

Ф. Туйкинның күп кенә хезмәтләре аны 1930 елларда башланган эзәрлекләүләр аркасында басылмыйча кала. Шулар арасында 1934 елда җирле сәхнәләрдә уйналып йөргән «Мәгариф корбаннары» пьесасы да бар. Ф. Туйкинның кайбер әсәрләре Уфа матбугатында да басылганнар. Мәсәлән, 1927 елда «Чәчән» журналында «Иделбай» исемле поэмасы дөнья күргән.

Фазыл Туйкинның иҗат мирасы соңгы елларда гына өйрәнелә башлады.

## «Сугышчы Сатыш әфәнде»

*(өзек)*

Бетмәс-төкәнмәс һөҗүмнәр сәбәпле Болгар дәүләтенең шөһрәте шактый гына кимегәнлектән, болгар халкында әллә нинди бер өметсезлек сизелә башлаган иде. Гүя аларны алларында әллә нинди куркыныч бер һәлакәт көткән шикелле, һәркем эчпошыргыч күңелсез бер хәлгә төшкән, һичбер нәрсәгә күңелләрен утырта алмыйча, үлемгә хәзерләнгән кеше төсле, һәрнәрсәгә өметсезлек күзе белән карап, рухлары сүнгән, гайрәтләре дә яхшы ук сүрелгән иде. Халыкның инкыйразга хәзерләнгән төсле бу ямансу кыланышларыннан Дәүләт авылының да тәэсирсез калмаганлыгы бик ачык күренә иде. Дәүләт авылы халкы да күңелләрендә бер төрле курку зәһәре булганлыкны сизенәләр. Әй, заманалар әллә ничегрәк, дип, халыкның күңеле тынычсызланганлыктан, шикләнүләрен үзара аптырашып сөйләшәләр, тора-торгач, сугышчы Кармыш агайның йортына җыелып, замананың барышы бозылудан зарланалар, яшь вакыттагы тынычлыкларын сагынып куялар, Кармыш агайны да төрле сораулар биреп йөдәтеп бетерәләр иде. Ул беркадәр сугышларда булып, сугышчы Кармыш абзый исемен күтәргән, сугыш вакытында күргән мәшәкатьләрен, анда йөргәндә җыйган мәгълүматларын, башлыкларына иткән хезмәтләрен, алардан ишеткән рәхмәтләрен сөйләп, халыкка төрле гакыллар биреп, белекле һәм булдыклы исемен дә алып, авылларында игътибарлы санала торган бер карт булганга, аңардан төрле вакыйгалар хакында сорашалар, киңәшәләр, аның сөйләгән сүзенә төрле мәгънәләр биреп үзара даулашалар, шулай итеп, күңел ачарга, хәсрәт таратырга юллар эзләп карыйлар иде.

Кармыш агай исә, бер дә каушамаган рәвештә, һичнәрсә булачак түгел кебек итеп сөйли, хәзер генә һөҗүмнәр, сугышлар булу ихтималы юклыкны да үзенчә төрле дәлилләр белән күрсәтә, халкының болай күңеле төшеп йөрүләрен яратмый, кулыннан килгән кадәр аларны юатырга тырыша иде. Сугыш булса да борчылырга кирәк түгел, без инде дошман җиңә алудан үткән. Менә фәлән сугышта да без җиңдек, ул сугыш нинди куркыныч иде, анда да ирек бирмәдек, аның өстенә никадәр малларын алдык, дип мактанып та куя иде. Кармыш агайның бу сүзләре төрле куркыныч хәбәрләр белән күңелләре төшеп беткән халыкка бик зур юаныч бирә алмаса да, үзенең егерме биш яшьлек углы Сатыш әфәндегә ялкын кебек тәэсир итә иде.

Аның атасы кебек гаярь сугышчы буласы килә һәм, атасы шикелле үк, башлыклар тарафыннан рәхмәтләр ишетеп бүләкләр аласы килә. Замандашларына да, тегеләй йөрдек, болай сугыштык, дип, төрлечә мактанып, «гайрәтле сугышчы Сатыш» исемен ишетәсе килә иде. Сатыш әфәнденең шундый тәмле хәлләр белән башы катып беткәнгәме, әллә яшьлеге сәбәпле халыкның тынычсызлыгыннан хәбәре аз булгангамы, ул башкалар кебек рухсызланмаган, алар төсле күңелсезләнмәгән иде. Бәлки, әй, берәр сугыш булса, атам белән бергә мин дә барыр идем дә, дошманнарны җиңеп кайтыр идек, дип тели һәм шуңар хәзерләнә иде.

Ул һәркөн диярлек, иртәнге аштан соң, болгар сугышчылары кебек кыскача ак чикмәнен киеп, билен бәйли, башына да җылы эчле тирән бүреген кия, аягына күн итек киеп, кылыч-сөңге кебек коралларын ала, үзенең ярата торган кечкенә генә гәүдәле йөгерек кара атын иярләп атлана. Читтән караганда тәмам бер болгар сугышчысы рәвешенә кереп, Дәүләт авылының болыннарына чыга иде. Анда аты белән чабып, төрлечә кыланып, сугышчы сыйфаты белән йөри, кичке аш вакыты җиткәч кенә йортларына кайта иде...

Киләчәкне күңел сизә дигән шикелле, болгар халкының бу тынычсызланганлыклары бушка чыкмады, һич көтмәгән бер тарафтан Болгар дәүләтенә каты-каты һөҗүмнәр башланды. Шәһәрләр, авыллар әллә нинди бер куркыныч хәбәрләр белән тулды. Халык та нишләргә белми аптырап кайнаша башлады. Ул арада сугышчыларга бик тизлек берлән Болгар шәһәренә җыелырга башлыклар тарафыннан әмерләр дә таратылды. Сугышчылар, җыелып-җыелып, Болгар шәһәренә китә башладылар. Авыллар кызганыч бер хәлгә керде. Хатыннарның ай-вайлары, балаларның чыр-чу килеп кычкырышулары, егълашулары, сугышчыларның Алладан ялварып ярдәм сораган тавышлары берлән кушылып, һәркемнең күңелен селкетә башлады. Кармыш агай да, никадәр гаярь кебек күренсә дә, карт башы берлән сугышта чигәчәк мәшәкатьләрне уйлап тынычсызлана, артык тирән уйларга чумып, салкын гына хәзерләнә иде. Сатыш әфәнде исә бөтенләй башка бер хәлдә иде. Бу куркынычлы вакыйгалар аңарга гүя бер бәйрәм кебек күренеп, шатланган һәм бөтенләй башка бер дәрт берлән дәртләнгән иде. Анасының сүзләренә никадәр илтифат итмәсә дә, аның мондый вакытларда кызганыч бер сурәткә кереп егълавын күрергә теләмәгәннән, Болгарга җыелырга әмер таратылгач та, тавышсыз-тынсыз гына, гадәтенчә киенеп, анасыннан яшеренеп, төн уртасында атына атланып, әллә кайчан Болгар шәһәренә чапкан иде...

## ӘДИП АФЗАЛ ТАҺИРОВ

Язучы һәм драматург Афзал Мөхеддин улы Таһиров 1890 елда хәзерге Әлмәт төбәгенә караган Габдрахман авылында крестьян гаиләсендә туган. Яшьли ятим калып, үзенең туганнары тәрбиясендә үсә. Үсә төшкәч, Казанга килеп «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга керә. Аннан Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсен тәмамлый.

1911—1917 елларда патша армиясендә хезмәт итә, 1918—1920 елларда гражданнар сугышында катнаша. 1920 елда армиядән котылып, Оренбург губернасы мәгариф бүлеге мөдире булып эшли һәм анда татар телендә чыга торган «Юксыллар сүзе» газетасының редакторы булып тора. Әлеге редакциядә ул елда атаклы татар шагыйре Һади Такташ та эшли, шигырьләре бу газетада басыла.

1922—1925 елларда Афзал Таһиров Үзбәкстанда төрле җавап-лы урыннарда хезмәт итә, анда Совет властен урнаштыруда катнаша.

1925—1927 елларда ул Мәскәүдә Коммунистик академиядә укый, аны тәмамлагач, Уфага партия эшләренә җибәрелә.

1931—1937 елларда Башкортстан Үзәк башкарма комитеты рәисе постында тора. Аның гомере 1938 елда, законсыз репрессия корбаны буларак, фаҗигале рәвештә өзелә.

Афзал Таһиров иҗатын, татар язучысы буларак, 1907 елда башлый. Бу елда ул беренче әсәре — «Бичура» комедиясен язган. Комедия сәхнәләрдә дә уйналган. 1908 елда аның «Сатылган кызлар» хикәясе дөнья күрә. 1915—1916 елларда зимагурлар тормышын гәүдәләндергән «Өтрәгәләмләр» повесте языла. Афзал Таһиров 1919—1931 еллар арасында «Ач һәм ялангачлар», «Беренче көннәр», «Кияү һәм кәләш», «Күчү чорында», «Солдатлар», «Тәхетләргә ләгънәт», «Ямәлкә тавы» һ.б. исемдә хикәяләр, пьесалар, повесть, романнар иҗат итеп бастыра. 1931 елдан соң ул, татар телендә язуын ташлап, башкорт әдәбиятына хезмәткә күчә.

Афзал Таһировның әсәрләрендә татар халкының тормышы сүрәтләнә, ул татар гаиләсендә туган, татар телендә язган. Шунлыктан без аның иҗатын татар әдәбияты тарихыннан чыгарып ташлый алмыйбыз, үз мирасыбыз итеп саныйбыз.

Түбәндә Афзал Таһировның 1933 елда Казанда басылган «Солдатлар. Беренче һәм икенче китап» романыннан бер өзек (31—32 б.) тәкъдим ителә.

## Смотр

...Февраль башлары иде. Көн дә тора торган вакыттан иртәрәк уяттылар. Ком, салам белән идән юдык, итек тазарттык, киемнәрне күрсәттек.

Фельдфебель, алга чыгып тора торган корсагын киереп:«Бригада командирына җавап бирегез!» — ди. Үзе, генерал тавышы чыгарырга тырышып: «Здорово, орлы!» — ди. Бөтен рота бердән: «Здра...жала...ваше превосходительство!» Теге: «Молодцы!» — ди. «Рад стараться!» — дип кычкырабыз бар хәлебез белән. Менә шулай итеп, ярты сәгать репетиция ясыйбыз.

Ашык-пошык чәй эчкәч тә, бөтен амуниция белән киендереп, кала читенә, киң мәйданга алып киттеләр. Иртән көн җылы сыман иде, без мәйданга барып җитү белән җепшек кар ява башлады. Бөтен полкны тезделәр. Отделениеләр, взводлар, батальоннар тигезләнделәр. Рота командирлары, үз роталарындагы аерым солдатларның төймәләре дөрес каптырылмауны күреп, 10 сәгать мылтык астында тору җәзасы билгеләделәр.

«Смирно!» командасы бирелде. Биш-ун минутка тавыш тынды. Тик кырыйдагы кешенең тын алганы гына ишетелә. Батальон яки полк командиры килә торгандыр инде, дип уйлаган идек. Менә бер вакыт «вольно» командасы бирелде. Юештә таралган аякларны алыштырып, туңган кулларны беразкыймылдатып җылыткач, тагын «Смирно!» командасы, тагын шәм кебек катып тору, тагын «вольно». Шул рәвешчә иртән сәгать 7 дә барган полк кичке сәгать дүрт ярымга хәтле торды. Солдатларның битләре күгелҗемләнде, бала йоннары кабарды. Аяклары, куллары көне буе яуган яңгырлы карда суыкланды.

Сәгать бишенче яртыда «Тигезлән!» командасы бирелде. Шуның артыннан озак тормады:«Смирно!» — диделәр.

Кала ягыннан бер төркем атлы күренде. Алар полкның уң канатына туктадылар. Полк командиры чабып барып рапорт ясады. Батальоннарны бордылар, роталардан колонналар ясадылар. Полк музыкасы уйный башлады. Роталар генерал янынннан үтә башладылар. Әфисәрләр турыннан үткәндә, озын буйлы, чандыр бер картның (генерал-майорның), ниндидер шәмәхә тавыш белән: «Здорово, ребята!» — дигән тавышы колакка чалынды. Без «һау»лап җаваپладык.

Безнең рота командиры, генерал яныннан узгач, бер читкә чыкты, зур эш башкарган кешегә охшап, маңгаен сыпырды. Взвод алдыннан килүче рота командиры Зелинскийга: «Подпоручик Зелинский, ротаны алып кайтыгыз!» — дип боерык бирде.

Зелинский, рота командирларының артта калганын күргәч тә, авыз эченнән кемнедер сүкте. Безгә аның: «Шушындый смотр белән солдат азаплаган өчен сезне суктырырга кирәк», — дигән сүзләре генә ишетелде.

Фельдфебель рота кырыеннан: «Айт-два! Айт-два!» — дип команда биреп килсә дә, Зелинский, артка карап алгач: «Иркен кайтыгыз, егетләр!» — диде.

Без, баткакланган урам карын ярып, казармага кайттык.

## ЗӘКИҖАН ШАҺГӘРӘЕВ

Әлмәт төбәгеннән XX гасыр башларында әдәбият мәйданына чыккан язучыларның берсе — Зәкиҗан Шаһгәрәев. Тарих фәннәре кандидаты Таһир Кәримов тапкан информациягә караганда, ул 1882 елда Камы Исмәгыйль авылында туган.

Аның тормыш юлы хакында мәгълүматлар юк дәрәҗәсендә иде. Бу хакта беркадәр күләмдә Азнакай төбәге Сарлы авылында яшәгән Таҗелбәнат Фазлыйәхмәт кызы Дәүләтгәрәевадан (1893 елда туган) 1979 елның җәендә язып алынган хәбәрләр эзләнүләргә этәрде. Шулай ук аның сакланып калган бердәнбер «Төрмәләр хатирәсе» повестенда да биографик материаллар чагылып үтә.

Зәкиҗан Шаһгәрәев XX гасырның башларында хәзерге Азнакай төбәгендәге Күк Тәкә авылы белән кушылып беткән Ялан Күлдә имам булып торган. Язган әсәренә караганда, ул җәдид имамнарының берсе була. Шунлыктан, 1911 елда бөтен Русия империясе буенча татар мөселманнарның алдынгы фикерле кешеләрен эзәрлекләү, мәдрәсәләрдә тентүләр уздыру, аларны ябулар башлангач, имамны да кулга алып төрмәгә утырталар. Зәкиҗан Шаһгәрәев үзенең төрмәдә күргәннәрен тасвирлап китап яза һәм аны 1913 елда Казанда бастырып чыгара[1]. Имамны жандармерия һәм урыс сәяси органнары тарафыннан уйлап чыгарылган «панисламизм» дигән бәладә гаеплиләр. Ул гаепсезгә, Бөгелмә, Минзәлә, Алабуга, Сарапул төрмәләренә этап белән күчә-күчә, утырып чыга.

Зәкиҗан Шаһгәрәевнең «Төрмәләр хатирәсе» Гаяз Исхакый, Йосыф Акчура кебек язучыларның бу елларда сәясәт нигезендә төрмәгә ябылуда күргәннәрен тасвирлаган әсәрләренә ияреп язылган.

Язучының тагын «Диңгез асты, яки Яңа галәм» исемле фантастик әсәре булуы хакында мәгълүмат бар, ләкин аның хәзергә табылганы юк.

Зәкиҗан Шаһгәрәев язмышы Совет дәверендә фаҗигале бетә. Аны 1937 елда гаепсезгә репрессиялиләр. Ул елларда кулга алынган язучыларның бөтен мирасын яндырып бетергән кебек, ГПУ органнары Зәкиҗан Шаһгәрәев мирасын да бик тырышып юкка чыгарганнар.

### «Төрмәләр хатирәсе»

*(өзек)*

1911 елны 30 гыйнварда көндез сәгать тугызда беренче участокның приставы өч урядник, бер стражник һәм бер переводчик илә безнең йортка килгәннәр иде. Үземне урядник аты илән Күк Тәкә базарыннан бер полицейский барып алды.

Становой пристав, нәзакәт берлән генә, үзенең ни өчен килгәнен, кайдан мәэмүр (чиновник) булганлыгын сөйләде. Табигый, мин аңа һәммә ачкычларны биреп, һәммә урыннарны күрсәтә башладым. Ошбу көн тентү кичкә кадәр сузылды.

Кич белән безгә Тымытыкка барырга кушып, үзе Тымытыкка китте: «Мин бу язмаларны А...дан перевод иттерәм»,— диде. Мин аңа каршы: «Мин аның переводына гына риза булмам шул»,— дигәч,— «Алай булса, үзең ышанган кешедән берәр кешене алып барырсың»,— диде.

Без ошбу көн ахшамнан соң Күк Тәкә имамы мулла Закир әфәнде Галиәкбәров илә Тымытыкка киттек. Без барганда, пристав язуларны А...дан перевод иттереп тәмам итмеш иде. Мулла Закир әфәндедән бераз нәрсә сорады да: «Бер дә зарарлы нәрсә тапмадым», — диеп, протокол язып, миннән кул куйдырды. Аннан без кайтып киттек.

Менә 4 февраль җомга көн көндез тугыз сәгатьтә янә әлеге пристав, өч урядник, бер стражник һәм А... илән килеп тентү башладылар. Бу юлы пристав әүвәлгесе кеби нәзакәтле түгел, ачулы, караңгы иде.

Барыннан да артык А... игътина (игътибар) илә тентемәк, бик гади җөмләләрне дә бик куркынычлы иттереп тәрҗемә кылмакта иде. Җомга көн булу мөнәсәбәте илә мин приставтан җомга укырга чыгарга сорадым. Пристав рөхсәт бирмәде...

Җомга вә шимбә көн тентү, тәфтишләр (эзләнүләр) соңында шөбһәле табылган китапларны пичәтләп алып, үземне арестовать иттеләр... Ярты төн узып сәгать берләргә кадәр булган бу биш сәгатьлек гомер үлемгә мәхкүм булган адәмнең үлем алдында торуы кеби кадәр авыр булды. Чыннан да, янымда ашау-эчү әсбабыннан һичнәрсәм юк. Карыным ач, үзем, көннең салкын кыш булуына карамыйча, хисапсыз сусаган идем. Сәгать берләрдә эчкәре, ристаннар ята торган бүлмәгә кереп ятарга әмер булды. Хәзергә кыеннан сәламәт калуыма шатланып, квадратный алты аршинлы, тимерләгән ике тәрәзәле бер бүлмәгә кереп, бер тунымны — астыма, берсен өстемә куеп, берничә сәгать рәхәт-рәхәт йоклап уяндым.

7 февральдә, иртән сәгать уннарда исправник янына ике полицейский алып менделәр. Исправник әфәнде, ике сүзнең өченчесе уларак: «Сине төрмәгә ябам. Китапларыңны карагач, жандармский теләсә нишләтер!» — диде. Ябучы 22 статья иде («Сильная охрана» статьясы). Шуннан соң сәгать икенче яртыларда ике страж илә төрмә йортына сәфәр иттек.

Ике кат капка арасында уң якка кертеп чишендереп, солдат приемы рәвешендә иңне-буйны үлчәп, булган кадәр акчаларымны алып, бик каты тентүләр соңында киемнәремне кияргә куштылар. Ристан киеме кидерә торганнардыр диеп көткәндә, үз киемнәремне кияргә рөхсәт булуы бу сәфәремдә беренче шатлыгым иде. Больница кыйсмендә (өлешендә) булган өч бүлмәнең берсенә — иңе ике, буе дүрт, биеклеге өч ярым аршинлы, тимерләгән зур гына тәрәзәле, ике караваt, бер өстәлле бүлмәгә китереп, ишекне ябып, каты гына шалтыратып йозаклап та куйдылар... Шул рәвешчә төрмә мәгыйшәте башланды...

Бөгелмә төрмәсенең тормышы, кыскача әйткәндә, менә шуннан гыйбарәт иде: даими 130 дан 150 гә кадәр ристан булмакта, шуның эченнән 10 нан вакыты илә 35 кә кадәр хатын таифәсе (төркеме) булынмакта, хатын-кыз нәүгысы (җенесе) күбрәге аракы сату илә кермәктә иделәр. Бөгелмә төрмәсе кечкенә төрмә иде. Бөгелмә өязенә табигъ булган (караган) халыклар да табигый юаш булдыкларыннан, монда сәяси эш илә керүчеләр юк хөкемендә аз иде...

## ШАГЫЙРЬ ҺӘМ ПЕДАГОГ
## СӘХАУДДИН МИҢЛЕКӘЙ

Сәхауддин Кашшафеддин улы Миңлекәй 1895 елның 7 декабрендә Татарстанның Ютазы төбәгенә карый торган Акбаш авылында игенче гаиләсендә туган.

Башлангыч белемне үз авылларында алгач, Сәхауддинне 1906 елны атаклы Бәйрәкә авылы мәдрәсәсенә бирәләр. 1913 елны ул Добрино авылындагы ике класслы урыс мәктәбенә кереп укый башлый, шул ук елда туган авылында кызлар мәктәбе ачып, укыту эшенә керешә.

1915 елны Сәхауддинне патша армиясенә солдат итеп алалар. Укый-яза белгән бу егет солдатлар арасында тиз абруй казана. 1917 елны февраль революциясе булгач, аны солдат комитетына сайлыйлар.

Сәхауддин, архив материалларына караганда, 1913 елдан яза башлый. Солдат хезмәтенә алынгач, аның шигырьләре фронтта татарлар өчен чыгарыла торган «Безнең тавыш» (Псков) һәм «Сугыш хатирәләре» исемле газеталарда, шулай ук Гаяз Исхакый тарафыннан чыгарылган «Ил» газетасында басылып торалар.

1918 елны Сәхауддин Миңлекәйне армиядән демобилизовать итәләр. Ул ватанына кайтып укытучылык эшенә керешә. 1919 елда Самара шәһәрендә мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбияләү курсларында укый. Шуннан кайткач, Зәй-Каратай, Әлмәт, Чәшеле (Югары һәм Түбән Чыршылы авыллары), Әпсәләм авылларында тарихта беренче мәртәбә татар балалар бакчалары оештырып җибәрә. 1920 елда Бөгелмә шәһәрендә дә аның җитәкчелегендә беренче балалар бакчасы ачыла.

1921 елгы ачлык вакытында балалар йортлары оештырып, күп ятимнәрне ач үлемнән коткарып кала. Шуннан соңгы бөтен гомерен ул тәрбия эшенә багышлый.

1926—1929 елларда Ленинградта өчъеллык югары кооператив курсларында укый. 1929—1932 елларда исә Казанда кооператив техникумында статистика фәне укыта.

1932 елны яңадан Бөгелмәгә кайтып, андагы сәүдә һәм кооператив мәктәбендә укыта башлый. 1942—1946 елларда хәрби хезмәттә була. 1950 елны Уфа шәһәренә күчә һәм шунда 1954 елның 14 гыйнварында авырып үлә.

Сәхауддин Миңлекәй үзенең иҗатын шигърияттән башлый. Аның әсәрләрендә авыл тормышы, табигате һәм шул фонда хезмәт кешесе гәүдәләнә. Империалистик сугышта авыр солдат хәле тасвирлана. Шагыйрь Октябрь революциясен шатлык белән каршылый, ләкин бу социаль күренештән үзенең алданганлыгын гражданнар сугышы һәм аннан соңгы сәясәттә күрә башлый.

Педагог буларак, аның шигырьләрендә мәктәп, тәрбия, балалар темасы үзәк урыннарны били. Яшьтән үк татар фольклоры белән кызыксыну Сәхауддин Миңлекәй шигырьләренә фольклор материаллары төсмерен бирә. Аның тарафыннан дистәләрчә әкият, мәзәк текстлары тупланып, аларны шагыйрь үзе исән чагында Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына тапшырган булган. Татар халкының күптомлык фольклор җыелмасын хәзерләгәндә, галимнәребез С. Миңлекәй хезмәтләрен дә искә алганнар һәм томнарга керткәннәр.

Шагыйрь һәм фольклорчы Сәхауддин Миңлекәй — берничә китап авторы. 1925 елны аның фольклор материаллары нигезендә язылган «Җырлы уеннар», 1927 елны Казанда «Кояшка таба», 1931 елда, үз иҗатын эченә алган, балалар өчен «Тезмә сүзләр» җыентыгы һәм урысчадан тәрҗемә шигырь, проза китаплары басыла. 1951 елда ул Уфада «Авыл кооператив кибетләрендә исәп-хисап йөртү» һәм 1952 елда «Сельпо хуҗалыгында акча, товар һәм башка бәялекләрне барлау» исемле уку әсбаплары язып бастыра.

Шагыйрь иҗат иткән әсәрләр барысы да балалар тәрбиясе өчен язылганнар, шунлыктан аны балалар шагыйре дип һич икеләнмичә билгеләргә була. Аның архивын Уфада яшәүче кызы пенсиядәге врач Чәчкә ханым Тукаева Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Мирасханәсенә китереп тапшырды. Архивта Сәхауддин Миңлекәйнең басылмаган хикәяләре, «Акбаш авылы үткәне» язмасы, «Гөлбикә» поэмасы, «Качкыннар» драмасы, басылмаган шигырьләре һ.б. бар.

Тагын шунысы игътибарга лаек, аның бер шигырь җыентыгын нәшриятка төзеп биргәч, рецензент Кави Нәҗми: «Бу китапта бер генә урында да «социализм», «Сталин» кебек сүзләр юк, аларны басарга ярамый»,— дип каршы төшкән булган.

Әлбәттә, Сәхауддин Миңлекәй ялган авторитетларга табынмаган, шунлыктан аның иҗаты 1930 еллардан соң үсә алмый басылып калган. Шагыйрьнең әдәби мирасы татар балалар китабы репертуарында бүген дә үз урынын алырлык һәм, һичшиксез, өйрәнелүгә лаек.

## Кирәк түгел миңа

Кирәк түгел миңа алтын сарай,
Зур исемнәр, таҗлар, тәхетләр.
Кирәк түгел миңа байлык, дан, шөһрәтләр,
Кирәк түгел андый бәхетләр!

Кирәк түгел миңа матур кызлар,
Тәмле эчемлекләр, шәрапләр.
Кирәк түгел бричка, тарантаслар,
Кареталар, юлга шәп атлар!

Кирәк булса — сезгә булсын барсы.
Миңа кирәк ирек, киң ялан,
Кайда хуш ис, гөлләр, күбәләкләр,
Кошлар сайрый, — шуңа шатланам!

## ЙОМГАК

Бу китапта Кама аръягының көнчыгыш төбәгендә татар әдәбияты үсеше тарихының үткән юлы тасвирланды. Моның өчен чыганаклар системасы барлыгын ачыклау мөһим иде.

Тупланган бай археографик материал бабаларыбызның моннан 1500 —2000 еллар элек калыплашкан рухи истәлекләр системасы булганлыгын исбатлый. Мәсәлән, унике еллык хайван исемнәре белән бәйле календарь һәм аның фалнамәләре, борынгы ырым үрнәкләре, төшлекләр шушы системага керәләр. Әлеге ядкәрләр бабаларыбызның борынгы гасырларда кытай, тибет, һинд цивилизацияләре белән мәдәни бәйләнешләрдә яшәгәнлеген раслыйлар. IX — XIII гасырларда төрки телендә бай әдәбият тудырыла. Бу әдәбият вәкилләреннән Йосыф Баласагуни, Йосыф Йүгнәки, Әхмәт Йәсәви, Сөләйман Бакырганый, Кол Галиләрнең әсәрләреннән үрнәкләр сакланып калган. Кама аръягы төбәгендә уздырылган археографик экспедицияләр барышында Насреддин Рабгузи, Мәхмүд бине Гали әл-Болгари әр-Кәрдәри, Хисам Кятиб,

Хәйдәр Хәрәзми, Лотфи, Өмми Камал, Хатаи Сакай, Кәрдәҗи Гали кебек шагыйрь һәм прозаикларның әсәрләре күчермәләре табылды.

XIV — XVII гасырларда Әлмәт төбәге Нугай урдасы дәүләте биләмәләренә әйләнгән вакытта бу якларда татар чәчән шагыйрьләренең традицияләре дәвам иткән: Җирән чәчән, Субра җырау, Асан Кайгу, Дусмәмбәт җырау, Чалкыяз җырау кебек импровизатор чәчәннәр иҗаты үсеп китә. Чын халык романнары булган «Чыңгызнамә», «Алпамыш», «Кузы Күрпәч һәм Баян Сылу», «Таһир белән Зөһрә», «Идегәй», «Гайсә углы Амәт», «Чура батыр», «Түләк белән Сусылу», «Кырык кыз» дастаннары һәм башкалар популярлык казана.

Шунысы игътибарга лаек, чәчәнлек әдәбияты традициясе Кама аръягында да, Башкортстан районнарындагы татарлар арасында да XX гасырның икенче яртысына кадәр сакланып килә. Моның мисалларын без 1930 елларда Нәкый Исәнбәт тарафыннан язып алынган Сукыр Фәррах җырлары-такмакларында, Азнакай төбәге Үчәлле авылы чәчәне Газыймә Гәрәйшина шигырьләрендә (1980 ел), Әлмәт ягындагы Яңа Кәшер авылыннан булган Әхмәди карт (1960 ел), Атаян (Шәфикъ Баһманов) такмакларында, Лениногорск төбәге Карагай авылыннан Миңлеҗамал Гулова (1908 — 1981), Фатыйма Зиннурова (1907 — ?) мөнәҗәт-такмакларыннан күрәбез һ.б.

Аларның иҗатында көннең әһәмиятле проблемаларына мөнәсәбәт белдерелә. Әхмәди карт үзенең такмакларында ярлыларны гаделсез җәберләүгә ризасызлыгын белдерсә, Атаян иҗатында колхозны конц-лагерьга әйләндерүне гаепләү; хатын-кыз чәчәннәрнең әсәрләрендә әхлакый, дини мотивлар күтәрелә.

Чәчән-шагыйрьләрнең әсәрләре афористик икеюллыклар, шигъри сатирик дүртьюллыклар, әхлаксызлык, шәфкатьсезлек, гаделсезлек хакындагы моң-зар тулы шигырь-мөнәҗәтләрне тәшкил итәләр. Кызганыч, әмма Нәкый ага Исәнбәт башлаган бу игелекле эшне татар әдәбиятында күреп, күтәреп алып китүчеләр күренмәде диярлек. Шунлыктан югарыда исемнәре китерелгән яки бу очракта исемнәре китерелмәгән чәчәннәр иҗаты, аларның тормыш юллары, язмышлары да өйрәнелмәде. Тик аерым чәчәннәрнең генә иҗатлары хакында берничә мәкалә чыгып калды. Әлбәттә, чәчәнлек иҗаты татарлар яшәгән барлык төбәкләрдә дә булган һәм беркадәр бүгенге көндә дә дәвам итеп килә, чөнки аны күпгасырлык тарихи традициясе булу яшәтә.

XVII гасырның икенче яртысыннан Кама аръягының көнчыгыш өлешендә татар язма әдәбияты үсүнең яңа этабы башлана. Аны әлеге төбәктә башлаучылар булып шагыйрьләрдән Мәүла Колый һәм иҗаты аз микъдарда сакланып калган Идрис Хафиз кебек шәхесләр торган. XVIII гасырның беренче чирегендә Әлмәт төбәгендә шагыйрь һәм дин галиме Габдерахман Тайсугани һәм телче филолог Гобәйдулла Болгари (Кизләви) хезмәтләре иҗат ителә.

XVIII гасырның иң куәтле халык хәрәкәтләренең берсенә әйләнгән Пугачев җитәкчелегендәге кораллы күтәрелеш үзенә зур көчне татарның милли-колониаль изүгә каршы көрәшендә тапты. Татар халкы үзенең милли бердәмлеген, идеологиясен, икътисадын торгызу өчен беркадәр иркенлеккә; теле, дине, мәгарифе өчен чикләүләрне киметүгә иреште.

Татарларда җанлану хәрәкәтенең иң әүвәлге билгеләре булып аның зиратларына куелган эпитафия язмалары тора. Әлмәт һәм аңа күрше төбәкләрдәге Чалпы, Урсай, Камы Исмәгыйль, Сарлы, Әлмәт (шәһәр), Тымытык, Бәйрәкә, Митрәй, Тайсуган, Нәдер, Колшәрип, Сарабиккол авылларындагы мөселман татар зиратларының эпитафик язмалары эчтәлек, каллиграфик бизәлеш, мигъмари рәвешләре белән милли-мәдәни үсешнең җанлануын сөйлиләр.

Җанлану хәрәкәтенең билгеләреннән авылларда мәчетләр, мәдрәсәләр артуны күрсәтергә кирәк. Аларга бәйле рәвештә, халык арасында укымышлылык, белем таралу күтәрелеше башлана. Татар укымышлылары мәгариф системасы, дини идарә һәм милли яшәеш, әхлак нормалары хакындагы проблемалар өстендә эшлиләр. Шушы җәһәттән, төбәктә Габдерәхим Утыз Имәни, Таҗеддин Ялчыгол, Хисамеддин Мөслими әсәрләре бу заманда күтәрелгән бөтен актуаль проблемаларга да кагыла иде. Алар тарафыннан күтәрелгән фикерләрнең кайберләре татар милләте өчен әле XX гасыр ахырында да әһәмиятләрен югалтмадылар. Әлеге проблемалар нигездә мәгърифәтчелек карашлары аша калыплаштылар.

Габдерәхим Утыз Имәни, Таҗеддин Ялчыгол һәм Хисамеддин Мөслимиләрнең эстафетасын XIX гасыр урталарына кадәр төбәктә Әхмәтҗан бине Габдерәхим Болгари (?—1848), Әхмәтҗан бине Шәмседдин Тубыли (1823 — ?) кебек шагыйрьләр дәвам итә. Аларның әсәрләрендә дә мәгърифәтчелек, дидактик үгет-нәсыйхәт өстенлек алган.

XIX гасырның ахырында Әлмәт төбәгендә Ризаэддин бине Фәхреддиннең мәгърифәтчелек эшчәнлеге башлана. Аның һәм бу төбәктән чыккан Фатих Кәриминең мәгърифәтчелеге гасыр башындагы шагыйрь һәм фәлсәфәчеләрнекеннән инде нык аерыла башлый. Аларның әсәрләрендә мәгърифәт фикерләрен таратучылар — урта гасыр мөселман цивилизациясендә тудырылган легендар шәхесләр түгел, ә XIX — XX гасырлар чигендә яшәгән татар типлары.

XX гасыр башында әдәбият мәйданына чыккан Фазыл һәм Кәбир Туйкиннар, Зәкиҗан Шаһгәрәев, Афзал Таһиров, Һади Атласов һ.б. әдәби, публицистик һәм тарихи әсәрләрендә әдәбият сәхнәсе инде тулаем дөньявилыкка таба борыла. Бу дәвердә дә Кама аръягында үскән әдәбиятның дистәләрчә каләм тибрәтүче яшьләре булган. Тик аларның иҗатлары тупланмаган булу — шактый бай мирасның бу хезмәттә урын алмавына сәбәп булып тора.

Йомгаклап әйткәндә, Әлмәт һәм аңа күрше төбәкләрдә туып үскән һәм иҗат иткән әдип-шагыйрьләр, галимнәр иҗаты татар әдәбиятының бай һәм кыйммәтле мирасын тәшкил итә.

ЭЧТӘЛЕК

Кереш ..........................................................................................................................
**Кама аръягы төбәкләрендәге археографик табышлар** ............................
**Тарих һәм әдәби мирас** ..........................................................................................
**Монда гыйрфан, монда нур...** ................................................................................
**Халык китабы ядкәрләре** ..............................................................................................
«Китабе авык» ..............................................................................................................
«Ана белән угыл» (Хикәйәте мөнәҗәт) ...............................................
«Акай явы турында хикәят» ..........................................................................
**Шагыйрь Мәүла Колый** .................................................................................................
«Хикмәте хәким» ........................................................................................................
**Шагыйрь һәм галим Габдерахман Тайсугани** .................................................
«Касыйдә» .......................................................................................................................
**Шагыйрь Рәхимкол бине Исламкол** ........................................................................
«Хикмәте Мәҗнүн» ...........................................................................................
**Тарихчы Петр Иванович Рычков** ..............................................................................
«История Оренбургская» исемле китаптан .......................................
**Шагыйрь һәм галим Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгари** ......................
«Мәрсия» ............................................................................................................................
**Таҗеддин Ялчыгол углы әл-Иштәки әл-Болгари** .........................................
«Рисаләи Газизә» әсәреннән ..............................................................................
**Хисамеддин Мөслими һәм аның «Тәварихе Болгария» әсәре** ...............
«Тәварихе Болгария» китабыннан .............................................................
**Шагыйрь Әхмәтҗан Тубыли** .........................................................................................
«Мәрсия» .........................................................................................................................
**Шагыйрь Әхмәт Уразаев-Кормаши** .........................................................................
«Кыйссаи Бүз егет»тән ...........................................................................................
«Таһир илә Зөһрә кыйссасы»ннан .................................................................
**Ризаэддин бине Фәхреддин** .........................................................................................
«Рәсми тәрҗемәи хәлем» ...........................................................................
**Шагыйрь Кәшшафеддин Минзәләви** ....................................................................
«Әдәпле бала» китабыннан ...............................................................................
**Тарихчы Һади Атласов** ......................................................................................................
«Сөен-бикә» китабыннан ........................................................................................
**Язучы һәм журналист Фатих Кәрими** .....................................................................
«Аурупа сәяхәтнамәсе» китабыннан .......................................................
**Кәбир Туйкин** ..........................................................................................................................
**Фольклорчы, әдип һәм педагог Фазыл Туйкин** ..............................................
«Сугышчы Сатыш әфәнде» ........................................................................
**Әдип Афзал Таһиров** .......................................................................................................
«Смотр» .......................................................................................................................................
**Зәкиҗан Шаһгәрәев** ...........................................................................................................
«Төрмәләр хатирәсе» ....................................................................................................
**Шагыйрь һәм педагог Сәхауддин Миңлекәй** ..................................................
«Кирәк түгел миңа» ...................................................................................................
Йомгак .........................................................................................................................

Заказное издание

**Ахметзянов Марсель Ибрагимович**

**ВОСТОЧНЫЕ РАЙОНЫ ЗАКАМЬЯ И ИСТОРИЯ ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРЫ**

*(на татарском языке)*

Редакторы *Н. К. Нотфуллина*
Рәссамы *Р. А. Сәйфуллина*
Техник редакторы *М. И. Данилевская*
Компьютерда *Г. Г. Шәйхетдинова* эшләде

Нәшриятка 83нче номерлы лицензия 1997 елның 7 апрелендә бирелгән. Оригинал-макеттан басарга кул куелды11.11.99.
Форматы 60x84 1/16. Офсет кәгазе. «Карелия» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 9,30 + форз. 0,23.
Нәшер-хисап табагы 7,73 + форз. 0,37. Тиражы 500 д. Заказ 101.

«Мәгариф» нәшрияты. 420503. Казан, Бауман урамы, 19.
Издательство «Магариф». 420503. Казань, ул. Баумана, 19.
Тел./факс (8432) 92-57-48.

ООО «Мастер Лайн». 420111. Казань, ул. Б. Красная, 55.